Безнен МИРАС

09

сентябрь 2014

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Кардәшлеккә чикләр юк,
Кардәшлектә читләр юк!

27-30 августта башкалабыз Казанда төрки телле әдәби журналларның форумы булды. Анда 14 илдән һәм Россия төбәкләреннән килгән баш мөхәррирләр вә каләм әһелләре катнашты.

Солтан Исхаков фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдмәнд

Безнең МИРАС 12 +

09(32)
сентябрь 2014

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

4

ЭЧТӘЛЕК

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

3 Туган тел сагында

ТАРИХИ МИРАС

4 Казан татарларында агач архитектурасы. *Михаил Худяков*
9 Исмәгыйль бәй Гаспралы... «Тәрҗеман». *Йосыф Акчура*
12 Бөек шигар, олуг идеал. *Фатих Әмирхан*

КАЗАН — ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ 2014 ЕЛДА МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ

14 Айшә ханым. *Усеин Болатуков*
20 Яңа чор үзбәк шигърияте Чулпаны. *Рәдиф Гаташ*

ДИНИ МИРАС

24 «Шәкертләргә бүләк иттем...» *Айдар Гайнетдинов*
25 Көтебе ситтә вә мөәллифләре. *Ризаэддин бине Фәхреддин*
30 Ал мәчет. *Ильяс хәзрәт Җиһаншин*

ПЕДАГОГИК МИРАС

34 Белем әлифбадан башлана. *Ләлә Мортазина*
38 Әхлак. *К.Бикколый, Г.Госмани*
40 И, туган тел...

ХӘТЕР САНДЫГЫ

42 Сүз һәм сурәт. *Ислам Әхмәтҗанов*

ҖИҢҮ — 70!

44 Уфалла арбасы
46 Кем ул — Абдулла Баттал?! *Фәрит Баттал*
51 Низаметдинның ике улы. *Рашат Низами*
54 Данлы юл эзләре. *Хәнәфи Бәдигый*

ӘДӘБИ МИРАС

56 Кутадгу билик (Котайткыч белем). *Йосыф Баласагуни*
60 Солдат. *Гаяз Исхакый*
68 Күчем ханның оныгы. *Марсель Галиев*
77 Тукай энциклопедиясе. *Әнисә Алиева*

34 БЕЛЕМ ӘЛИФБАДАН БАШЛАНА. *Ләлә Мортазина*

89 МИЛЛИ МУЗЕЙ ХӘЗИНӘЛӘРЕ.

78 Ачы тәҗрибә авазы. *Габдулла Тукай*

ХӘТЕР САГЫНДА

80 Урланган такта кыйссасы. *Мөбарәк Мусин*
85 Мөкатдәс хәзинә. *Рамил Вәлиев*
89 Милли музей хәзинәләре.

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

90 Ярты гасыр элек — татар мәктәбе.

СӘНГАТИ МИРАС

96 Бәяләнмәгән талант. *Марс Макаров*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

102 Тел язмышы — милләт язмышы. *Миргазиян Юныс*
106 Миллият сүзлеге. *Адлер Тимергалин*

ТАБИГЫЙ МИРАС

110 Ак кыя. *Морад Дусай*

100 ЕЛ ЭЛЕК

112 «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның сентябрь ае. *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 Көлке куа килә...

119 Мирасворд
120 «Безнең мирас» елъязмасы. Сентябрь

Заказ №А-2270. **Тираж** — 1532 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 2.09.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Татарстан фән һәм мәгариф министрлыгы, Татарстан радиосы, композитор Риф Гатауллин архивларыннан һәм Ленар Гобәйдуллин төшергән фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Җәйге челлә. Төш вакыты». 2006.
Киндер, майлы буяу. *Р.Хуҗин рәсеме*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закир
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миңнәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Техник хезмәткәр
Данил Салихов
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ТУГАН ТЕЛ САГЫНДА

Август аенда мәркәзебез Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының VI Бөтенроссия корылтае булып узды. Андагы күп санлы чыгыш-нотыкларда әйтелгән алмаксатлар, кем әйтмешли, якты хыял-теләкләр чын-чынлап тормышка ашар, газиз туган телебезгә, аның сагында торучы фидакяр затларыбызга игътибар тагы да көчәер, яшь буынны тәрбияләүдә, телебезне саклауда күркәм вә нәтиҗәле эшләр отыры артыр, иншаллаһ.

Теле барның — иле бар. И, газиз туган тел! Мәшһүребез Тукайча әйтсәк: «И, туган тел, и, матур тел — әткәм-әнкәмнең теле!»

«Безнең мирас»ның бу саны, тулаем диярлек, телебезгә нисбәтле саллы мәкаләләрдән, тарихи, әдәби вә сәнгати әсәрләрдән гыйбарәт. Укып уйланырлык, гыйбрәт алырлык, билгеле бер нәтиҗә ясарлык язмалар алар.

«Телне саклау, аның байлыгын халыкка җиткерү өчен тотылган акча Япония дәүләтенең бюджетында икенче урында тора» (Миргазиян Юныс).

«Авыл җирендә мәктәпләрне эреләндерергә тырыштык (1960 нчы еллар башында дип аңларга кирәк. — Л.Л.), *шунлыктан мәктәпләрнең саны бераз кимеде. 3540 иде, 3460ка калды. Татар мәктәбе ныгый, алга бара. Ел саен колхозлар исәбенә 150-160 мәктәп салына...»* (Мирза Мәхмүтов, 1958-1976 елларда ТАССР мәгариф министры).

«Дәрес әзли. Сәгать, вакыт әзли,
Мәктәп буйлап әзли балаларын.
— Укысыннар! Тукай теле бит! — ди,
Үгетләргә чыккан аналарын...
Гафу итмәс халык, телне кыйнап,
Тәхетләрдә утыручыларны.
...Бер гаепсез башын иеп йөри
Татар теле укытучылары» (Кадыйр Сибгатуллин. «Шәһәрдә татар теле укытучылары»).

Тукай теле. Татар мәктәбе... Күпме михнәтләр кичеп тә исән ич әле син, Татар Теле! Сау әле син, Татар Мәктәбе!

Хөрмәтле татар теле һәм әдәбияты укытучылары! Тел язмышы, милләт язмышы — сезнең кулда. Игелекле хезмәт юлыгызда Ходай сезгә сабырлыклар бирсен. Һәрчак башыгызны горур йөртергә язсын. Амин!



ТАРИХЧЫ, АРХЕОЛОГ МИХАИЛ ХУДЯКОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Михаил Худяков

КАЗАН ТАТАРЛАРЫНДА АГАЧ АРХИТЕКТУРАСЫ

Бүгенге көнгә кадәр мөселман сәнгатенә багышланган хезмәтләрдә болгар һәм татар тарихи һәйкәлләре бөтенләй тикшерелми. Ә ул аерым игътибарга лаек, чөнки IX-X гасырдан башлап Идел буенда үзенчәлекле мәдәният чәчәк ата, мондагы халык алга киткән гарәп-фарсы мәдәниятен тоеп яши. Гөрләп торган халыкара сәүдә үзәкләре булган хәзәр, болгар, соңрак татар шәһәрләрендә игътибарга һәм өйрәнелүгә лаек, үзеннән бик күп ядкярләр калдырган төзү эшләре үсеш кичерә. Ибн-Хәүкәл истәлекләренә караганда, X гасырда хәзәрләрнең башкаласы Итилдә 30га якын мәчет һәм кирпечтән салынган каган сарае булган. Бүгенге көнгә Болгарда таштан кабартып һәм чокып ясалган арабескалар белән бизәлгән монументаль корылма, хәрабәләре һәм искиткеч мозаика һәм майолика калдыклары сакланган.

Шунысы кызык, Казан археологлары, Болгар һәм Казан губернасының башка җирләрендәге казылмаларга зур игътибар биреп, бүгенге көнгә кадәр бер тапкыр да Казанның үзенә куллары җитмәде.

Татар Казаны таш биналарының тышкы күренешен очраклы рәвештә 1861 елда кафедральный собор болдырын сүтеп корганда табылган күпертеп сыланган арабескалар (алар Казан университеты музеенда саклана) һәм Касыйм шәһәрендәге шуңа охшаш үрнәкләр аша гына күзаллый алабыз.

Күпертеп сыланган арабескалар Казан мәчетләрендәге декоратив бизәлешнең Болгар мәчетләрендәгечә булуын күрсәтә. Касыйм биналары белән болгар биналары арасында гаҗәеп охшашлык бар: Касыймдагы Хан мәчете манарасы Болгардагы Зур манара һәм Кече багана белән бер төзелеш мәктәбенә карый. Касыймның Казан белән мәдәни, сәүдә һәм сәяси бәйләнешлары бездә болгар төзелеше формалары Касыймга бары тик Казан аша гына килеп кергән, дигән фикер калдыра һәм, шулай итеп, Казан архитектурасының килеп чыгышы болгар архитектурасы белән бәйле булганлыгына тагын бер дәлил булып тора.

Бүгенге көнгә кадәр үзенең бөтен миллилеген саклап калган агач архитектурасы иң оригиналь һәм үзенчәлекле булырга тиеш иде. Кызганычка күрә, көнчыгыш архитектурасы тарихчылары әлеге халык архитектурасына беркайчан да игътибар итмәгәннәр. Казан татарларының агач архитектурасына тулы бер характеристика бирү безнең бурычка керми, без бары тик үзебез туплаган берничә күзәтүне билгеләп, абруйлырак белгечләрнең әлеге үзенчәлекле сәнгать төренә игътибар итүләренә өметләнәбез.

Казан татарлары булдырган иң үзенчәлекле архитектура гонсыры булып, мөселман мәчете манарасы тора. Гадәттәгечә, мәчет уртадан манара тишеп чыккан ике кыеклы түбәле турыпочмаклы агач йорт формасында салына. Манара — өстендә ачык мәйданчыгы яисә пыяладан беседкасы булган 8 кырлы багана; манара шпиц һәм кыйгач ай белән тәмамланган 8 кырлы гөмбәз белән төгәлләнә.

Казан мәчетләре манараларының классик мөселман архитектурасы белән дә, шулай ук Кырым һәм Кавказ архитектурасындагы манаралар белән дә бернинди уртаклыгы юк. Алар урнашу тәртибе (түбә уртасында), архитектур формалар, түшәү материаллары һәм пропорция белән аерылып тора.

Силуэтның пропорциясе билгеле бер канунга буйсына, шунлыктан җиңеллек, төзеклелек һәм нәфислек тәэсиренә ирешелә. Манара киңлегенең аның биеклегенә даими бәйләнеше, шу-

лай ук гөмбәз өсте пропорциясе төгәл сақлана, ләкин аның чикләре әлегә өйрәнелмәгән. Күзәтүләрдән чыгып, гөмбәз өсте биеклегенең нигез диаметрына булган бәйләнеше 3,5:1 яисә 4:1 нисбәттә булуы шактый еш очрый, дия алабыз.

Казан шәһәрендә татар корылмалары азрак үзенчәлеккә ия. Йортның алгы ягы урамга түгел, ә ишегалдына карап тора, урам ягыннан йорт койма белән аерып алына. Койма өстенә рәшәткә куеп, йортта яшәүчеләр урамның бер өлешен ерактан ук күреп торалар, шул ук вакытта үзләре үтеп баручыларның кызыксынучан карашларыннан кача да алалар. Гадәти агач йорт ике кыеклы түбәле һәм фронтонлы бүрәнә ызба. Казан татарларының бай тораклары бер-берсе белән пыяладан ябылган галлерея һәм витражлы чыгу юлы белән тоташкан ике катлы берничә йорттан тора. Бай йортларның өстендә һәрвакытта да борынгы урыслардагы теремны (тирмәне!) хәтерләткән пыяла чарлак урнаштырыла.

Әмма сәнгатьнең бер генә өлкәсендә дә татарның милли холкы декоратив бизәкләрдәге сыман ачык чагылмый кебек. Декорация принциплары буенча татарлар урыслардан кискен аерылып торалар: урыслар агач каралтыны һәм көнкүреш әйберләрен уеп бизәп, буяуны бары тәрәзә йөзлекләрендә генә файдаланса, — татарлар, киресенчә, уеп бизәк ясаудан качып, бизәгәндә бары тик буяулар гына куллана. Төс — татар сәнгатенең төп стихиясе. Декоратив буяуларны архитектурада куллану татарларның Шәрык белән тыгыз бәйләнешен күрсәтә. Буяулар ярдәмендә чын сәнгать тудырган фарсы һәм Сәмәрканд осталары турында күпләр белә.

Буяу корылманың иң күренекле өлешләрендә кулланыла: мәчет манараларында, йорт фронтоннарында, коймаларда һәм капкаларда. Татар буявының төп үзенчәлеге — полихромия. Татарлар беркайчан да әйберне бер генә төскә буямый, алар һәрвакыт берничә төсне

Төс – татар сәнгатенең төп стихиясе. Декоратив буяуларны архитектурада куллану татарларның Шәрык белән тыгыз бәйләнешен күрсәтә.

кушып төрләндерә. Бер-берсе белән катнаштырылмаган төсләрнең кушылмасы ирексездән гаҗәпләнү тудыра (сары белән яшел, сары белән зәңгәр, яшел белән кызыл). Урыслар аны «татар зәвыгы» дип атый. Төсләрнең гадәти гаммасы гади һәм катлаулы түгел; алар һәрвакытта да диярлек бертөрле: Казан татарлары бүтән төсләрне, шул исәптән кызыл төсне яратмый һәм аларны бик сирәк очракта гына куллана.

Архитектурада полихромияле буяу биналарның тактадан ясалган диварларын каймалауда кулланыла. Ул кытыршы таш белән тышлап алган сыман горизонталь, бер-берсе белән аралашып барган киң һәм тар такталардан тора. Тар такталар батынкыланып, ә киңнәре алга чыгып тора. Манаралар да шул рәвешле бизәлә — киңнәре сары яки зәңгәр төскә, ә тарлары акка буяла. Манараның мәзин азан әйтә торган мәйданчыгыннан аста 4 төстән торган кайма урнаша, һәм ул салават күперен хәтерләтә: яшел, зәңгәр, ак һәм сары. Беседка баганалары һәм кәрнизләр ак төстә, гөмбәз исә һәрвакыт яшел була.

Йорт фронтоннары кырыйлары ак каймалы яшел яки сары төскә буяла. Кайчакта фронтонга ярымтүгәрәк тәрәзә уела, төрле якка нурлар сузгач, ул кояшны хәтерләтә (нурлар аралаша: озыннар — ак һәм кыскалар — төрле төсле). Без йорт диварын буяуның 2 ысулын атыйбыз. Бер очракта бөтен диварлар да такта тышына туры китерелгән ике төскә буяла. Киң такталар төсле (сары, кайвакытта яшел яисә зәңгәр), ә тар такталар ак төскә буяла. Буяуның икенче төре — стеналар бер төскә буялса, почмак такталарын аралаштырып буйыйлар. Бу очракта киң

такталар ак булып кала, тарлары — төсле. Бай булмаган йортларда фронтон гына буялып, стеналар такта белән тышланмый. Ишегалдындагы аерым йортларны тоташтырган галлереяларның пыялалары төрле төсләрдә була: зәңгәр, яшел, сары, кызыл һәм шәмәхә.

Буйга сугылган койма такталары вертикаль рәвештә буяла. Киң такталар соры яисә яшел төстә булса, тарлары ак төскә буяла. Рәшәткә шулай ук төрле төсләргә буяла. Мәсәлән, сөңге формасындагы очлы башы ак, баганалары яшел, ә тактасы зәңгәр төскә буяла. Капка* — татарның горурлыгы. Шуңадыр, йорт һәм койма буялмаган очракта да, капканы буямыйча калмыйлар. Капканың һәр ишеге уртасында челтәрле, чокып ясалган зур яфрак-чәчәк сыман бизәк урнаша; капканың һәр ишеге почмагында әлеге бизәкнең кечерәк кисәге урнаштырыла. Капканың фоны ачык яшел, сары яисә зәңгәр төстә булса, кырыйларындагы каймасы ишекләр белән бергә ак төскә буяла.

Урыс һәм татарлар арасында капка бизәлешендә кискен аерымлыклар күзәтелә. Урыслар капкаларын чокып бизәкләп, бернинди буяу да кулланмый. Татар агач архитектурасының иң яхшы үрнәкләре Арча кантонының төньяктагы авылларында — Югары Мәтәскә, Карадуган һәм Балтачта очрый. Мәңгәр йортларының матурлыгы турында Казан татарлары халык җырларында мактап җырлый. Арча тирә-ягындагы 1552 елгы сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан **А.М.Курбский** сүзләре искә төшә: *«Әлеге җирдә... бәк оланнарының йортлары бар, бигрәк гүзәл итеп салынганнар һәм ихластан соклануга лаеклар».* Казанның үзендә татарга хас корылмалар күп түгел. Бары 1825 елда төзелгән Адмиралтея бистәсендә урнашкан мәчет кенә милли үзенчәлекле. Казанда урыс архитекторлары тарафыннан төзелгән

Капка — татарның горурлыгы. Шуңадыр, йорт һәм койма буялмаган очракта да, капканы буямыйча калмыйлар.

*Профессор Фирдәвес Гарипованың капка атамасына багышланган «Юлларыбызга изге капкалар ачылсын!» мәкаләсе журналның 7 нче санында дөнья күрде.

Ленар Гобәйдуллин фотосы

Арча районы, Яңа Кырлай. Әхмәтхан бай йорты. XX гасыр башы

таш мәчетләр татарныкы түгел, урыс агач архитектурасының үрнәкләре булып санала. Әлеге мәчетләрдә шул чорда урыс архитектурасында өстенлек иткән өслүпләр — барокко (Апанай мәчете), рококо (Мәрҗани мәчете), классицизм (Зәңгәр мәчет) чагылыш таба.

Узган гасырның икенче яртысында шәрык алымнарын беркадәр кулланган мәчетләр (Юнысов, Госманов, Борнай, Әҗем мәчетләре) төзелә. Казандагы бер генә таш мәчет тә татар агач архитектурасының милли үзенчәлекләрен тулы күләмдә чагылдырмый. Хәтта милли архитектура өчен гадәти булган гөмбәзләр дә манараларның пропорцияләре турындагы күзаллауны тудыра алмый. Милли өслүптәге таш манараларның гүзәл үрнәген Уфадагы Мөфти мәчете (1830 ел), шулай ук Оренбургтагы 5 нче һәм Каргалыдагы 2 нче мәчеттә күрергә мөмкин. Шәһәрләрдә таш мәчетләрнең күбесе исә урыс архитекторлары тарафыннан төзелә һәм аларда милли өслүпнең эзе дә юк. Урыс архитекторларының идеяләре татар милли архитектурасы өчен ят. Кайбер мәчетләр православие чиркәүләренә охшатылып (Троицк шәһәрендәге 6 нчы мәчет), икенчеләре католикларның храмнарына охшатып, 2 манаралы итеп салынган (Уфадагы 4 нче, Троицктагы 2 нче, Каргалыдагы 8 нче мәчетләр); хәтта Мисыр пирамидасы формасындагы мәчетне дә очратырга мөмкин (Түбән Новгород ярминкәсе). Кайбер мәчетләрнең күренеше бигрәк тә сәер. Моңа Омски шәһәрендә урнашкан өч гөмбәзле мәчетне мисалга китереп була. Ә кайбер очракта архитекторның аңлаешсыз фантазиясе мәчет идеясен турыдан-туры мыскыллауга кайтып калган (Тверь шәһәрендәге мәчет тимер юлдагы су кудыру җайланмасы рәвешендә төзелгән).

Казанский музейный вестник. — 1924. — №1. — С.23-28.

Русчадан ***Ркаил Зәйдулла*** *тәрҗемәсе*

Равил Айдаров рәсемнәре ■

ИСМӘГЫЙЛЬ БӘЙ ГАСПРАЛЫ... «ТӘРҖЕМАН»

Йосыф Акчура

ИСМӘГЫЙЛЬ БӘЙ ГАСПРАЛЫ... «ТӘРҖЕМАН»

«Тәрҗеман»ны чыгару алдыннан, аңа әзерлек рәвешендә дөнья күргән «Түнгеч», «Шәфәкъ», «Ай», «Йолдыз», «Кояш» кебек басмаларының һәммәсендә Гаспралы тел мәсьәләсенә зур әһәмият бирде. Төрек (төрки) теленең байлыгына, үсү мөмкинлекләренә, телне чит сүзләр белән чүпләүгә ярамаганлыгына, төрки телләр арасында шивә аерымлыклары азлыгына, кыскасы, гомуми бер төрек (төрки) теле барлыгына карата, кырык үзәннән су китерәчәк, башта бераз яшеренрәк, соңра ачыктан-ачык сурәттә бик күп мәкаләләр язылды. Мәсәлән, «Түнгеч»нең керешен, яъни Исмәгыйль бәй милләтенә үз телендәге беренче мөрәҗәгатен шулай башлый: *«Милләтебезнең әсәре булган телебез, әдәбиятча эшләнмәгән булса да, өйрәнергә, кагыйдәләргә күндәм (киләчәк) телдер. Гаять нәфис татар шигырьләрендә, нугай жүнкеләреннән (җыр тупламнарыннан), кыргыз һәм төрекмән җырларыннан аңлашылыр ки, әгәр лисаныбыз, остасы табылып, сүз составы тикшерелеп тәртипкә салынса, хәзергегә караганда күп дәрәҗәдә алга киткән хәлгә килер һәм кулланышка җайлы булыр. Максатыбыз — телебезне алга җибәрү...»* Бу сүзләрне һич алыштырмыйча, үзенчә китердек. *(Без тәрҗемәдә бирдек. — М.Г.)* Русия идарәсе кул астында булган төрки кабиләләрнең халык әдәбияты — эшләнәчәк телнең, гомуми төрек (төрки) теленең чыганагы дип саный. Исмәгыйль бәйнең тел өлкәсендә «бөтен төрекчелеге (төркичелеге)» беренче язмасы кәгазьгә төшкән көннән мәйдандадыр. Икенче журналчыгы «Шәфәкъ»тә — бу исемнең мәгънәле булуы ачык. Казанда һәм Кырымда билгеле булган бер җырның бу төбәкләр телендә яңгырашын чагыштыра. Бу ике шивәнең якынлыгын махсус мисаллар белән дәлилли. Бер үк вакытта Казан шивәсендә чит телләрдән алынмалар күп булуын тәнкыйть итә. Асыл максат рус теленнән кергән сүзләргә ишарә булса да, тагын цензура күзәтүе астында моны ачык белдерә алмый: *«Казанлылар үз телләренә чуваш, мордва сүзләрен катнаштырып, үз сүзләрен аларның сүзләре белән алыштыралар, хәлбуки «ала-кола» тел — тел була алмый. Аракы эчәсең икән, ачыктан-ачык эч. «Сәлам» сүзе бар чакта, «Как поживаешь?» дип әйтү нигә кирәк? Кесәңдә акча барда, кешедән сорау ник кирәк? Төрекчә (төркичә) сүз бар чакта, башка тел сүзе ниемә кирәк?»* («Шәфәкъ», 9.08.1881). Бу мәзәккә охшатып язылган эпизод беренче төрки телдәге язмаларыннан ук ана телен «алалы-колалылар»дан тазартырга тырышуын күрсәтә. Ул соңгы гомеренә кадәр шул тырышлыгын саклый. «Тәрҗеман»ның госманлы төрекләре арасында киң таркалган заманында, ул госманлы теле «ала-колалыгын» тәнкыйтьли. Гаспралыны тел сафлыгын саклау хәрәкәтен башлаучылардан, шул хәрәкәт җитәкчеләреннән дип була.

Исмәгыйль бәй Гаспралының прин-

* Дәвамы. 2014 елның 1 нче санынан басылып килә.

ципларыннан берсе — төрек (төрки) хатын-кызларына иркенлек һәм ирләр белән тиң хокуклыгын тәэмин итүне яклавы. Бу принципны да ул дәвамлы рәвештә гамәлгә кертергә тырыша. Аның карашынча, хатыннар — милләт аналары, милләтне тәрбияләүчеләр. Хатыннар хәяте аңлау тапмаса, сәләтле балалар тәрбияләү эше зур кимчелеккә юлыгачак. Кешелекнең яртысы — хатыннар. Алар иҗтимагый хәяттән, хезмәттән читләштерелсәләр, милләтнең яшәеше һәм хезмәте ярты хәлендә калыр. Исмәгыйль бәйнең хатыннар мәсьәләсе турында «Хатыннар өлкәсе» дигән гүзәл бер әсәре дә бар.

Барлык төркиләрне Көнбатыш ысулы белән тәрбия итү, агарту, Көнбатыш яшәеше рәвешенә тарту, Көнбатыш сүзләреннән азат саф гомуми бер төрек (төрки) гыйлемен һәм телен мәйданга китерү, гомуми хәяткә хатыннарны да катнаштырып, барлык төрки халыкларның алгарышын һәм яңарышын тизләтү чаралары турында уйланган Исмәгыйль бәй күңелендә һәм каләмендә читтән килгән тәэсирләр чагылышы рәвешендә кайбер башка, мәсәлән, мөселман төркиләр тормышына тирән тәэсир күрсәткән дин мәсьәләләре мөһим тема тәшкил итә. Исмәгыйль бәйнең исламга карашы милли хәяткә файда дәрәҗәсе белән нык бәйләнгән. *«XIX гасыр азакларына таба исламны «төзәтү», яңарту хәрәкәте куәт алган вакыт. Ислам — көнбатыш мәдәниятен барлыкка китерүчеләрдән. Ислам, кайбер шартларда Көнбатыш мәдәниятен кабул итүгә каршы түгел. Ислам хатыннарның тиң хокуклыгын, хөрриятен, ирләр белән кулга-кул тотынып эшләүләрен яклый. Ислам мөселманнарның бер-берсенә каршы мәзһәбләргә бүленүен кире кага... һ.б.»* «Гасры сәгадәт», ягъни сәхабәләр заманындагы тәртипләрен кире кайтару идеясе белән мәйданга чыккан бу хәрәкәт — «Яңа исламизм»ның бу тезисларын Исмәгыйль бәй дә үз итә һәм милләт чикләре тышында да таратырга тырыша... «Дар-р-рәхәт мөселманнары» хикәясе (повесть-утопиясе) — шул юнәлештә тырышлыгының иң камил үрнәге.

Исмәгыйль бәйнең шул юнәлештәге эшчәнлеге үскән һәм җитлеккән-өлкәнләшкән саен, фикерләрен тарату өчен язучылык хезмәте генә җитешми башлый. Һәр елда төрки дөньяның бер тарафына сәяхәт ясый. Госманлы өлкәсе, Кавказия, Төркестан, Казан, Касыйм һәм Литва татарларының яшәешләре белән таныша, язмаларында күтәргән мәсьәләләр буенча фикер алыша. Кытайдан — Германиягә, Төньяк Боз диңгезеннән — Африкага, Һинд океанына кадәрге илләр мәгърифәтчеләре белән шул ук мәсьәләдә хәбәрләшә, фикер уртаклаша.

Русиядә 1905 ел революциясе булып, кысынкылыклар азаеп, байтак иркенлекләр туган заманда, төрек (төрки) милләтенең, башка милләтләр арасында хәят гаугасында (яшәү өчен көрәштә), Зәрдәби сүзләре белән әйткәндә, «җиңелеп, читләтелеп юкка чыкмас өчен» билгеләгән чараларны, бер принцип хәлендә «Тәрҗеман» девиз итте.

ТЕЛДӘ, ФИКЕРДӘ, ЭШТӘ БЕРЛЕК

1905 елдан соң бер принцип, бер ишарәт рәвешендә кулланылган бу өч нигез — принципның төп элементларын Исмәгыйль бәй 20-25 елдан бирле инде эзлекле, гамәлдә кулланыштан төшерелмәстән эшләтә иде. Бөтен төрекләрнең (төркиләрнең) гамәлдә, телдә, фикердә берлекләрен тәэмин итәр өчен, мәсьәләне яктырту һәм юл күрсәтүдән тыш, төрек (төрки) балаларын башлангыч белем мәктәпләрендә бу идеяләрне укытуга нисбәтле махсус тәртип-кагыйдә урнаштырган иде. Билгеләнгән программа «ысулы җәдит» буенча укытыла. Ягъни Европа ысулына нигезләнгән мәктәпләрдә

башлангыч белем ана телендә — җирле шивәләрдә укытылачак. Фәкать өч елга кадәр. Шулвакытта, алар әдәби тел дигән «гомум төрек (төрки) теле»н дә өйрәнәчәкләр. Дүртенче уку елыннан башлап, укытулар шул әдәби телдә, барлык төркиләр өчен уртак бер телдә булачак.

Исмәгыйль бәйнең әдәби теле — гомуми төрек (төрки) теле дип аталган, төркиләр өчен үзара аңлашырга уртак бер төрки тел — нык садәләштергән Истанбул төрекчәсе... Мәктәпләрдә тел берлеге белән бер үк вакытта шул ук идеянең башка элементлары — фикер һәм эш берлеге өйрәтеләчәк һәм аңлатылачак. Гаспралының өмет һәм гамәленә караганда, Төньяк һәм Көнчыгыш төрекләрендә (төркиләрендә) бер яктан — мәктәпләр, икенче яктан — матбугат, өченче яктан — хәйрия, гыйлем һәм әдәбият җәмгыятьләре белән милли ярдәмләшү оешмалары ярдәмендә телдә, фикердә, эштә берлек идеалын тормышка ашыру мөмкин нәрсә.

«Телдә, фикердә, эштә берлек принцибы» бөтен төрекчелек (төркичелек) хәрәкәтен, тел, әдәбият, социология, хәтта сәясәт өлкәләрен дә, һәммәсен, һәммәсен берләштереп үз эченә ала, дип уйлыйм. Аңардан соң килгән төрекчеләр (төркичеләр) һәм «бөтен төрекчеләр (төркичеләр)» бу нигез принципларны нечкәләп тикшереп ачыклаячаклар, куәтләндерәчәкләр, камилләштерәчәкләр. Төгәл 15 еллар элек төрекчелек (төркичелек) хәрәкәте турында язган бер мәкаләмдә әйткән сүзләрне биредә дә кабатлыйм: *«Минемчә, бөтен төреклек (төркилек) теориясен иң әүвәл мәйданга чыгаручы — элеккеге Кырым ханнарының ташландык һәм онытылган, гадәттә, бүгенге дөньядан аерым һәм еракта яшәгән кечкенә башкаласында, атнага бер чыгучы кечкенә бер газета — «Тәрҗеман». «Тәрҗеман»ның нашире һәм мөхәррире Кырым мирзаларыннан — Гаспралы Исмәгыйль бәй. Исмәгыйль бәй бөтен төрек (төрки) дөньясын күз алдында тотып, аңа хезмәт итте. «Тәрҗеман» карашынча, Казан татарлары, Урта Азия сартлары, таранчылар (уйгырлар)-фәләннәр юк. Бер дингә инанган, бер телдә сөйләшкән төрекләр (төркиләр) генә бар»[1].*

Унбиш ел элек язган бу фикеремә инде бер искәрмә генә өсти алам: Исмәгыйль бәйдән элек «бөтен төреклек (төркилек)» идеясен бер система хәлендә тикшерү эше теориясен формалаштырырга тырышкан һичбер кеше булмавын тәкрар кабатлау белән бергә, бу идеяне ара-тирә, ерактан күргәндәй булганнарның да барлыгына ышандым. Алар, исемнәре югарыда телгә алынган[2], Вәфикъ паша, шәех Сөләйман әфәнде, Җәләлетдин паша кебек Көнбатыш төрекләре (төркиләре) арасында эшләгән кайбер затлар. Ләкин аларның берсе дә, Кырымлы Исмәгыйль бәй кебек, ачык рәвештә тотрыклык белән ныклы теоретик нигезгә кую эшенә керешмәгән. Кыскасы, Гаспралы Исмәгыйль бәйне мин «бөтен төрекчелек (төркичелек)» хәрәкәтенең үзәк фигурасы дип санауның дөреслегенә ышанам.

Гаспралы Исмәгыйль бәй 1914 елның 11 сентябрендә Бакчасарайда «Тәрҗеман» редакция янәшәсендәге үз өендә үпкә туберкулёзыннан 63,5 яшендә вафат итте.

Төрек теленнән
***Мәсгуд Гайнетдин** тәрҗемәсе* ■

---

[1] Й.Акчура. Төрекчелек. Бу мәкалә башта 1328/1910 елда «Салнамәи Сәрвәт-и фөнүн», соңрак, 1329/1911 елда «Төрек йорты»ның кушымта бүлеге итеп чыгарылган «Алтын әрмәган»дә басылган.
[2] Ягъни журналыбызның алдагы саннарында.

ИСМӘГЫЙЛЬ ГАСПРИНСКИЙ ВАФАТЫНА 100 ЕЛ

БӨЕК ШИГАР, ОЛУГ ИДЕАЛ *

Фатих Әмирхан

Моннан утыз ике ел әүвәл иде Гаспринский «Дилдә[1], фикердә, эшдә берлек!» дип өстенә язылган бер әләм тотып шималь төрекләренең[2] юл башына төште.

Гомуми идеаллардан мәхрүм, таркаулыкның соң дәрәҗәсенә килеп йиткән төрек[3] кабиләләреннән берсе булган без, татарлар, ул караңгы көннәрдә инде борылмаска дигән шикелле бер катгыять белән бетү юлында адымнар ата идек. Һәйәте иҗтимагыя хәлендә яшәр өчен кирәк булган бөтен мөкаддиматтән[4] хиссасыз[5], надан, фәкыйрь, идеалсыз без татарлар ул мәнхус[6] көннәрдә үземезнең кайгылы, вак, сукыр тормышымызны, шундый ук кайгылы, вак һәм сукыр үлем белән очлар өчен ашыгып-ашыгып бара идек.

— Менә шулвакытта, шул мәнхус вакытта Гаспринский чыкты. Чыкты да бөтен милләтнең барыш юлын борып йибәрер өчен бөтен көчен сарыф итте.

Бу вакытта «Ул» Гаязның бәхетсез Җәгъфәре[7] шикелле ялгыз иде.

Халык наданлыктан чери, берәнсәрән зыялылар милләтне хәкарәт[8] итеп, аңар кул селки вә аннан аерыла торган бу вакытта Гаспринский берүзе халык өчен яна, аның өчен егълый иде. Тауларны йилкәгә күтәрү кадәр авыр күренгән олуг йөкне Гаспринский үзенең миллият уты белән чыныккан йөрәге, рухы өстенә күтәреп салып, милләтне сахил[9] сәламәткә илтеп чыгарыр өчен тырыша иде.

Нинди генә бер мәтеннән[10] милләтнең тарихе тәмәддененә[11] каралмасын, анда зур даһиның ихтирам белән телгә алына торган зур исеменә очраладыр.

Безнең милләтемез өчен шул зур даһи, шул зур исем Гаспринский вә аның исемедер. Безнең бөтен хәрәкәт фикриямезнең башы аңар барып тоташа, безнең бөтен хадим милләтемезнең «тәрәкъкыят силсиләләре» аңар барып чыгадыр.

Шималь төрекләре бу көннәрдә башка төрек кабиләләре шикелле үк үзләренең истикъбальләре[12] өчен иде-

* Олуг мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспринский вафатына ошбу елның 11 (24) сентябрендә 100 ел тула. Аның вафат булу хәбәре татар җәмәгатьчелеген зур кайгыга сала, шул уңайдан «Вакыт», «Йолдыз», «Кояш» газеталарында, «Аң», «Шура», «Мәктәп» кебек журналларда мәкаләләр циклы, кайгынамәләр басыла. Фатих Әмирханның әлеге мәкаләсе «Кояш» газетасының 14 сентябрь (№ 509) санында дөнья күргән. Мәкалә Ф.Әмирханның 1958, 1989 елларда басылган сайланма әсәрләренә, И.Гаспралының 2006 елда «Җыен» нәшрияты чыгарган тарихи-документаль җыентыгына кертелмәгән.

[1] Дилдә — телдә.
[2] Шималь төрекләре — биредә татарлар күз алдында тотыла.
[3] Төрек — төрки дип укырга.
[4] Мөкаддимат — башлангыч.
[5] Хисса — өлеш.
[6] Мәнхус — шомлы.
[7] Гаязның бәхетсез Җәгъфәре — Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренең төп герое.
[8] Хәкарәт итеп — хурлап.
[9] Сахил — диңгез кырые, яры.
[10] Мәтен — китапның тексты.
[11] Тарихе тәмәддененә — мәдәниятле булу тарихына.

ал тәгъкыйб итүдән[13] түбән торалар иде. Милләтләрнең бөтенлеге аннан башка мөмкин булмаган шул идеалны мөҗмәл[14] сурәттә бөтен төрек галәме өчен Гаспринский сузып бирде.

Гаспринский үзенең бик ерактан күрә ала торган бәсыйрәте[15] белән милләтне өстери торган юлының кайда илтеп чыгарырга мөмкин икәнен бик дөрест күреп килә вә шуңар күрә үзе алып бара торган юлның бердәнбер тугры юл икәненә бөтен вөҗүде[16] белән иман итеп, бөтен гомере буенча инде шул иманының ялкыны белән армый-талмый хезмәт итә. Аның бөтен гомерендә без бер минут кына булсын тәрәддедкә[17] төшкәнен күрмимез, аның бөтен юлында, бөтен барышында без кечкенә генә дә боргалану тапмыймыз. Ул үзенең шул кырык елга якынлык хезмәтен гаҗәеп бер ышаныч вә гаҗәеп бер катгыять белән алып бара.

— Бәхетле мондый каһарман!

Фикерләрнең сикеренгән дәверләрендә, гакылларның ыргытылган идеал эзләп йөдәгән елларында Гаспринскийда бу сикеренү, бу эзләнүне без күрмибез. Ул әүвәл аяк баскан юлы белән туп-тугры бара, яшьлегеннән ясаган идеалы белән үзенең озак гомере буенча аерылышмый, милләтне ул бервакытта да әле бер якка, әле икенче якка өстерәп йөдәтми, бәлки һаман бер якка гына өстери. Мондый ачык аң, мондый нык мәсләк горфи[18] адәмнәргә түгел, бәлки зур талантларның да бик күбесенә мөяссәр булмыйдыр.

— Олуг мондый сахибе фикер[19]!

Гасприский нинди нәрсәгә эш башласа, нинди нәрсәгә тәшәббес итсә[20], шул эштә вә шул тәшәббестә без бер бәрәкәт вә бер ныклык күрәмез. Шул эштә вә шул тәшәббестә без, вакытындамы яхуд бераз соңракмы, зур бер хикмәт, зур бер мантыйкыйлык табамыз.

Милләт Гаспринскийны кырык елдан бирле инде күреп килә. Менә шул кырык еллык күрү нәтиҗәсе буларак, ул инде гаҗәиб бер ышаныч белән аңар ышанган, Гаспринский артыннан һәр кая барырга мөмкин икәнлегенә иман иткән иде.

Милләтнең фикри барышы фортналарга[21] очрап, әле анда, әле монда борылырга хазир торган вакытларда Гаспринский милли корабның баһадир капитаны иде. Ул рухани куәтле куллары белән милләтне, дилдә, фикердә, эштә берлек юлыннан инхираф иттерми[22], итә башласа, тагы юлга төшереп алып барырга бөтен көчен сарыф итә вә муаффәкътә[23] була иде. Аның шул кабилияте, аны табигый сурәттә, милләтнең юлбашчысы ясады.

— Юлбашчылары шулай гына булырга тиешләр!

Милләт башта аны икърар итмәгән, хәтта аңар ачуланган, аннан соң аның фикри, рухи куәтенә каршы тора алмыйча, аңар ияргән.

— Хаклык, рухани куәт һәрвакыт өсткә чыга!

Гаспринский вафат итте, ләкин аның төрек галәме өчен күрсәтеп киткән юлы, сызып куйган планы, тутырып калдырган идеалы, дилдә, фикердә, эштә берлек идеалы — болар калдылар, ныгып, тамырлар җәеп калдылар. Болар инде үлмәсләр вә үзләре белән бергә хөрмәтле юлбашчының хөрмәтле хатирәсендә мәңгегә калырлар.

Гаспринскийның кабере өстендә эчеләчәк бер ант, биреләчәк бер вәгъдә булса, ул да аның юлына хыянәт итмәскә, ул игълян иткән шигаргә вафасызлык[24] кыйлмаска биреләчәк вәгъдәдер.

Текстны һәм искәрмәләрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

---

[12] Истикъбальләре — киләчәкләре.
[13] Тәгъкыйб итү — эзләү.
[14] Мөҗмәл — гомуми.
[15] Бәсыйрәт — аң.
[16] Вөҗүде — барлыгы.
[17] Тәрәддед — икеләнү, бер карарга килми тору.
[18] Горфи — гади.
[19] Сахибе фикер — фикер иясе.
[20] Тәшәббес итсә — керешсә.
[21] Фортналарга — форт, ныгытма.
[22] Инхираф иттерми - тайпылдырмый.
[23] Муаффәкъ — эше барып чыккан.
[24] Вафасызлык — тугрысызлык.

АЙШӘ ХАНЫМ

Усеин Болатуков

(Өч пәрдәлек пьеса)

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Морза өе. Мөхәммәт морзаның бүлмәсе. Бүлмәнең ике ягында топчаннар. Ишек янында өстәл. Өстәл өстендә – китаплар, карточкалар, кара савыты, каләм. Өстәл янәшәсендәге этажеркада китаплар.

Мөхәммәт морза *(топчан өстендә утырып, бер төрек китабы укый. Янында утырган Айшә ханым белән Али морза тыңлый).*

Шигырьне тыярга!
Беркемгә шигырь яздырмаска!
Бу милләткә җан өрүче
бер битне дә бастырмаска!
Вәхшилекне бетерер өчен
һәр мәктәпне яптырырга!
Булган акчаларга мәчетләрне
буятырга!

Айшә ханым *(Мөхәммәт морзаның муенына кулын куеп).* Һа-а-й, ул җиреннән тагын бер укычы, агам!

Мөхәммәт морза *(укый).*

Шигырьне тыярга!
Шулай булсын.
Шигырь яздырмаска!
Бу милләткә җан өрүче
бер битне дә бастырмаска!
Кыргыйлык бетсен өчен
һәр мәктәпне ябарга.
Булган акчаларыгызга
мәчетләрне буятырга.

Айшә ханым. Ничек язганнар, ә!

Мөхәммәт морза. Ошыймы, ә?

Айшә ханым. Әлбәттә, ошый!

Мөхәммәт морза *(Али морзага).* Ә сиңа?

Али морза. Миңамы? Әлбәттә, ошый. Нәрсә дигән сүз ул: «Мәчетләрне буятырга»?

Айшә ханым. Бала түгелме, ә? Бер дә акылы юк инде.

Али морза. Ни булган минем акылга? Синеке кадәр дә юкмы әллә?

Мөхәммәт морза *(Айшә ханымга).* Обижать итмә шуны, ул әле бала гына, аның күп нәрсәдән хәбәре юк.

Али морза. Минем күп нәрсәдән хәбәрем бар.

Мөхәммәт морза. Посмотрим, нидән хәбәрең бар икән?

Али морза. Җәннәт, җәһәннәм бар, сират күпере бар. Намаз укыган, ата-ана сүзен тыңлаганнар сират күперен яшен тизлегендә үтеп китәр һәм җәннәт почмагына төшәр. Менә барысыннан хәбәрем бар.

Айшә ханым *(көлемсерәп).* Тагын нидән хәбәрең бар?

Али морза *(мыскыллап).* Ашыровка гашыйк булдың, анысын да беләм. Сине аңа бирмәячәкләр, аннан да хәбәрем бар. Тәһарәт алганда аякларыңны юарга иренәсең, анысын да беләм.

Ахыры. Башы журналның 7 нче санында.

Мөхәммәт морза *(Али морзаның аркасыннан кагып).* Молодец, энекәш! Син белмәгән нәрсә юк, син бөтенесен беләсең. *(Торып, китабын этажерка өстенә куя һәм урынына килеп утыра.)* Һәммәсен дә беләсең, һәммәсен дә?

Али морза. Әлбәттә, барысын да беләм.

Мөхәммәт морза. Великолепно! Мине дә тыңла бераз.

Али морза. Синеме? Ни әйтәсең? Әйт, карарбыз.

Мөхәммәт морза. Тыңла, энем. Рай...

Али морза. «Рай» ни дигән сүз ул? Ни әйткәнеңне аңламадым.

Мөхәммәт морза. Да, җәннәт ул шулар өчен, кем үзенең народын сөяр.

Али морза. «Народ» дигәнең нәрсә инде?

Айшә ханым. «Милләт», димәк.

Али морза. Ә «милләт» дигәнең нәрсә?

Айшә ханым. Барлык казакларны «бер милләт» диләр. Без мөселманнарга да «бер милләт» диләр.

Мөхәммәт морза. Тыңла дальше. Җәннәт ул шулар өчен, кем хаким дине өчен җан бирер, җәннәткә раньше всех ул керер, хаким исә, «бу татар, бу морза» дип аермас. Җәһәннәм, энекәем, ул шулар өчен, кем үз милләтенә бер польза китермәс, ярлыларны, көчсезләрне обижать итәр.

Али морза *(Айшә ханымга).* Шулаймы?

Айшә ханым. Әлбәттә, шулай. Мәрхәмәтсез кеше сиксән ел намаз кылса да, җәннәткә кермәс. Начар, көнчел кеше йөз тапкыр хаҗга барса да, җәһәннәмнән чыкмас, фетнәче мең ел ураза тотса да, сират күперен кичмәс. Моны акылыңа сеңдер, онытма!

Али морза. Ә менә эти-әни алай дими. «Безнең сүздән йөрсәң, аннан соң җәннәткә керерсең», диләр.

Ханым *(килеп кергәч).* Аһ, үземнең пар күгәрченнәрем! *(Мөхәммәт морза белән Али морзаны үбә.)* Мин сезне шундый яратам!

Али морза. Ә Айшә апаны сөймисезмени?

Ханым. Мин өчегезне дә бик яратам, балаларым. Тоткан туфрагыгыз алтынга әйләнсен!

Али морза *(чәчәк савытыннан туфрак алып).* Алтын түгел лә, әнием. Догагызны Аллаһ кабул итмәде.

Айшә ханым *(Али морзаның битеннән үбеп).* Шаян, наян син, минем кардәшем.

Али морза *(калтыранып).* Мин шаянмы? Шаян адәм кеше көлдерер.

Морза *(кочагына песи күтәреп эчкә үтә).* Сез монда икәнсез. *(Мөхәммәт морзаның тырнак кискәнен күреп.)* Хатын, бүген нинди көн?

Ханым. Сишәмбе булса кирәк.

Морза *(Али морзага).* Кил, улым, борын очыңнан үбим. *(Али морзаның кулыннан тотып топчанга барып утыра. Али морзаның битеннән үбә.)* Бар, алып килче сары тышлы китапны.

Али морза *(назланып).* Бездә сары тышлы китап меңнән артык, кайсысын китерим?

Айшә ханым. Мин беләм. Алып килимме? *(Чабып китә. Китапны алып килеп этисенә бирә. Мөхәммәт морза, этисенә карап, кайчысын урынына куя.)*

Морза *(китапны караштырганнан соң, Мөхәммәт морзага биреп).* Мә, укычы шушы җирдән!

Мөхәммәт морза *(укый).* Тырнак кисү һәм чәч алу, сакал-мыек кыру өчен тиеш көн — җомга ул.

Морза. Тагын бер кат укы.

Мөхәммәт морза Тырнак кисү вә сакал-мыек кыру өчен тиеш булган көн — җомга.

Морза *(күзләрен акайтып).* Кердеме колагыңа? Әллә бер колагыңнан кереп, икенчесеннән чыктымы?

Мөхәммәт морза *(көлемсерәп).* Берсенә генә түгел, икесенә дә керде.

Ханым *(мыскыллап).* Бүген керер, иртәгә чыгар. *(Мөхәммәт морзаның маңгаеннан үбә.)*

Мөхәммәт морза. Сомневаться

итмә, әнием, навеки калыр колагымда.

Ханым. Ярый, карарбыз. *(Песине күреп.)* Кем килер икән? Күрәсезме, мәче битен юа?

Али морза. Мәче каян белә кунак киләчәген? Үзегез: «Алдагыны Аллаһ кына белә», дисез.

Ханым. Әлбәттә, белми. Ләкин, Аллаһ мәчегә белдерә, ә мәче — безгә.

Мөхәммәт морза. Яңа филин. Странно. Сезнең әйтүегез буенча, Аллаһ хайванны кешедән выше күрә. Мондый эш буламы?

Морза. Монда странный-мыстранный эш юк. Синең кебек имансыз татар егетләре, әлбәттә, хайваннан түбәнрәк.

Мөхәммәт морза *(сикереп торып).* Әти, башта син шунысын әйт, ни өчен син мине түбәнсетәсең? Мин сиңа үксез баламы әллә? Әйтеп бир! Ни өчен мине хайваннан түбән күрәсең? Ни өчен фанатизм кысасыннан чыга алмыйсың? Ни өчен татарларны пычракка салып таптыйсың, ә морзаларны күккә чөясең? Кеше булу өчен башта акыл кирәк. Әгәр башы булмаса, ни файда морзадан?...

Али морза. Менә сиңа яңа хәбәр! Башсыз кеше буламы? Сиңа бирәр нәрсә булганмы, агам, акылың башыңдамы?

Айшә ханым. Син әле бала гына, тыгылма һәр эшкә. Карале, кара! Адәм булдым дип, бу да сүзгә кысыла.

Морза *(еламсырап).* Кара әле, карчык! Әйт әле, кем чыгар бу буыннан? Мондый тәкъдирне сорадыммыни мин Тәңредән?

Мөхәммәт морза. Жалею, что сорый белмәгәнсең, атакаем. Синең мондый булганың миңа кызганыч.

Айшә ханым. Барысын да белү мөмкин түгел бер кешегә. Сораганда да осталык кирәк.

Ханым. Кычкырма син, акылсыз! Кычкырма, ахмак! Бөртек кадәр дә акылың юк бит башыңда.

Айшә ханым. Әгәр укыткан булсагыз, булыр иде, бәлки. Шулай да кайберләрдән акылым ким түгел.

Морза *(сикереп торып).* Белмисеңмени, ишәк, мин дингә каршы бармаганны? Казакча уку-язу, хәтта, татарча язу да үзе бер гөнаһ. Кызлар эше түгел ул.

Айшә ханым. Шундый эш буламы? Ни өчен безгә уку-язу гөнаһ булсын?

Морза. Күп сөйләнмә! Ата-ана әйткән һәр нәрсә фарыздыр, мәҗбүридер.

Айшә ханым. Ата-ана Аллаһмы?

Фатма *(килеп кереп).* Кунак килде!

Өлкәннәр *(икесе бергә).* Әлбәттә, әлбәттә. *(Чыгып китәләр.)*

Айшә ханым. Кызык, кем икән ул?

Али морза. Тукта, мин барып карыйм. *(Чыгып китә.)*

Мөхәммәт морза. Может быть, сине яучыларга килгәннәрдер?

Айшә ханым. Бәлки, шулайдыр, җаным. Язмышым шулардан тора.

Мөхәммәт морза. Ә ни өчен?

Айшә ханым. Атна саен бер-ике җирдән яучы килә.

Мөхәммәт морза. Ни өчен никахламыйлар? Сорамадыңмы?

Айшә ханым. Минем теләгемне искә алмаячаклар. Үгез, ат, болын саткан кебек сатып җибәрәчәкләр. Әмма әлегә берсен дә ошатмыйлар.

Мөхәммәт морза. Беләсеңме, Айшә, мин динебезне, татарлыгымны, гореф-гадәтләрне бик ихтирам итә идем. Ләкин моның кебек дикий гадәтләрне — хакимлекне, татарларны мәсхәрә итүне бөтенләй сөймим, боже мой! Кайчан татарлык кешелек рәтенә менәр, күрерменме шул көннәрне? Кайчан татар уяныр, йокылык царствосыннан чыгар? Айшә, бу безнең морза халкында бер начар гадәт бар, татарларны, кендек кардәшләрне кеше урынына куймау, минемчә, акылсызлык, не правда ли?

Айшә ханым. Әлбәттә, шулай. Әнине ал, әтине ал. Соң мондый тормыш буламы?

Мөхәммәт морза. Мондый наданлыкны мин переварить итә алмыйм. Бер уч мөселман Кырымда сиксән төргә бүленгән. Бер төрлесе «мин морза», дип чыкса, икенчесе «мин духовный», ди. Соң шундый жалкий положениедән ничек янып үлмибез, ә? Раббым, кайчан без Кырымда берләшә алырбыз? Кайчан

безнең яшьләр, кызлар укый башлар? Морзалар корыга укый. Гимназиягә кереп, бер класста ун ел утыра да, аны бетергәч, «мин интеллигент» дип, эт куып йөриләр. Правду сказать, безнең ханий кызларыбызга да исем-акылым китә. Слава богу, гимназия бетергән ханийларыбыз бар. Тик ни файда? Мәхәббәт турындагы романнар укып, любовный письмолар язудан башка, һичбер эш белмиләр. Кызларыгызны караңгылыктан чыгарга булышыгыз, дисәң, «минем кызым зур инде, борчылмагыз», диләр. Йә тагын: «Сала кызларын укытсаң — башсызланырлар», — дип тә куялар. Соң, шулай буламыни? Яшьләребезне алыйк. Модисткалар артыннан ухаживать итүдән башка, берәр эш беләләрме? Дворян молодёжы арасында милләтне кайгыртканнар бик аз. Валлаһи, бер уйлап карасаң, тәүбә кылучы морза малае түгелме соң мин?.. Айшә, мин сиңа күрсәтмәдемме иптәшем язган стихотворениене?

Айшә ханым. Юк, күрсәтче!

Мөхәммәт морза *(китапларын караштыра башлый да, бер китап эченнән бер табак кәгазь табып алып, урынына килеп утыра).* Менә, көчкә таптым. Тыңла. Ошармы? *(Укый.)*

Йөрәккәем, чыр-чыр яна
Әгәр төшсә исемә.
Туфраклар чәчелә кулдан,
Кем адашкан Кырымда?!
Кая китте бабайларым
Ат уйнаткан вакыт?
Кая китте, бабайларым,
Сез утырган тәхет?
Уян, татар, уян син!
Ач бер тапкыр күзеңне —
Шушы сазлык эченнән
Алып чык син үзеңне!

Яхшы язган, ә?

Айшә ханым. Әлбәттә, әйбәт язылган. Кем язды аны?

Мөхәммәт морза *(көлемсерәп).* Ашыров язды, аның поэтически таланты бар.

Айшә ханым. Шигырьләре күпме?

Мөхәммәт морза. Уничтожить итте.

Айшә ханым. Ни өчен?

Мөхәммәт морза. Егетнең таланты напрасно пропадать итте... Язган шигырьләрен булыр-булмас кешеләргә күрсәтүе сәбәпле, барысын югалтты.

Айшә ханым. Дөресен әйткәндә, мин сине аңламыйм.

Мөхәммәт морза. Аңламаска монда бер трудный эш юк. Безнең татар интеллигенциясе берәр нәрсә «йор»сыз язылганны ошатмый, аны эш рәтенә куймый. Аның кебек язарга кирәк, укыган кеше аңламаслык итеп, ягъни яртысы гарәпчә, яртысы фарсыча булсын. Менә нәрсәгә безнең интеллигенция стремится. Боже мой, кайчан безнең китаплар, газеталар чиста ана телендә язылыр? Күрербезме икән шул көннәрне?

Али морза *(килеп кереп).* Миңа сөенче!

Айшә ханым. Йә, кем бар?

Али морза. Ни бирәсең? Әйтәм.

Айшә ханым. Нәрсә телисең, шуны. Әйтче, энекәем!

Али морза. Сине кодаларга килделәр. Әкрен генә ишек артыннан тыңладым, сине бер тол ногайга никахлаячаклар. Хәсән морза исемле.

Айшә ханым. Ю-ю-ю-к! Ялганлыйсың! *(Али морзаның кулыннан тотып.)* Дөресен әйт инде, энем!

Али морза. Ышанмасаң, ышанма. Мин ялвармыйм.

Фатма *(килеп кереп).* Котлыйм сине, ханым. Сезгә яучылар килде.

Али морза. Менә, ышанмаган идең?

Айшә ханым. Яучымы? Каф тавы артына олаксын! Хәсән морзага да ләгънәт яусын. Туганнарым, аның белән мин ничек яшәрмен? Раббым, ни өчен син миңа шулкадәр мәрхәмәтсез?

Али морза. Апаем, син ни өчен елыйсың? Булмаган эш белән ник йөрәгеңне газаплыйсың?

Мөхәммәт морза *(Айшә ханымның кулыннан тотып).* Айшә, нигә елыйсың? Сөйлә миңа причинасын.

Али морза *(кодалар булган өйне рәшәткә аркылы күзәтә, ә Айшә ханым елавын дәвам итә).* Күрәсеңме, күрәсеңме? Барасың килмимени сиксән яшьлек надан һәм тол морзага?

Мөхәммәт морза. Ә син каян беләсең надан һәм тол булганын?

Айшә ханым. Үзе тол, үзе надан, һич килешәчәк түгелмен!

Али морза. Агай, әйдә шаяртыйк әтине. Фатманы никахлаштырсыннар. Барсын Хәсән морзага һәм яшәсеннәр рәхәтләнеп!

Фатма *(башын чайкап).* Юк, морзам! Мин — татар кызы. Хәсән морза алмаячак мине.

Айшә ханым *(күз яшьләрен сөртеп).* Әти-әни сатканнардыр гомеремне!

Али морза. Күңелеңне төшермә син, апаем, әтигә әйтермен, синең кебек чибәр, булдыклы кызны бирмәсен шул адәмгә.

Мөхәммәт морза. Якыным минем, якыным. Сине бирмәм Хәсәнгә! Теләмичә өйләнешүдән бәхетсезлек юктыр кеше өчен.

Айшә ханым. Ни өчен тудым мин, ә? Раббым, миңа рәхәт яшәү өчен мондый хәрам дөньяга... кирәкме сатылырга?

Али морза *(Айшә ханымны кочаклап).* Елама син, туганым! Сөрт күзеңдәге яшьләрне! Мин сөйләрмен апай...

Фатма *(тынычландырырга тырышып).* Хафаланмагыз, ханым. Әлегә бернинди эш юк. Кунаклар биредә, әлегә китмиләр.

Али морза *(Айшә ханымның каршысына килеп).* Синең урыныңда булсам, йөземне күрсәтмичә барыр идем өенә. «Син болайсың, син тегеләйсең», дип әйтсә, бирер идем йодрык белән шул ногайның күзенә!

Айшә ханы *(көлемсерәп).* Мин сине бик яратам, чын күңелемнән сөям, энекәем! Тыңла, исеңдә калдыр, бер васыять әйтәм, һичбер вакыт әйтмә син: «Бу морза, ул татар, бу ногай!» дип. Һәммәсенә игътибарлы бул.

Али морза Менә сиңа яңа закон! Ник татарны санлаем? Әти-әни юлыннан нигә чыгарга?

Мөхәммәт морза *(Али морзаның кулыннан тотып).* Әйдә, барып ялварыйк әнигә. *(Али морза белән чыгып китә.)*

Айшә ханым *(бераз уйлап торганнан соң, Фатмага карап).* Аллаһ нигә кулларыбызны бәйләде икән? Бу нәрсә була инде: синең теләгең белән исәпләшмичә, сине кияүгә бирсеннәр ди.

Фатма. Сез ни өчен борчыласыз, ханым? Бәлки әле Сезне аңа бирмәсләр.

Айшә ханым. Ю-ю-ю-к, Фатма! Җаным сизә. Әни дә, әти дә Хәсән морзаны беләләр. Хәсән морза кебек кияү бу заманда йә табылыр, йә табылмас, диләр.

Фатма. Әни, әти беләләр икән, шуннан нәрсә? Алайса ни өчен барырга теләмисез? Юкса ямьсезме, йә бик фәкыйрьме?

Айшә ханым. Ямьсез дә түгел, ярлы да түгел, әмма *(тавышын әкренәйтеп)* Мөхәммәт агамның иптәше чибәр дә, акыллы да түгелме? Дүртбиш тапкыр килде безгә, бары яхшы кичерешләр калдырды күңелдә.

Фатма. Чибәр, әмма әниегез аны ярлы һәм җәмәгать укыта, дигән шикелле.

Айшә ханым. Ярлысын — ярлы, халыкны бушлай укыта, ләкин Хәсән морза кебек тол түгел, надан да түгел.

Фатма. Һәм татар түгелме?

Айшә ханым. Татар булса, ни? Татарлар мөселман түгелме?

Фатма. Шулаен шулай, әмма әтиәниең риза булырмы? Мин үзем Хәсән морзага барыр идем. Җаным рәхәттә яшәсә, ни пычагыма аптырарга аның тол һәм надан булуына.

Айшә ханым. Син шулай уйлыйсың? Минем өчен сукыр бер тиенлек андый гомер. Ир була торып, һич югында русча бер хат та яза белмәү кимчелек түгелме? Ишәк кебек бер кәгазь дә укый белмәсә, ничек «ирем бар!», диярсең дә, аның белән гомер итәрсең?!

Фатма. Ә сез беләсез бит! Сез укырсыз, сез язарсыз. Кодачагызга да ярдәм итмәячәксезмени? Теләсәгез, әкрен-әкрен аны да укырга өйрәтерсез.

Айшә ханым. Минме? Аллаһ сакласын! Ни эшләрмен андый күзле бүкән белән, ә? Укый-яза белмәгән ир-ат — күзле бүкәндер, хатыны — чүпрәктер!

Али морза *(килеп кереп).* Һич бу-

лачак эш түгел! Сине никахлаштырачаклар. Әти дә, әни дә безне шелтәләде. Әти бөтенләй куркытты. Әтинең күзләре кызарган: «Мин һәммәгезне кылдан үткәрәм! Минем нәселнең киләчәге булыр, сүземне тотам, киләчәге булыр, бер дә шөбһәләнмәгез!» — ди.

Айшә ханым. Кайда кодалар?

Али морза. Алар утыралар. Икебез дә алар алдында көлкегә калдык. Бер мәкерлесе миңа карап: «Сез нинди тәртипсез балалар», — ди.

Айшә ханым. Ә Мөхәммәт агам кайда?

Али морза *(әкрен генә).* Ишетмисезме? Бәхәсләшеп калды. «Минем исемем Мөхәммәт булганда, Айшә Хәсән морзага бармаячак! Атыгыз, үтерегез, миңа барыбер, тик мондый ахмаклыкны күзем күрмәсен», — ди.

Айшә ханым *(еламсырап).* Ах, минем абыем! *(Фатмага карап.)* Бар, чакыр. Кирәкми, минем өчен тавыш чыгармасын. *(Фатма торып китә. Айшә елый.)*

Нинди кара язмыш язылган икән бу башкаема?!

Али морза *(кулларын төкреклә п).* Апаем, китер, шул кара язмышны куып җибәрим. *(Айшә ханымның башын кочаклап, учы белән маңгаен сыйпый.)* Күтәр башыңны, болай елама. Әтиәнидән башка чыкмассың.

Айшә ханым *(яшьләрен сөртә, елмая).* Башка чыгылмас, әмма ни эшләрем? Җаным сөйми бит.

Али морза. Сөясеңме-сөймисеңме, ахырында барыбер бер хәсискә барачаксың, ә?! Шулай булгач, нигә кирәк бу кадәр кайгырырга, ә?

Айшә ханым. Хәсиснең дә хәсистән аермасы бар, энекәем.

Али морза. Алай булса, син барып кайт Хәсән морзага, әгәр аны ошатмасаң, икенчегә барырсың, анысын да ошатмасаң, башкасына барырсың, зур эшмени? *(Айшә ханымның чәчләре белән уйнап, әкрен генә бер җыр көйли.)*

Айшә ханым *(көлемсерәп, күз яшьләрен сөртеп, бераз башын аска иеп утыра да, аннан башын калкытып).* Гаҗәеп эш, моңа һич акылым җитми.

Ни өчен мондый гадәтләр
үзебездән күтәрелми?
Һәркем күрергә тели
ахрызаман дәгъвасын,
Ләкин бер дә күренми
шул дәгъваның файдасы.
Безнең милләт айнымаячак,
айнымаячак кайчан да!
Ахырзаман гына түгел,
кыямәт көне купса да.
Ата-ана үз кызларын
хайваннар кебек сата.
Татар, морза бер-берсенә
тирән чокырлар казый.
Бер укымышлы затлар
безне каргадай күрә.
«Казак булган! Ак карга!» —
дип, аннан соң бездән көлә.
(Али морзаның кулыннан тотып).
Син яшь егет, син яшь әле,
Чынлап сөям, туганым,
Тыңла мине, ничек булса да,
Үтә минем догамны,
Әти-әни сүзе белән өйләнмә
юк кешегә!
Кемне җаның сөя, шуны ал,
һич карама нәселенә.
Көчләп өйләндергәннәрнең
җаннары күп кимерелде,
Соңыннан ата-аналар тәүбә итте,
үкенде.
Кичен-көндез тырыш син
иске дөньяны егарга,
Бу наданлык зинданыннан
кызларны алып чыгарга!
Исемең синең мәңге калыр,
Һәрбер җирдә балкыр ул.
Сиңа милләт рәхмәт укыр,
Һәм эшеңне алкышлар!

Али морза. *(йодрыгын югары күтәреп).* Алырмын мин кылыч, зур булгач. Татарлардан беренче булып мин бөтен иске дөньяны җимерермен!

Пәрдә төшә.

24 гыйнвар-5 июнь, 1916 ел.
Кырым татар теленнән
***Нурулла Гаптуллин** тәрҗемәсе* ■

ЯҢА ЧОР ҮЗБӘК ШИГЪРИЯТЕ ЧУЛПАНЫ

Рәдиф Гаташ

Егерменче гасырның беренче чирегендә үзбәк әдәбиятында чын мәгънәсендә таң йолдызы булып балкыган, аның үсешендә зур, мөһим роль башкарган шагыйрьләрнең берсе – Чулпандыр.

Шагыйрь булуы өстенә ул – «Төн һәм көн» исемле роман, хикәяләр язган прозаик; шактый пьесалар язып, Үзбәк милли театрларында куйдырган, шулай ук Гоцци, Шекспир кебек дөнья әдипләренең әсәрләрен («Принцесса Турандот», «Һамлет» һ.б.) тәрҗемә итеп, сәхнәдә яшәү биргән драматург, журналист, публицист, педагог... – кыскасы,

Бату, Наим Сәед һәм Чулпан. Мәскәү, 20 нче еллар

1917 елдагы түнтәрелештән соңгы эзләнүле, элекке кадими тормыштан яңа чорга күчү авырлыкларын, каршылыкларын иҗатында ачык чагылдырган егерменче гасыр әдәбияты башының зыялы төркиләр улы. Чын исеме Габделхәмит Сөләйман улы булган (Чулпан — аның тәхәллүсе. Тагын — «Каләндәр» (дәрвиш-сәяхәтче), «Мирзакаләндәр», «Андиҗанлы» имзалары белән дә язган) шагыйрь 1897 елда Андиҗанда сәүдәгәр гаиләсендә туган. Атасы Сөләйман да шигырьләр язган, фарсы һәм үзбәк төркичәсендә язганыннан һәм үзе яраткан Иран шагыйрьләреннән кульъязма диван да төзегән. Алга китеп әйтик: егерменче елларда улы Чулпан Мәскәүдә яшәп, андагы үзбәк театры студиясендә туган тел һәм әдәбият укыткан чорында атасы аңа хатларны шигырь (газәл, касыйдә) белән яза торган була. Менә нинди мохит!

Әхмәтзәки Вәлиди 1914 елда борынгы мәдәни мирасыбызны (уртак әдәби ядкярләрне дә!) эзләп, фәнни командировкада булганда Ташкент, Андиҗан, Бохара шәһәрләрендә үзбәк зыялылары: Мәхмүдхуҗа Бәһбүди, Васли, М.Карый һ.б. алдынгы мәдәният әһелләре белән таныша. Шул сәфәрендә Андиҗанда әле 15-16 яшьлек шагыйрь Чулпан һәм аның әтисе Сөләйман белән очраша. Үзен укып, ишетеп белгән яшь Чулпан «яшь тарихчы карт Зәки»не (Бабич сүзе) кунакка чакыра. Атасы бу турыда белмәгән икән, улын ачулана, шулай да кунакны табынга дәшә, әңгәмәләшә. Ә Чулпан бер иптәше белән гел сөйләшеп утыра икән — әтисе аны тагын ачулана башлагач, Ә.Вәлиди Мәүләнә Румидан шундый мисал китерә (фарсыча): *«Сандугач бик матур сайраучы кош. Әмма ул сайраганда башка кошлар да тынып тормыйлар...»* — ди. Бу хуҗага ошый, ул йомшара.

Ә бит бәләкәйдән шул ук Руми, Сәгъди, Хафизларны, төрек шагыйрьләрен, безнең Тукайны бик яратып, аларның «җырына» никадәр мөкиббән булса да, Чулпан үзе дә «сайрый», «җырлый», тавышын ныгыта бара — нәтиҗәдә төрки халыкларның уртак горурлыгы — чын шагыйрь булып үсеп җитә. Шулай: асыл кошлар да, шагыйрьләр дә үз тыңлаучысын таба! Һәм Әхмәдзәки белән дуслыгы дәвам итә: Вәлиди Оренбурда, соңрак Саранскида, Эстәрлетамакта Башкорт хөкүмәтен җитәкләгәндә, беркадәр вакыт янына үзбәк дуслары да килеп, Башкортстанда яшәп ала: мәсәлән, Чулпан аның шәхси секретаре дә булып тора. Соңрак Ә.Вәлиди Төркестан азатлыгы өчен милли көрәшкә кушылып, анда узган елларында да еш аралашалар, конспирация өчен Вәлидинең аны кабул итмәгән чаклары да була (шагыйрь бит, хискә бирелеп, берәрсенә яшеренгән урынын әйтер, янәсе. Чынлап та, Мәскәүдән килгән күренекле галим, Вәлидинең танышы Самойлович аны нәкъ Чулпан аша табып, күрешергә уйлый. Сак Вәлиди, шикләнеп, аны кабул итми. Саф күңелле олуг шагыйрьгә тирән ихтирамда булса да!). Чөнки Мәскәүнең кулы аны ничек эзләп, кайда, кемнәр аша сузылачагын да яхшы чамалый... 1937 елда кулга алынгач, Чулпанга бу еллардагы очрашуларын, «сәяхәтләр»ен дә исенә бер генә төшермәгәндер тикшерүчеләр.

Шунысы кызык: үзбәктә дә, казахта да тикшерүче (следователь, «Чаткылар»ны хәтерлә!..) сүзе — тиргәүче икән. Уйланырсың... Тиргәгәннәр! Үзбәкстан төзелеп, Төркестан халыклары төрле ил-өлкәләр булып бүленгәч тә, Чулпан элекке дусларын онытмагандыр, әлбәттә. Егерменче елларда Чулпанга — «ярлылар шагыйре түгел», дип, сыйнфый позициядән торып, ун елга якын матбугат аша һөҗүм бара. Шагыйрьнең иң нык иҗади үсеше чоры бу, югыйсә, Мәскәүдә дә, Ташкентта да дуслары, иҗади энеләре күп. Әйтик, Г.Голәм, Айбек, Х.Галимҗан, Уйгун кебекләр. Алар үзләренә остаз санаган шагыйрьне яклап та карыйлар,

ләкин аларны бик тиз «хаталарын танырга» мәҗбүр итәләр. Махсус әдәби «суд»лар, аның иҗаты турында партияле чыгышлар, аннан — карарлар да була. Нәтиҗәдә, 1937 елда кулга алынган шагыйрь 1938 елда атып үтерелә һәм… 1990 елларга кадәр исеме үк онытылуга дучар ителә. Оныта алдылар микән? Шундый шагыйрьне? Элекке үзбәк әдәбияты традицияләрен иң яңа әдәби алымнар белән кушып, чор үзгәрешләре музыкасын, сөйләү, җиткерүдә үз стилен, гадилегендә үк үтемле шигъриятен тудыра алган Чулпанны!

1991 елда Ташкентта Г.Голәм исемендәге нәшриятта (үз шәкертенең исемен йөрткән андый басмаханә буласын күзаллады микән дәрвиш рухлы шагыйрь?!) «Янә алдым сазымны» исемле китабы дөнья күрә: роман, пьеса, шигырьләр… Ниһаять! Ә.Вәлиди «Хатирәләр»ен укыгач та хәтеремә сеңеп калган Чулпан исеме, иҗаты китап булып та кулыма иреште — озак эзләп, таныш үзбәкләр аша кайтарттым. Ул арада 2009 елның апрель аенда алман галиме М.Фридерихның «Казан утлары»нда Дәрдмәнд турындагы мәкаләсе дә (И.Гыйләҗев тәрҗемәсе) басылып чыкты, чит ил галименең ул чор әдәби галәмендә «аңа тиң итеп Чулпанны гына кую мөмкин», дип язуы мине тагын да ныграк кызыксындырды. Җитмәсә, табигать һәм мәңгелек темасын, яшәешнең үзенчә шигъри моделен тудыруда ул аларга остаз итеп, У.Уитмен һәм Р.Тагор исемнәрен китерә — нәтиҗәдә, Дәрдмәнд һәм Чулпанны бик югары бәяли. Бу да Чулпан китабын эзләүгә этәрде. Һәм менә алга алдым, өйрәнә башладым. Беренче күзем тукталган шигырь — «Шәрык нуры»*. Мулланур Вахитовка, аның үлеменә багышланган күләмле мәрсия. Ул мине тетрәтте: без үз революционерыбызны оныта язып, ул коммунист, халкын аңламагандыр дип, соңгы вакытта М.Солтангалиев һ.б. белән мавыгып алдык.

Әле 1917 елда төзелә башлап, 1918дә формалашкан, Сталин җитәкчелегендәге Милли-мөселман комиссариаты да инде безгә «кызыксыз» кебек иде. Җитәкчесе М.Вахитов 1918 елның җәендә үк үтерелә бит, ни эш кыра алган алар, янәсе? Ә юк, шәрык халыклары бу комиссариатка бик зур өмет баглап, ерак Төркестан сахраларында Мулланурны — шәрыкне уятачак нур итеп кабул иткәннәр икән! Г. Ибраһимовның аны «шәрыкнең бөек революционеры» дип атавы да юкка түгел икән. Бик бай, тирән мәгънәле бу шигырь! Укыгыз әле… Башка шигырьләре дә: гыйсъян белән янган, көрәш рухлы, чакырулы, нәгърәле эндәшләр дә, гаҗәеп матур лирикасы да… яңа, совет мохитенә җайлашырга омтылу, дус-ишләрен шуңа ышандыру шигырьләре дә… Шашкын һәм дәрвиш гыйшкының илне сөюгә күчү ышанычы… Шәкерте Г.Голәмгә язган Нариндәрьядан газәл-хаты…

Ә Г.Голәм яшьлегендә Һ.Такташ белән дә таныш-дус булган. Егерменче еллар азагында Ташкентта аның «баглар кебек матур илендә» юлда арган Хәсән Туфан кунак була. Мөгаен, Такташны да, Чулпанны да, Бабичны да искә алып сөйләшкәндер алар. Шулайдыр. 1966 елда Тукайның 80 еллыгына дип Казанга килгәнендә Г.Голәм Туфанда да кунакта булды; Казанны бик сагынган иде, Тукай, Такташ каберләрен дә зиярәт итте ул… Чулпан шәкерте шул елны вафат булды — зилзилә Ташкентны тетрәткәндә, күпне кичергән йөрәге түзмәгәндер…

Быел бит Казанның төрки илләр белән багланышта үзе мәркәз булган елы. Быел — Мәдәният елы дип беләбез, Чулпаннан тәрҗемәләр китабы да шул бәйрәм хозурына бүләк булсын!

*Бу шигырь журналыбызның быелгы 4нче санында (43нче бит) дөнья күрде. — *Ред.*

ЧУЛПАН

КАЛӘНДӘР ГЫЙШКЫ

Мәхәббәтнең сарае киң икән —тик юлын югалттым ки,
Күп гасырлык ташлар яткан бу хәтәр юлда калдым ки.
Карашлар диңгезен күрдем: күп назлы дулкыны бардыр,
Һәлакәт киләсен белми колачны шунда салдым ки...
Гаҗәп дөнья икән бу гыйшык дөньясы, әй-йа, дуслар,
Бу дөнья дип, мәңгелеген — бик аз бәһагә саттым ки.
Аның гөл илендә былбыл сайрады, өзде бәгырьне,
Кулымнан эш төште тәмам — моң-зар эченә баттым ки.
Чын каләндәрдәй гиздем мин дөньяны, яр тапмый,
Тагын тар куышыма кайгым, аһым белән мин кайттым ки.
Мәхәббәт күгендә исемем гүзәл Чулпан иде, дуслар,
Кояш нурына түзми, җиремә төшеп аякны бастым ки...

Баку, 1920

КӨЗГЕ ЯФРАКЛАР

Көз җитте... Туфраклар агарып калдылар —
Агарып төс җуйды көзләрдә туфраклар.
Соң сулыш! — Яфраклар кызарып яндылар,
Кызарып яндылар соң дәмдә яфраклар.

Каргалар багларда «Кар!» диеп калдылар, —
Белмәдем, кемнәрнең өлеше-ризыгы киселер?!
Яңакка бер тырнак — кул әзе салдылар, —
Белмәдем, кемнәрнең өмете өзелер?!

Әй, суык илләрдән боз киеп килгәннәр,
Ул тупас төсегез кырларда юк булсын.
Әй, минем бакчамнан җимешем өзгәннәр,
Ул кара уегыз тиз карга күмелсен.

Белмәдем, кемнәрнең өмете юк булыр,
Соң сулыш... яфраклар кызарып яндылар...
Белмәдем, кемнәрнең өлеше киселер,
Көз инде... Туфраклар төс җуеп, агарып калдылар.

1923 ■

Хәмит Латыйф рәсеме

«ШӘКЕРТЛӘРГӘ БҮЛӘК ИТТЕМ...»

Айдар Гайнетдинов

Ризаэддин Фәхреддин (1859-1936) исемен телгә алуга ук без күз алдыбызга милләтебез, динебез өчен бөтен көчен сарыф итеп, армыйталмый хезмәт куйган, галимнәрнең галиме булып саналган бөек татар галимен китерәбез. Ул безгә тарих, дин, әдәбият, педагогика һ.б. буенча бәяләп бетергесез бик зур мирас калдырган энциклопедик белемле шәхес. Шуңа күрә аның һәрбер сүзе, фикере, мәкаләсе, китабы ифрат зур игътибарга лаек.



«Көтебе ситтә вә мөәллифләре» китабының 1910 елгы басмасы. Авторы – Ризаэддин Фәхреддин

Кызганычка каршы, галимнәр, белгечләр тарафыннан галимнең барлык хезмәтләре дә халыкка кайтарылды, дип әлегә әйтеп булмый. Кайберләре һаман үз чиратын көтеп ята. Мәсәлән, шундыйлардан «Көтебе ситтә вә мөәллифләре» китабы. Бу хезмәт 1909 елда язылып, 1910 һәм 1913 елларда Оренбургның «Вакыт» матбагасында басылып чыккан булган. Әлегә бу әсәр игътибардан читтә кала килде. Чынлыкта исә «Көтебе ситтә вә мөәллифләре» әсәрендә бик күп файдалы мәгълүматлар, киңәшләр урын алган. Бигрәк тә мәдрәсәләр өчен аның әһәмияте әйтеп бетергесез. Ризаэддин Фәхреддин максат итеп нәкъ менә, беренче чиратта, шәкертләргә дәреслек буларак хезмәт язуны күздә тоткан. Галим аны Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе шәкертләренә адреслый.

Хезмәт хәдис гыйлеме буенча язылган. Анда хәдис терминологиясе аңлатыла, хәдис төрләре, үзенчәлекләре билгеләнә, шулай ук хәдисләрне җыеп җыентыклар төзегән шәхесләрнең кыскача тәрҗемәи хәлләре, эшчәнлекләре, хезмәтләре яктыртыла. Нигездә, ислам дөньясында мәшһүр алты хәдис җыентыгы яки китабы турында сөйләгәнлектән, хезмәтнең исеме — «Көтебе ситтә вә мөәллифләре», ягъни гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә «Алты китап һәм төзүчеләре» дип атала. Хәдис буенча китаплар, җыентыклар язылмый, ә төзелә, чөнки хәдиснең авторы Мөхәммәд пәйгамбәр үзе булганлыктан, аның шул сүзләрен, гамәлләрен сөйләгән сәхабәләр сүзләрен хәдис җыючылар язып алып, шул рәвешле җыентыкларын төзегәннәр. Шуңа күрә бу очракта «мөәллиф» сүзен «автор» яки «язучы» дип түгел, ә «төзүче» дип аңларга кирәк.

Ризаэддин Фәхреддин хәдис гыйлеменә зур игътибар бирелергә тиешле икәнен бик күп хезмәтләрендә азсызыклый, чөнки ислам дине өйрәтмәләренең чыганакларыннан, әһәмияте буенча Коръәннән кала, икенче урын-

да хәдисләр килә. Боларның икесен дә белгән мөселман үзе үк галим-мөҗтәһидкә әйләнә һәм шәригать мәсьәләләрен үзе тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртә, нәтиҗә ясый ала. Нәкъ менә шундый дәрәҗәдәге кешеләр күбрәк булса, татарлар, схоластикадан, тәкълидтән — башкаларга сукырларча иярүдән арынып, рухи яктан нык үсеш алырлар иде, дип саный Ризаэддин Фәхреддин. Аның бу фикерләре бүгенге көндә дә бик актуаль булып кала бирә.

Кызганыч ки, бүгенге мәдрәсәләрдә чит телләрдән тәрҗемә ителгән дәреслекләр буенча укыталар, үзебезнең җирлектә үз галимнәребез тарафыннан язылган мондый төр дәреслекләр исә читтә кала. Бу инде аңлашыла да, беренчедән, алар гарәп графикасында язылган, икенчедән, иске татар телендә, ягъни хәзерге телдән берникадәр аерыла торган телдә язылган. Шуларны истә тотып, без Ризаэддин Фәхреддиннең әлеге әсәре укучыга аңларга уңайлы булсын өчен барлык архаик грамматик формаларны хәзерге әдәби тел нормаларына салып эшләргә булдык, ягъни максималь дәрәҗәдә хәзерге гамәлдәге телгә җайлаштырдык, якынайттык. Бу хезмәттән укучылар файда алырлар, гыйлем тупларлар, дигән теләктә калабыз.

КӨТЕБЕ СИТТӘ ВӘ МӨӘЛЛИФЛӘРЕ

Ризаэддин бине Фәхреддин

БҮЛӘГЕМ

«Хөсәения» мәдрәсәсенең шәкертләренә, хәдис гыйлеменнән дәрес укыткан вакытта, бу фәнгә караган кайбер мәгълүматны җыеп, бер китап төзү хакында вәгъдә биргән идем. Фәкать бу җирдә сөйләргә тиеш булмаган сәбәп белән, телгә алынган хезмәттән мин аерылдым һәм вакыт үтү белән шәкертләр дә мәдрәсәдән чыктылар яки чыгарылдылар һәм төрле җирләргә теләсә ничек таралып киттеләр. Шулай булса да, вәгъдәмне үтәү максаты белән язган китапны «Көтебе ситтә вә мөәллифләре» исеме белән төзедем һәм телгә алынган шәкертләргә бүләк иттем.

Аллаһ Тәгаләнең рәхмәт капкалары бикләнмәгән сурәттә, башка капкаларның бикләнүләренең карары юк. **«Әгәр Аллаһның елгасы акса, башка елгаларның кирәге калмас».** Шуның өчен өметем ки, мәҗбүри рәвештә мәдрәсәдән аерылган шәкертләрдән күбесе Хак Сөбханә вә Тәгалә хәзрәтләренең рәхмәте күләгәсендә, киләчәк заманда хөрмәтле адәмнәрдән һәм гыйлем, әдәп әһелләреннән булырлар. Бу көндә нинди җирләрдә булсалар да, булсыннар, минем ахирәт капиталым һәм соңгы запасым булу ышанычым белән мәшгульлегем бу хезмәтемне бүләк рәвешендә кабул итәрләр. Моның белән беррәттән, гамәл дәфтәремә язылганнан соң хәер-дога белән рухымны шат кылырлар. **«Кеше үлү белән, тик өч нәрсәдән башка, аның гамәлләре аннан киселер: агып торучы сәдака (кешеләргә файда китерүче эшләре), файдалы гыйлеме һәм дога кылучы изге баласы».** (Мөслим).

КЕРЕШ

«Көтебе ситтә [алты китап] һәм төзүчеләре» хакында сүз сөйләргә керешмәстән элек, кыскалык белән булса да, гомуми сурәттә хәдис гыйлеме хакында бераз сөйләргә кирәк. Чөнки хәдис гыйлеме турында булган бу нәрсәләр белән таныш булмыйча, «Көтебе ситтә һәм төзүчеләре» хакында язылган нәрсәләрдән өмет итәрлек дәрәҗәдә файда күренмәс. Шуның өчен бу җирдә, берничә бүлекләргә аерып, хәдис гыйлеме хакында, кыскача булса да, беркадәр бәхәсләр язылачак.

Гасры сәгадәттән [сәхабәләр яшәгән гасырдан] аз көннәрдән соң махсус галимнәр тарафыннан хәдис китаплары төзелде һәм хәдисләрнең иснадлары[1] тикшерелде. Сәнәдләр[2] һәм равиләр[3] хакында «җәрх вә тәгъдил»ләр [хәдис сөйләүчене гаепләү яки мактаулар] игълан ителде, зәгыйфь һәм асылсыз булган хәдисләр ачык күрсәтелде; хәтта мәүдуг [ялган] булганнары махсус китапларда җыелып бәян кылынды. Нәтиҗәдә, бу турыда булган хезмәтләрнең һәрберсе үтәлде. Инде хәдис галимнәре каршында сахих [дөрес] булганнарын «сахих» дип әйтү һәм шуларның фәтваләре белән гамәл кылудан башка чарага ихтыяҗ калмады. Аерым алганда, чаралар күбәеп, гасырлар ерак китү сәбәпле, равиләрнең хәлләрен бүген янәдән тикшерү яки мәйданда булган хәдис китапларында язылган иснадлардан башка бер иснадлар табып чыгару мөмкин түгел.

Моның өстенә, хәдис китаплары, махсус адәмнәр тарафыннан төзәтелде һәм хәдис гыйлеменә караган затлар тарафыннан шәрехләр язылды. Ниһаять, болар заманының көчле булган адәмнәре төзәтүләре белән төрле матбагаларда басылып, дөньяның дүрт ягына нәшер ителде. Инде бу хезмәтләр гыйлем әһелләренең кулларында. Әлеге нәрсәләр безнең бу китабыбызны төзүдән чикләми. Бәлки, киресенчә, китабыбыз боларга бәйле булганлыктан, гыйлем алу юлында булган кайбер шәкертләр, ихтимал ки, файда алырлар. Өметебез шул. **«Дөреслектә, гамәлләр нияткә карап хисапланыр һәм, чынлыкта, һәркемгә ниятләгән нәрсәсе генә булыр».**

I

ХӘДИС ҺӘМ СӨННӘТ, АЛАРНЫҢ СӨЙЛӘНҮЛӘРЕ

Хәдис дин әмерләренә караган, галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез Мөхәммәд саллаллаһү галәйһи вә сәлләм хәзрәтләреннән чыккан сүзләр, эшләр, тәкъририләрдән[4] гыйбарәт булыр[5]. «Сөннәт» тә шул ук нәрсә[6].

Кешеләр эшләрен һәм дөньяви мөгамәләләрен дөрес акыл, тәҗрибә һәм фаразлар белән белсәләр дә, шәригать хөкемнәрен рәсүлүллаһ хәбәреннән башка бүтән юл белән белергә көчләре юк. Моның өчен ислам шәригатебезнең бөек мәртәбәле Коръәннән соң икенче дәрәҗәдә булган дәлиле һәм нигезе — хәдис һәм сөннәт. **Хөрмәтле рәсүлнең эш һәм тәкърирләре «сөннәт фигълия» һәм «сөннәт гамәлия» дип, сүзләре «сөннәт каулия» дип билгеле булган.**

[1] *Иснад — хәдисне тапшыручылар (равиләр) чылбыры.*

[2] *Сәнәд — иснад мәгънәсендә.*

[3] *Рави — хәдис тапшыручы, риваять итүче кеше.*

[4] Бернәрсә эшләнгәнлекне күреп торган хәлдә, хөрмәтле рәсүл тарафыннан тыелмаган икән, моңа «тәкърир» дип әйтәләр (үзгәртмәде, тыймады, бәлки, шул көе калдырды).

[5] Кайберәүләр «хәдис»не тик пәйгамбәрнең сүзләренә генә кайтарып калдыралар.

[6] «Сөннәт» сүзе түбәндәге мәгънәләргә ия:
1) Капма-каршысы бидгать. Әгәр дә хөрмәтле рәсүл юлына туры килә торган гамәл булса, фәлән кеше сөннәт белән гамәл кыла, дип әйтәләр. Бу юл Коръән һәм хәдис белән ныгытылган булсын. Моның капма-каршысы булганнарга бидгать әһеле дип әйтәләр.
2) Сәхабәләр гамәле. Бер гамәлнең асылы кирәк китапта (Коръәндә) һәм сөннәттә булсын яки булмасын. Әгәр дә сәхабәләр тарафыннан риваять ителгән икән, моңа «сөннәт»

Хөрмәтле рәсүл хәзрәтләренең хәдис һәм сөннәтләрен сәхабәләр күреп һәм ишетеп риваять иткәннәр; алардан табигыйннар[7] һәм болардан да тәбгы-табигыйннар[8]. Нәтиҗәдә, сәләфләрдән[9] хәләфләр[10] риваять итеп торганнар.

Хәдис гыйлеме элекке вакытларда бары тик күңелләрдә генә саклана иде. Хәдис галимнәре аны ишетер өчен шәһәрләрдән шәһәрләргә һәм илләрдән илләргә йөрделәр. Соңра, хәдис гыйлемен белгән затлар бер-бер артлы вафат булганнан соң, бу гыйлемне ятлау максаты белән җыентыклар төзергә керештеләр һәм күп китапларны мәйданга чыгардылар.

Хәдис белгечләре тарафыннан мондый хәдис китаплары да тәнкыйтьләнде, төзүчеләрнең равиләре хакында булган өйрәнүләре һәм тырышуларына караган китаплар берничә дәрәҗәләргә аерылды, яхшылары белән яманнары бүленде.

Рәсүлуллаһ саллаллаһү галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренең үзеннән турыдан-туры ишеткән кемсәләргә бәйле хәдис-шәрифләр хәбәр мөтәватир, хәбәр мәшһүр, хәбәр вахид дип йөртелгән өч төрле юлның берсе белән ирешергә мөмкин.

Хәбәр мөтәватир — шундый хәбәр ки, акыл белән фикер йөрткәндә, ялганлаулары мөмкин булмаган; күп һәм төрле кешеләр тарафыннан риваять ителгән хәдисләр[11].

Хәбәр мәшһүр — шундый хәбәр ки, беренче гасырда аз кешеләр тарафыннан сөйләнелгән хәлдә, икенче һәм аннан соңгы гасырларда мөтаватир дәрәҗәсенә ирешә.

Хәбәр вахид — шундый хәбәр ки, беренче һәм аннан соңгы гасырларда мөтәватир дәрәҗәсенә ирешә алмый.

Хәбәр мөтәватир белән бәйләнгән нәрсәләр хис белән [күреп һәм ишетеп] бәйләнгән нәрсәләр шикелле, **«гыйлем якыйни» [асылда, шик төшми һәм үзгәрми торган гыйлем]** була. Үзләре барып күрмәсәләр дә, тик бер хәбәр белән Мәккә, Истанбул, Петербург, Искәндәрия шәһәрләренең барлыгын белү шикелле. Әгәр дә мөтәватир юлы белән бер хәдис сөйләнелсә, ул хөрмәтле рәсүл хәзрәтләренең үз авызыннан ишетелгән дәрәҗәдә була.

Мөтәватир дәрәҗәсенә ирешмәгән бик күп хәбәр вахидларның, моңа тиеш булса да, уртак бер мәгънәгә ишарә итүләре [сәбәпле], бу ишарә иткән ноктада, «мөтаватир мәгънәви» була. Хатим исемле кемсәнең юмартлыгына ишарә иткән хәбәрләр кебек[12]. Моны да мөтәватир сүзе шикелле «гыйлем якыйни» тапшыра.

Мөтәватир юлы белән сөйләнелгән нәрсәләр «сөннәт фигълия»дә күп булган хәлдә, «сөннәт каулия»дә булуында каршылыклар бар. Кайберәүләр: «Бар» — дип хәтта мисаллар күрсәткән хәлдә, күп кешеләр моны инкяр итәләр. Һәрхәлдә, гамәлләр һәм игътикадлар [ышанулар] хакында бер караштa булган мөтәватир хәдис юк[13].

Хәбәр мәшһүрдән «гыйлем якыйни» белән «зан» [уй] арасында бер гыйлем һәм, икенче төрле әйткәндә, «гыйлем якыйнигә якын зан» яки «занга якын гыйлем якыйни» хасил була. Бу нәрсәне «гыйлем таманинә» дип атыйлар[14].

Хәбәр вахид белән тик «зан» гына хасил була. Хәбәр мәшһүр һәм хәбәр вахид белән гамәл дөрес булган хәлдә (чөнки гамәл

дип әйтәләр. 3) Фарыз һәм ваҗибнең капма-каршысы. Бу мәгънә белән сөннәт күбрәк фикыһ китапларында кулланыла.

[7] *Табигыйннар — сәхабәләрне күргән кешеләр.*

[8] *Тәбгы-табигыйннар — табигыйннарны күргән кешеләр.*

[9] *Сәләфләр — борынгы изге мөселман кешеләр.*

[10] *Хәләфләр — сәләфләрдән соң килүче буыннар.*

[11] «Хәбәр мөтаватир» равиләренең гадел кеше булулары шарт түгел.

[12] Сүзләр я берләшкән булсын, я башка булсын, ике мәгънә берләшкән хәбәрләр «тәватир ләфзый» дип атала. Әмма сүзләр һәм мәгънәләр башка булып та, барысыннан бер уртак мәгънә аңлашылса, моның турында «тәватир мәгънәви» дип әйтәләр. Мәсәлән, берәү Хатимнең ат бирүен, икенче кеше дөя бирүен, өченчесе акча бирүен сөйли. Башка берәүләр сыйфатлары хакында хәбәр итәләр. Бу төрле хәбәрләрнең барысыннан бер «бирү» мәгънәсе аңлашыла. Бу — юмартлык дигән

өчен уй да җитә), дәлилләре «якыйни» һәм катгый булу белән шарт ителгән игътикадлар дөрес булмый.

Хәбәр вахидтә булган сәнәдләр һәр буында **берәр генә заттан гыйбарәт булса, «гариб», икешәрдән гыйбарәт булса, «газиз»** дип атала. «Сахих» дип аталыр өчен хәдисләрнең «газиз» булуы шарт түгел. Бәлки, «гариб» хәдисләр дә «сахих» була алалар. Имам Бохари да үзенең җыентыгында булган хәдисләрнең «газиз» булуын мәҗбүри санамаган.

Хөрмәтле рәсүлдән турыдан-туры ишеткән кемсәләргә карата хәдисләрнең һәрберсе «мөтәватир» хөкемендә булган хәлдә, «гыйлем якыйни»ны тапшыра. Шул сәбәпле, сәхабәләр заманында бердәм рәвештә кылынган гамәлләр рәсүлуллаһның әмере һәм сүзе белән йөкләнелгәнлектән, бөтен мөселманнар өчен шул рәвешле гамәл кылу тиешле була. Гәрчә, сәнәдләре һәм дәлилләре хакында кирәкле башка бер дәлил күренмәсә дә. Фарыз намазларының вакытлары һәм рәкәгатьләре, зәкят микъдарлары моңа мисал булса кирәк.

II

ХӘДИС ГЫЙЛЕМЕНЕҢ ФАЗЫЙЛӘТЕ. РИВАЯТЬ ҺӘМ ДИРАЯТЬ ХӘДИС. ХӘДИС НИГЕЗЛӘРЕ ХАКЫНДА БАСЫЛГАН ХЕЗМӘТЛӘР

Хәдис гыйлеменең ислам әһелләре өчен иң фазыйләтле бер гыйлем булуын күп язарга хаҗәт булмас. Ислам диненең, Коръәншәрифтән соң, икенче дәрәҗәдәге нигезе һәм бинасы хәдис-шәриф булса, бу гыйлемнең никадәр бөек һәм [хәдис] галимнәренең дә хөрмәтле булырга тиешлеге мәгълүм булса кирәк. Галәмнәрнең горурлыгы булган әфәндебез (Мөхәммәд пәйгамбәр) хәзрәтләренең: **«Бездән нәрсә дә булса ишетеп һәм аны ничек ишеткән, шул рәвешле башкага әйтеп ирештергән кешене Аллаһ сөендерсен, әйтеп ирештерелгән кешене теге беренче ишеткән кешегә караганда яхшырак аңларга мөмкин бит[15]»**, дигән сүзләрендә булган хәер-догасы һәм кешеләрне хәдисләрне башкаларга ирештерергә чакыруы белән моның хөрмәтле эш булуына дәлил буларак җитә. Хөрмәтле сәхабәләр һәм табигыйннар Коръән һәм сөннәт гыйлемнәренә гаять игътибар иттеләр, хәтта ки бер хәдисне үзенең равиеннән турыдан-туры ишетү өчен айлык сәфәрләрдә йөриләр иде.[16] Мөхетдин бине Гарәби хәзрәтләре: **«Хәдис әһелләре кыямәт көнендә пәйгамбәрләр белән бергә кубарылачаклар. Өммәттә аларның һәрберсе чылбыр белән пәйгамбәрләргә тоташкан хәлдә вәхине[17] ирештерүчеләр һәм бу эштә пәйгамбәрләрнең варислары булып торалар. Әгәр дә фәкыйһлар хәдисләр риваяте белән шөгыльләнмәгән булсалар, аларга андый дәрәҗә юк һәм пәйгамбәрләр белән түгел, ә, бәлки, гади кешеләр белән кубарылачаклар. Галимнәр исемен хәдис галимнәренә карата кулланалар, чынлыкта, алар имамнар»**, — дип әйтә.[18]

Хәдис фәнен иң элек «риваять гыйлеме» һәм «диряять гыйлеме» дигән ике бүлеккә аералар. Хәдис нигезләренә һәм терминнарына караган бәхәсләр «риваять хәдис» исемле бүлегенә керә.

төшенчә. Шул төрле хәбәрләр Хатимнең юмартлыгы хакында «мөтәватир» була.

[13] Кайберәүләр: «Иннәмәл-әгъмәлү бин-ният» хәдисен һәм: «Мән кәззәбә галә мүтәгаммидә» хәдисен «таватир ләфзый» итеп күрсәтәләр. «Тәдриб әр-рави»га мөраҗәгать ителә. Б.190-191.

[14] Кайбер фәкыйһләр «хәбәр мәшһүр»не «хәбәр мөтаватир» дәрәҗәсендә саныйлар. Мөхәддисләр дә юллар бер-берсенә капма-каршы булу, зәгыйфь равиләрдән һәм кимчелекләрдән сәламәт булу шартлары белән бу фикердә. Фәкать мөтаватир зарури гыйлемне тапшырган хәлдә, мондый хәбәр мәшһүрләр теоретик гыйлемне тапшыра, диләр.

[15] Җамигъ Тирмизи. — Т.2. — Б.90.

[16] Ибне Габделбәр. Мохтасар җамигъ бәян әл-гыйлем. — Б.46-47.

[17] *Вәхи — берәр фикерне Алла тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә салу.*

Хәдисләрнең рәсүл әфәндебезгә тоташкан иснадларын, равиләрнең гаделлеген һәм кабул ителмәү сәбәпләрен тикшерү, аларның тормыш юллары, эшчәнлекләре белән таныш булу **«риваять гыйлеме»**нә кирә. «Риваять гыйлеме» буенча хәдисләр: сахих, зәгыйфь, мөнкәр[19], мәүдугъ[20] , шулай ук мөтәватир, мәшһүр, хәбәр вәхид һәм дә болардан башка бик күп төрләргә аерылырга мөмкин.

Иснадлары сәламәт булып җиткәннән соң, шул хәдисләр белән гамәл кылу мөмкин булу-булмавын, аның буенча гамәл кылу итеп тотылудан берәр тыю очравы-очрамавын тикшерү — **«дираять гыйлеме».**

Рәсүлуллаһ әфәндебез хәзрәтләреннән сөйләнелгән хәдис белән гамәл кылу өчен аның дөрес булуын, кимчелекләрдән азат булуын белергә кирәк булган кебек, эчтәлеге белән гамәл кылмастан [элек], я шәригать, я акыл ягыннан тыелмавын белергә дә күпвакыт ихтыяҗ була. Һәрбер «Калә ән-нәби галәйһис-сәләм» («Пәйгамбәр галәйһис-сәләм әйтте») астында язылган гыйбарә хәдис булмаган кебек, һәрбер хәдис тә аның буенча гамәл кылу хөкемен алмый. Бу нәрсәләрне тикшерү «дираять хәдис» бүлеген тәшкил итә.

Шул сәбәпледер, иң бөек хәдис китапларыннан булган Бохари һәм Мөслим җыентыкларында булган хәдисләрне ислам галимнәре шул хәленчә кабул итми, бәлки, һәрвакыт тикшерәләр. Хәтта ки кайбер урында мәтенендә[21] хата барлыгын исбат итәләр.

Хәдис нигезләре хакында басылган хезмәтләр болар:

1. «Әлфиййәтү фи усул әл-хәдис». Шигъри формада язылган бу китап Зәйнеддин әл-Гыйракый (805) хезмәте булып, үзе Сәхави (902) тарафыннан язылган ике данә шәрехе белән бергә 1303 елда Ләкнәүдә басылган.

2. «Әр-рисаләт әл-мохтасара». Сәййид Шәриф (816) тарафыннан язылган бу хезмәт 4 биттә «Җамигъ Тирмизи» белән бергә басылган.

3. «Әл-мәнзумәт әл-бәйкунийә». Шигъри формада булган бу хезмәт Зәркани (1122) шәрехе белән бергә 131 елда Мисырда басылган.

4. «Мөкаддимәт Ибне Салах». Төзүчесе Әбү Гамру бине Салах (643) булган бу китап 1326 елда Мисырда басылган.

5. «Тәкъриб ән-Нәвави». Имам Нәвави (676) хезмәте булган бу китап имам Сөютыйның (911) «Тәдриб әр-рави» шәрехе белән бергә 1307 елда Мисырда басылган.

6. «Нөзһәт ән-нәзар фи тәүдыйхи нөхбәт әл-фикер». 1295 елда Канбурда басылды. Ибне Хәҗәр әл-Гаскалани (852) хезмәте. Китап читендә язылган Муса әфәнде [хезмәте] белән 1328 елда Оренбург шәһәрендә басылды.

7. «Мөкаддимәт әш-шәйхи Габделхак». Габделхак әд-Дәһләви хезмәте булган бу китап «Мишкят әл-мәсабих» тарафларында басылды.

Дәвамы бар

*Текстны басмага **Айдар Гайнетдинов** әзерләде.* ■

[18] Әл-фүтухат әл-мәккиййә. — Т.3. — Б.56.

[19] *Мөнкәр — инкарь ителгән, танылмаган.*

[20] *Мәүдугъ — дөрес дип калдырылган.*

[21] *Мәтен — текст, хәдиснең эчтәлеге.*

АЛ МӘЧЕТ

Ильяс хәзрәт Җиһаншин

*«Казан сәүдәгәре Муса бине Исмәгыйль бине Апанай кызы Зөбәйдә хаҗи Тимерфулат бине Муса бине Ягъкуб бине Ишмәмәт никахында вафат булгач, 1808 елда кызының мирасы хисабына төзетте».**

Унынчы мәхәллә саналган «Ал мәчет»нең төзелеше бөтен халыкны таң калдыра. Борынгы осталарның эш үрнәкләре серен бүген дә сокланып, гаҗәпләнеп өйрәнәләр, сөйлиләр. Әлбәттә, «Ал мәчет» архитектурасы башкалардан бик нык аерыла. Мәчетнең буе 16х12 метр, алгы якта манарасы куелган хәлдә салына. 1905 (башка чыганакларга караганда — 1906) елда беренче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтсафа улы Галикәев (1847-1919) карамагындагы мәчет бинасының иңе 16 метр, буе 23 метр итеп киңәйтелә, аның архитектурасына кайбер үзгәрешләр кертелә. Мәчет кызыл кирпечтән ике катлы итеп салынган. Манарасы бинаның төньяк ягына терәп үзенең нигезеннән күтәрелгән. Бина тышкы яктан штукатурланган, кирпечләре төрле-төрле формада тышкарак чыгарып салу ысулы белән декоратив элементларга баетылган. Манара астан сигез кырлы ике ярустан гыйбарәт һәм биек чатыр, алтын шар һәм ай белән тәмамланган. Гомумән, бу мәчет бөтен кыяфәте белән традицион татар мәчетләреннән шактый ук аерылып тора. Ул берникадәр шәрык архитектурасына тартымрак. Фасад эшләнешендә Шәрык аһәңнәре өстенлек иткән милли юнәлешне күрергә була. Кызганыч ки, 1930 елларда балконның өске өлеше һәм чатыр җимерелә, аскы сигез кырлы ярус белән балкон гына сакланып кала. Мәчет комплексына мәдрәсә, мәчет, имам йорты һәм 1888 елда рөхсәт алынып, таштан сату-алу өчен төзелгән кибет кергә. Мәчет 10 нчы мәхәллә мәчете, «Тәбәнәк Бохаралы мәчете», аннан соң «Ал мәчет» дип йөртелгән. Барлык комплекс коеп һәм чүкеп ясалган тимер рәшәткә белән әйләндерелеп алынган булган. Үзәк архивтан алган мәгълүматлар һәм Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең язмалары буенча мәчетнең беренче имамы чыгышы белән Биектау районы Әлдермеш авылы кешесе Хәмит Мортазин булган. Заманында ул тәүге мәртәбә Казанда мөселманнар өчен дини уку йортлары ачу мәсьәләсен күтәргән.

*Шиһабеддин Мәрҗани. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабыннан.

Хәмит хәзрәт үзеннән соң имамлыкны улы Мөхәммәткә тапшыра. Мөхәммәт хәзрәт ошбу мәчеттә 1832 елга кадәр эшләгән. Әлбәттә, мәчет бай иганәчеләр ярдәме хисабына яшәгән. 1879 елда моңарчы имам булып торган Габделгани Шаһиәхмәт улы Иманколов урынына мәхәллә халкы Габделкаюм Габделбадыйковны (1836-1906) сайлап куйган. Габделкаюм хәзрәт аңа кадәр Арча районы Олы Бәрәзә авылында имам вазифасын башкарган. Заманының укымышлы руханиларыннан саналган Габделкаюм хәзрәт 1890 елда үзенә ярдәмче итеп билгеләнгән җәдидчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле Салихҗан әл-Баруди (Галиев) белән берлектә мәхәлләдә алдынгы ысул (җәдид) белән белем бирү тәртипләрен урнаштырган. 1908 елда унынчы мәчет мәхәлләсендә җәдид ысулына нигезләнгән укытучылар курслары оештырганы өчен агасы Галимҗан хәзрәт Баруди белән бергә Вологда губернасына сөрелә. Аның эшен 1907 елда мәрхүм әтисе урынына имам итеп сайланган Мөхәммәтгабдулла Габделкаюм улы Габделбадыйков дәвам итә. Ул үз карамагындагы Якупов мәдрәсәсендә җәдидчелек нингезләрен саклап кала. 1910 елда ошбу мәдрәсәдә 90 шәкерт укыган.

10 нчы мәчетнең мәхәлләсе ул вакытта өлешчә кече Сембер урамын һәм шул төбәктәге тыкрыкларны биләгән. XX гасыр башында мәхәлләдә ир-ат затыннан 486 кеше исәпләнгән.

Дөрес, 1917 елның Октябрь революциясе җилләре Яңа Бистә мәчетләренә дә кагыла. 1931 елның 22 нче июлендә Татарстан Республикасының Үзәк башкарма комитеты карары белән бу гыйбадәтханә ябыла. Совет чорында мәчет бинасы башта тулай торак, аннан соң Х.Ямашев исемендәге мех берләшмәсенең санаторий-профилакториесе вазифасын башкару сәбәпле, ике як тәрәзәле зал икегә бүленә, аркалы тәрәзәләрдән зуррак итеп турыпочмаклыларын ясыйлар. Тәрәзә формалары тулысынча үзгәрә.

Ниһаять, мәчет бинасы төп хуҗаларына 1998 елда кайтарып бирелде. «Ал мәчет» бинасы янә мөселманнарга хезмәт итә башлады. Ремонт үткәрелде һәм кыска вакыт эчендә гыйбадәтханә, таһарәтханә, уку бүлмәләре, ашханә, китапханә һәм шәкертләр өчен торак урыннар булдырылды. Ошбу изге тарихлы бинада Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе урнашты.

Аллаһның рәхмәтләре булышадыр. 2005 елның 15 декабрендә, ниһаять, Бистә мөселманнарының тагын бер хыялы тормышка ашты: «Ал мәчет» манарасы күтәрелеп, анда ярым ай калыкты. Мәчет мөселманнар карамагына кайтарылып бирелгәч, гыйбадәтханәнең манарасын куярга элек берничә тапкыр талпынып карадык, әмма үз максатыбызга ирешә алмадык. Югыйсә, закон нигезендә Татарстандагы шактый күп иске мәчетләр архитектура, сәнгати кыйммәте зур булган биналар, дип игълан ителгән («Ал мәчет» тә шулар арасында), дәүләт аларны элекке хәленә кайтарырга тиеш булып та, бу үтәлмәгән, ә дин әһелләреннән моңа, ягъни мәчетнең манарасын торгызырга, тышкы фасадны реставрацияләү, тәрәзә рамнарын яңарту һәм тирә-якны тимер рәшәткә белән тотып алу өчен бик күп чыгымнар сорала иде. Аллаһның ярдәме ниятләребезгә туры килде.

Шунысы куандыра: Яңа Бистәдәге икенче гыйбадәтханәгә дә чын мәчет кыяфәте керде. Аллаһка шөкер, «Ал мәчет» янәдән Яңа Бистә яменә әйләнде.

Әдәбият:

1.Мәрҗани Ш.Б.Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. — 415 б.

2. Хайрутдинов Р.Р. Салихов Р.Р. Республика Татарстан: памятники истории и культуры татарского народа. (Конец XVIII — начало XX веков). — Казань: Изд-во «Фест», 1995. — 280 с. ■



БЕЛЕМ ӘЛИФБАДАН БАШЛАНА

(XX гасырның 20-30 елларында дөнья күргән зурлар әлифбаларына күзәтү)

....

Ләлә Мортазина

Татар әлифбасының күп гасырлык тарихы бар. Бүген, киң колач алган техникалаштыру, компьютерлаштыру заманында да әлифба үзенең тоткан юлын югалтмый. Бизәлеше, эчтәлеге үзгәрсә дә, төп максаты һәм педагогик бурычлары ягыннан әлифба моннан йөз ел элек дөнья күргәннәреннән әллә ни аерылмый.

Балаларны гына түгел, олыларны укырга-язарга өйрәтүдә дә иң төп әсбап булып әлифба хезмәт иткән. РСФСР Халык комиссарлары советының 1919 елның 26 декабрендә кабул ителгән «РСФСР халыклары арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү турында»гы декреты нигезендә ликбез (ликвидация безграмотности) кампаниясе киң колач алып җәелдерелә башлый һәм иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып, ликпунктларны һәм ликбез мәктәпләрен әлифбалар белән тәэмин итү бурычы килеп баса. Беренче чорда, зурлар өчен махсус әлифбаларның бөтенләй булмавы сәбәпле, балалар өчен язылган дәреслекләр файдаланыла. Әмма аларның олы кешенең психологик, һөнәри һәм яшь үзенчәлекләренә, кы-

зыксынуларына туры килмәүләре сәбәпле, ликбез системасында куллану мөмкинлеге бик чикле, хәтта мөмкин дә булмый. Балалар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч булган эчтәлек зурларны уку барышыннан читләштергән. Мондый әсбап нигезендә укыту методик яктан да дөрес булмаган. Шуңа күрә декрет кабул ителгәннән соң беренче көннәрдә үк әлифбалар төзү эше көн кадагына баса.

1920 елда татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре төзү буенча алты кешелек махсус хәйят (комиссия) булдырыла. Алар арасында М.Корбангалиев, Г.Ибраһимов, Х.Бәдигый, Г.Шәрәф һ.б. була. Комиссия формасы һәм эчтәлеге белән яңа шартларга, заман идеологиясенә туры килгән зурлар әлифбалары язу мәсьәләсен дә карый, әлифба да бастырып чыгара[1]. Әмма дәреслекләр язу билгеле бер методикага нигезләнергә тиеш. Ә бу өлкәдә тәҗрибә булмый әле. Тәкый Бәдигыйның «Зурлар әлифбасына үрнәк»[2] әсбабы, әлифба буларак тәкъдим ителсә дә (анда бары тик бер генә дәрес үрнәге бирелгән), беренче чиратта зурларны укырга-язарга өйрәтү буенча методик кулланмаларның тәүгесе һәм ликбез мәктәпләрендә укуукыту барышын күзалларга беркадәр мөмкинлек бирүче чыганак буларак игътибарга лаек. Шул ук елны тагын бер әсбап дөнья күрә — ул татар балалары өчен революциягә кадәр үк бик күп санда әлифбалар төзеп бастырган Мөхетдин Корбангалиевнең рәсемле әлифбасы[3]. Х.Кәримов һәм Д.Тукаль авторлыгындагы әлифба[4] Уфада дөнья күрә. Казан һәм Уфадан тыш, зурлар өчен татар әлифбалары Мәскәүдә дә нәшер ителгән[5].

Башка халыклар белән чагыштырганда, татарлар уку-укыту әсбаплары, бигрәк тә әлифбалар белән тәэмин ителеш ягыннан беренче урында торалар. 1923/24 уку елына татар телендә гомуми тиражы 40 мең экземпляр булган әлифба бастырыла. Башка милләт вәкилләре өчен балалар әлифбалары сатып алына. Ел азагына инде татар телендә крестьяннар өчен 100 мең, эшчеләр өчен 20 мең (чагыштыру өчен: марилар өчен барлыгы 21 мең экземпляр) әлифба басылып чыга[6]. Бу факт татарлар арасында методист-авторларның әзерлелек дәрәҗәсе югары булуын, татарларның уку-укыту эшенә, гадәттәгечә, бик җаваплы якын килүен раслаучы бер мисал булып тора.

Зурлар әлифбаларының эчтәлеге аларның һөнәри эшчәнлекләре белән турыдан-туры бәйләнештә сайланган. 20 нче елларның икенче яртысында басылып чыккан әлифбалар әлеге принципны искә алып эшләнгән. Төрле юнәлештәге — гомуми, крестьяннар (авыл варианты)[7], эшчеләр (шәһәр өчен)[8], кызыл армиячеләр өчен[9] махсус әсбаплар булуы олы кешеләрнең кызыксынуларын тулырак канәгатьләндергән, чөнки китапларның эчтәлеге аларга таныш, якын булган материалдан гыйбарәт. 1920 еллар башыннан алып 30 нчы еллар башына кадәр совет уку-укыту системасына комплекслар методы (комплекс системасы дип тә

[1] Зурлар әлифбасы. Тел-әдәбият дәреслекләре хәзерләүче хәйят тарафыннан төзелде. — Казан: Татгосиздат, 1921. — 54 б.
[2] Бәдигый Т. Зурлар әлифбасына үрнәк. — Казан: Татар.дәүл.нәшр., 1920. — 15 б.
[3] Корбангалиев М. Олылар өчен рәсемле татар әлифбасы. — Казан: Милләт, 1920. — 46 б.
[4] Кәримов Х., Тукаль Д. Зурлар әлифбасы. — Уфа: Вилаять нәшрияты комиссиясенең мәктәптән тыш мәгариф шөгъбәсе, 1920. — 31 б.
[5] Мөхәммәдев М.Н. Эшчеләр әлифбасы. — М., 1924. — 80 б.; Корбангалиев М., Бәдигый Х. Крестьян әлифбасы (Зурлар өчен). — М., 1925. — 48 б. һ..б.
[6] Народное просвещение в РСФСР к 1924-25 учебному году. — М.: 1925. — С.256.
[7] Бәдигый Х., Корбангалиев М. Крестьян әлифбасы. Зурлар өчен. Бөтен сүзләрне күзәтү юлы белән авыл хуҗалыгы тормышына каратып язылган. — Казан: Восток, 1923. — 59 б.; Дистанов Г., Бурнаш В. Яңа ил. Авыл өчен (Зурлар әлифбасы). - Казан: Татиздат, 1930. — 65 б. һ.б.
[8] Вәлит Г., Арслан М. Эшчеләр әлифбасы. — М.: Центриздат, 1930. — 88 б.; Мөхәммәдев М. Эшчеләр әлифбасы. — М.: 1924. — 80 б. Һ.б.
[9] Саттаров Ш. Кызылармеец әлифбасы. — М.: Дәүл. хәрби. нәшр., 1925. — 64 б.

атыйлар) кертелә. 1923 елның маенда узган II укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча бөтенсоюз съездында яңа метод белән укыту мәсьәләләре дә карала. Казанда 1923 елның 15-20 сентябрендә булып узган I көнчыгыш методик конференциясендә танылган педагог М.Корбангалиев комплекс методының эчтәлегенә багышланган чыгыш ясый[10]. Барлык дәреслекләрне, шул исәптән әлифбаларны да, яңа метод нигезендә төзергә тәкъдим ителә. Бу төр әлифбаларның төзелеше түбәндәгедән гыйбарәт була: һәр дәрес өчен билгеле бер тема сайлап алына һәм барлык мәгълүмат шул тема (мәүзугъ) тирәли оеша. Олы кеше бер дәрес кысаларында бер үк вакытта укырга һәм язарга өйрәнә, шулай ук элементар математик белемнәр (санарга, кушарга һәм алырга өйрәнү, гади вакланмалар, процентлар һәм диаграммалар белән эш итү) туплый. Шулай итеп, бу төр әлифбалар аерым предметлар буенча дәреслекләрне алыштырган. Дәрес темасы итеп олы кешеләрне кызыксындыра торган бер лозунг (шигарь) алынган. Ул, һичшиксез, эшче һәм крестьяннар тормышына караган һәм сәяси яктан тәрбияви көчкә ия булган. Дөрес оештырылган әңгәмә нәтиҗәсендә белем алучылар үзләре үк шул лозунгка килеп чыгарга тиеш була. Дәрес материалы да шуңа нигезләп бирелгән. Шулай итеп, укытучының педагогик осталыгы лозунгка салынган фикерне сәяси белем бирү чыганагы буларак файдаланырга мөмкинлек биргән.

Әлбәттә, билгеле бер вакыт аралыгы, үзенчәлекле шартлар өчен (аз вакыт эчендә киң һәм күпкырлы мәгълүмат бирү мәҗбүрияте) комплекслар системасының уңайлы яклары булган. Ул олыларның дәрес материалы, сәяси вазгыять белән кызыксынулары артуга китергән, предметара бәйләнешләр булдыруга, тормыш-көнкүреш, әйләнә-тирә дөнья белән тәңгәллекләр урнаштыруга ярдәм иткән, әмма методик яктан караганда кимчелекләре дә булган. Татар әлифбалары тарихын өйрәнгән галим Фатыйх Ибраһимов фикеренчә, бу методның иң зур җитешсезлеге авыр аңлаешлы сүзләрнең күп булуында, күп очракта дәрес материалының комплекс темасы белән бәйләнеше начар булуда[11].

Әйтеп узганча, сәяси материал зурлар әлифбаларының төп эчтәлеген тәшкил иткән. Чөнки, *«зурлар арасында наданлык бетерүдән төп максат аларны фәкать коры уку-язу техникасына гына өйрәтү түгел, бәлки аларга сәяси һәм икътисади мәгълүматлар да биреп, сыйнфый аңнарын арттыру һәм киләчәктә советлар төзелеше эшенә аңлы гражданнар булып катнашырлык хәлгә китерүдер»*[12]. Шул ук вакытта укытучыларның үзләренең сәяси белем дәрәҗәсе җитәрлек булмау күренешләре дә күзәтелгән, чөнки ликвидаторлар арасында моңа кадәр педагогика белән бәйләнеше булмаган, хәтта курслар узмаган, ләкин укый-яза белгән кешеләр дә булган (*«Укытучылар күп вакытта үзләре сәяси яктан караганда укый-яза белми торган, әмма сәяси, сыйнфый аңнары булган укучыларга караганда да надандрак»*[13]). Бу зурларны укыту эшен дөрес юлга салуны сорый, һәм иң әһәмиятле чараларның берсе булып, укытучыларның сәяси белемнәрен арттыру (махсус тәгълимати мәктәпләр аша алып барылган) белән бергә, сәяси материал дөрес урнаштырылган әлифбалар төзү торган. Әлифбаларның төп эчтәлеген яңа идеология басымы астында яшәгән халыкны заман шартларына күнектерү, совет власте төзелешенең

---

[10] Корбангалиев М. Бөтенроссия җөмһүриятендә яшәүче төрек-татар халыклары арасында мәгариф эшләренең моңа кадәр кузгатылмаган почмагы // Мәгариф. — 1923. — №9-10. — Б.10-11.

[11] Ибрагимов Ф.И. Развитие методики обучения татарской грамоте и буквари: Автореф. Дисс. .. к.пед.н. — Казань: 1969. — С.43.

[12] Сафин М., Газиз Р. Наданлыкны бетерү мәктәпләренең программы (методик күрсәтмәләр белән). — Казан: 1926. — Б.3.

[13] Сафин М., Газиз Р. Наданлыкны бетерү мәктәпләренең программы (методик күрсәтмәләр белән). — Казан: 1926. — Б.4.

нигезләрен, советлар, Кызыл Армиянең әһәмиятен төшенергә өйрәтүдән гыйбарәт мәгълүматлар тәшкил иткән. Шулай ук совет иленең капиталистик илләр белән чагыштыргандагы өстенлекләре, аларда эшчеләргә яшәүнең гаять авыр булуы, илебез халкының тормышы көннән-көн җиңеләя бару, өметле, бәхетле киләчәге һ.б.ш. материаллар төп эчтәлекне тәшкил итә. Революциягә кадәр дөнья күргән әлифбалардан аермалы буларак, бу чор әлифбалары бөтен дөнья пролетариатын туплау, берләштерү шигарен алга сөрә. Ярлылар һәм байлар, ачлар һәм туклар тормышын сурәтләү аша совет җәмгыятенә, аның төзелешенә мәхәббәт тәрбияләнгән. Болар барысы да әлифбаларның эчтәлегендә чагылыш тапкан.

Шул ук вакытта, билгеле бер вакыт аралыгында дөнья күргән барлык әлифбалар да, кайсы категория кешеләргә атап язылуларына карамастан, бердәм метод һәм принципларга нигезләнгән. Беренче чорда укырга-язарга өйрәтүдә авазлар методы дәвам итсә, 20 нче еллар башында, укыту методлары өлкәсендә алып барылган эзләнүләр, комплекслап укыту системасының килеп керүе грамотага өйрәтүдә бөтен сүзләр методын кабул итүгә китерә[14]. Бу методны шулай ук «Америка ысулы» дип тә йөрткәннәр. Әлифбалар да шул нигездә төзелә башлый. Шушы методка ияреп язылган беренче әлифба булып Т.Бәдигыйның алда искә алынган әлифбасы саналса да, М.Корбангалиев язуынча, бу әлифба да, *«ныклап тикшергәндә, методы шул ук аваз методы һәм мөндәриҗәсе шул ук иске әлифбалар мөндәриҗәсе кебек үк диярлек»[15].* Беренче чорда яңа методны тәгаенләп бетерү шактый кыен була, бу хәл әлифбаларда да чагылыш таба.

Бөтен сүзләр методы бердәнбер дөрес һәм нигезләнгән дип табылса да, әле күп педагоглар элеккеге гадәт буенча аваз методы белән укытуны дәвам итә. Бөтен сүзләр методы зурларны укырга-язарга өйрәтүдә аеруча уңайлы дип табыла, чөнки, әлифба авторлары әйтүенчә, олы кешегә бер дәрес дәвамында бербөтен мәгълүмат, белем алу мөһим, ә аерым авазларны өйрәнүгә корылган аваз методы мондый мөмкинлекне бирми; дәрес дәвамында бер (ике) генә хәрефне (авазны) үзләштерү олы кешенең психологиясенә туры килми, аның өчен билгеле бер уңышка ирешүен, төгәлләнгән мәгълүмат алганлыгын күрү мөһим. Бөтен сүзләр методы исә бер дәрес кысасында аерым бер җөмләне (тулы бер мәгълүматка ия булган сөйләм кисәген) мәгънәви яктан аңлап, аны тулаем кабул итү (бу башта укытучы артыннан кабатлап бару, аннан соң бергәләп һәм аерым-аерым уку юлы белән алып барылган), сүзләргә аеру, аларның язылышын, укылышын истә калдыру (бу бик примитив алым — тактага, плакатка язылган яисә кисмә хәрефләрдән төзелгән берәр җөмләнең машиналь рәвештә, аңламыйча, охшатып кына рәсемен дәфтәргә күчереп алу рәвешендә алып барылган), истә калдырылган шул сүзләрне таный белү, башка чыганаклардан табып алу, иҗекләргә һәм, ниһаять, авазларга (хәрефләргә) аерырга өйрәнү һәм шулардан яңа сүзләр төзүдән гыйбарәт[16]. Дәрес материалы итеп укучыларга яхшы таныш булган, аларның тормышы белән бәйләнешле булган сүзләр сайланган. Бер дәрес эчендә билгеле бер эчтәлеккә караган тулы мәгълүмат алу олы кеше өчен зур мәгънәгә ия булган. Шуңа күрә бу методка күп педагоглар өстенлек бирә.

---

[14] Ибраһимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана // Татарская книга: страницы истории = Татар китабы: тарихи сәхифәләр. — Казань, 2012. — С.153.

[15] Корбангалиев М., Бәдигый Х. Укый-яза белмәүчеләр мәктәпләрендә укытучылар өчен кулланма. — М.: Тип. ВЧК л/б, 1924. — Б.11.

[16] Бу турыда тулырак кара: Корбангалиев М., Бәдигый Х. Укый-яза белмәүчеләр мәктәпләрендә укытучылар өчен кулланма. — М.: Тип. ВЧК л/б, 1924. — Б.12 — 13; Муртазина Л.Р. Педагогическая деятельность ликбезов в 20-40-е годы XX столетия (на примере Республики Татарстан): Дисс. … к. пед.н. — Казань, 2003. — С.117-119.

Беренче чорда М.Корбангалиев аны методик яктан нигезләп, яклап чыга. 1925 елның 16-19 июлендә Казанда узган татарлар арасында наданлыкны бетерү конференциясендә М.Корбангалиев һәм М.Арсланов комплекс системасын һәм бөтен сүзләр методын яклап чыгыш ясыйлар һәм шул принципларга нигезләнеп төзелгән әлифба һәм башка дәреслекләрнең кимчелекләрен дә аерып күрсәтәләр. Мәсәлән, алар әлифба авторларын *«эшче-крестьян массасының түбән катлавын авыр аңлана торган рус һәм гарәп сүзләре урынсыз куллануда, кирәкле материалның тиешенчә бирелеп бетерелмәвендә яисә, киресенчә, чамадан тыш күп бирелүендә, татар тормышыннан алынган матур әдәбият әсәрләреннән өзекләрне бик аз бирүдә»* тәнкыйтьлиләр[17]. Әмма озак та үтми, бөтен сүзләр методы кискен тәнкыйтькә дучар була һәм ликбез системасыннан кире кагыла. 1927 елда татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләренә багышланган I Бөтенсоюз конференциясендә галим «Укырга-язарга өйрәтү методының асылы» дигән темага чыгыш ясый, бөтен сүзләр методын җитди анализлап, аның төп кимчелекләрен күрсәтә. Бу фикерләр аның башка хезмәтләрендә дә чагылыш таба. Гомумән алганда, М.Корбангалиев, беренче чорда заман шаукымына бирелеп, «Америка ысулы»н яклап чыкса да, татарларда аваз методын фәнни нигезләүдә зур эшчәнлек күрсәткән галим буларак педагогика тарихына кереп калды[18]. Бу конференциядән соң төзелгән әлифбалар аваз методына нигезләнә башлый һәм ВКП(б) ӨКның 1931 елның 5 сентябрь карары нигезендә аерым предметларга бүлеп укыту (ягъни комплекс системасын кире кагу) һәм авазлар методына кучу турындагы карар кабул ителгәннән соң[19] әлифбалар төзүдә элеккеге методлар бөтенләй кулланылмый башлый, бу өлкәдә экспериментлар башка күзәтелми.

Зурлар әлифбасы ике өлештән гыйбарәт: әлифба һәм әлифбадан соңгы, ягъни укый-язу күнекмәләрен ныгыту чоры (әлифбаның кайсы чорын өйрәнүенә бәйле рәвештә белем алучыларны шул рәвешле атап йөрү тәҗрибәсе дә булган). Текстлардан гыйбарәт булган икенче өлеш мәктәп әлифбалары белән чагыштырганда күпкә күләмлерәк. Бу олыларның белемнәрен истә калдыру һаҗәте зуррак булу белән бәйле, чөнки укуларын аз белемлеләр мәктәбендә дәвам итмәгән очракта аларда рецидив (уку күнекмәләрен югалту), күпмедер вакыттан соң кире ликпунктларга әйләнеп кайту куркынычы янаган. Дөрес төзелгән әлифба бу мәсьәләне хәл итүгә дә беркадәр булышлык иткән. Шуның өстенә, олыларны укытуда газета, плакат, төрле китаплар да актив кулланылган. Әлифбаларда олы кешенең тормышында кирәк булган рәсми кәгазьләрне тутырырга өйрәткән материаллар да очрый. Бу да, үз чиратында, заман таләбе нигезендә эшләнгән.

Әлифбалар эчтәлегенә караган тагын бер үзенчәлек — аларның олылар тормышын бөтен киңлегендә колачларга омтылулары. Мәсәлән, аналар һәм балалар, бала тәрбияләү, балаларның сәламәтлеген саклау кебек мәсьәләләргә багышланган текстлар, грамотага гына өйрәтеп калмыйча, бигрәк тә авыл шартларында гомер кичерүче әниләрнең бу өлкәдәге белемнәрен арттыруга да ярдәм иткән. Г.Дистанов һәм В.Бурнашларның «Яңа ил. Авыл өчен» әсбабы шундыйлардан[20].

30 нчы елларның урталарыннан татар

[17] Сафин М., Газиз Р. Наданлыкны бетерү мәктәпләренең программы (методик күрсәтмәләр белән). — Казан: 1926. — Б 16.

[18] Ибраһимов Ф.И.Белем әлифбадан башлана // Татарская книга: страницы истории = Татар китабы: тарихи сәхифәләр. — Казань, 2012. — С.153.

[19] Ибрагимов Ф.И. Развитие методики обучения татарской грамоте и буквари. Автореф. дисс. … к.пед.н. — Казань: 1969. — С.43.

[20] Дистанов Г., Бурнаш В. Яңа ил. Авыл өчен. (Зурлар әлифбасы). — Казан: 1930. — Б.86-88.

телендәге барлык башка дәреслекләр кебек үк зурлар әлифбалары да үзләренең милли йөзләрен бөтенләй югалта, совет педагогикасының гомуми кануннары нигезендә үсеш ала. Бу күренеш моннан соңгы чорларда да дәвам итә.

20 нче елларның икенче яртысында татар графикасын латинга күчерүгә бәйле рәвештә, әлифбалар да яңалифкә күчә башлый. Бу эш бик четерекле һәм авыр бара. Чөнки гарәп графикасында укый-яза белгән халык янәдән яңа грамота үзләштерү эшенә керешергә тиеш була. Бу халык арасында беркадәр каршылыклар тудыра, әмма илдә барган вазгыять таләп итү сәбәпле, яңалиф нигезендә дә укый-язарга өйрәтү буенча эш җәелдерелә. Яңа әлифбалар әзерләнә. Күчеш чорының үзенчәлеге итеп катнаш (комбинатив) дәреслекләр (алар берьюлы ике графиканы берләштергән) барлыкка килүне күрсәтергә мөмкин. Аларда төп уку материалы латин, методик күрсәтмәләр гарәп язуында бирелгән (мәсәлән, Ш.Рамазанов белән Х.Мәхмүтовның «Зурлар өчен яңалиф сабаклары» әлифбасы)[21]. Бу чорда «комбинатив метод» атамасын билгеләүдә кайбер фикер төрлелеген дә күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, Х.Зәйни һәм Ф. Исхаковларның «Крестьян әлифбасы», авторларның үзләре күрсәтүенчә, комбинатив метод нигезендә төзелгән. Ләкин алар, алдагы әлифбадан аермалы буларак, бу терминны бөтен сүзләр методын нигез итеп алып, татар сүзләрен әйтүдә күбрәк туры килгән аваз методына беркадәр ияреп эшләү дип аңлыйлар[22]. Бу метод башка кайбер әлифбаларда да күзәтелә, һәм ул күчү чорының бер үзенчәлеге буларак карала.

Г.Нугайбәк авторлыгында дөнья күргән әлифба[23], үзенчәлекле әсбап буларак, башкалардан беркадәр аерылып тора. Аваз методына нигезләнгән бу әлифбада хәрефләр кулланылыш ешлыгы кимү буенча урнаштырылган, ягъни беренче чиратта татар сүзләрендә иң еш очрый торган, аннан соң кимрәк кулланыла торган хәрефләр бирелгән. Шул елларда дөнья күргән башка әлифбалардан аермалы буларак, ул графикалар алмашынган чорның үзенчәлекләрен истә тотып эшләнгән: анда хәрефләр өч төрле язылышта — гарәп, латин һәм рус графикасында бирелгән. Бу, әлбәттә, яңа алфавитны үзләштерүдә дә, шулай ук рус хәрефләре белән танышa торуда да (ликпунктларда рус теле дә укытылган) уңайлы булган.

30 нчы елларның икенче яртысында дөнья күргән әлифбалар, моңарчы нәшер ителгәннәреннән аермалы буларак, бары тик укырга һәм язарга өйрәтүне генә максат итеп ала[24]. Бу яктан караганда алар тышкы кыяфәтләре белән дә, эчтәлекләре белән дә XX гасырның икенче яртысы, хәтта 80 нче елларында басылып чыккан балалар әлифбаларыннан әллә ни аерылмый. Зурлар өчен әлифбалар әзерләү эше, 1939 елда беренчел укый-яза белмәүчелек (азбучная неграмотность) нигездә бетерелү сәбәпле туктала. Ләкин әле Бөек Ватан сугышы чорында да аз белемлеләрне, Кызыл Армиядә хезмәт итүчеләрне укыту эше дәвам итә[25]. Укый-яза белмәүчеләрне укыту буенча 50 нче еллар азагында дөнья күргән методик әсбапларның булуы бу эшнең әле озак вакытлар дәвам итүен раслый. ■

---

[21] Зәйни Х., Исхаков Ф. Крестьян әлифбасы. — М.: СССР халыклары ҮН, 1928.

[22] Нугайбәк Г. Әлифба. Зурлар өчен. — Казан: Яңалиф, 1927. — 16 б.

[23] Кульбиков З. Зурлар мәктәбе өчен әлифба. Төзәтелгән 2 нче басма. - Уфа: Башк. Дәүл.нәшр., 1935. — 75 б.

[24] Муртазина Л.Р. Педагогическая деятельность ликбезов в 20-40-е годы XX столетия (на примере Республики Татарстан): Дисс. ... к.пед.н. — Казань, 2003. — С.52-53.

[25] Укый- яза белмәүчеләр һәм аз укый-яза белүчеләр өчен программалар. Татар теле. — Казан: Татгосиздат, 1952. — 22 б.; Укый-яза белмәүчеләрне укыту буенча инструктив-методик күрсәтмәләр. — Казан: Татар. кит.нәшр, 1958. — 62 б.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә башлангыч сыйныф дәресе. Якынча 1904 ел

ӘХЛАК*

К.Бикколый, Г.Госмани

1.КҮРКӘМ ХОЛЫК

Ислам динендә иң хөрмәтле булган нәсрә күркәм холыклы, ачык йөзле булмактыр. Күркәм холык — шундый кадерле сыйфаттыр, ул хуҗасына файдадан башка һичнәрсә китермәс.

* Бикколый К, Госмани Г. Әхлак: Мәктәб ибтидаиянең соң сыйныфлары өчен тәртиб ителде. – Казан: Кәримовлар нәшр., 1911. – 35 б. Китапның титул битенә авторлары «мелла Касыйм Бикколый вә мелла Г.Госмани» дип күрсәтелгән. Касыйм Бикколый, ягъни Бикколов – күренекле мәгърифәтче, Буа өязе Яңа Тинчәле авылы мөгаллиме, мулла. Г.Госманиның исеме күрсәтелмәгән. Мөгаен ул Гаяз Госмановтыр. Бу шәхеснең исеме вакытлы матбугат битләрендә мулла, Буа хәйрия җәмгыятенең ревизия комиссиясе әгъзасы буларак искә алына.
Әсәр кече һәм урта яшьтәге мәктәп укучыларына, мәдрәсә шәкертләренә адресланганлыктан, тулысынча диярлек хәзерге татар әдәби телендә тәкъдим ителә.

Дөньяда иң бәхетле кеше — күркәм холыклы кешедер. Күркәм холыктан артык һичбер дәүләт вә нигъмәт булмас. Сез, шәкертләр, күркәм холыклы булып, дөнья вә ахирәт сәгадәтенә ирешеп, ата-аналарыгыздан, нәсел вә карендәшләрегездән рәхмәт алыйк дисәгез, яман вә явыз холыклардан сакланып, яхшы вә изге холыкларга гадәт итегез. Насыйп булса, бу китапта яман вә ярамас холыклардан күбесе бәян ителер. Алардан сакланырга тырышыгыз! Ачык йөзле, татлы сүзле булып, юк нәрсә өчен кешегә ачуланып, адәмнәрне рәнҗетерлек каты сүзләрдән сакланса-гыз, олуглар вә остазларның сүзе илә генә гамәл кылсагыз, иншаллаһ, күркәм холыклы шәкертләрдән булып, дөнья вә ахирәттә бөек мәртәбәләрне табарсыз.

Галимнәрнең олугы Мөхәммәд әл-Җәвад хәзрәтләре: «Гүзәллек йөздә булмаенча, телнең татлы булуындадыр», — димеш. Бер кеше никадәр матур вә күркәм йөзле булса, яман сүзле булып, явыз холыклы булса — дөньяда иң кабахәт кеше шулдыр.

Аның күркәм йөзе һичнәрсәгә ярамас. Гакыллы адәмнәр кешенең йөзенә карамый, холкына карарлар. Көләч йөзле, татлы сүзле, күркәм холыклы

булган бер бала, ямьсез булса да, холыксыз, матур йөзле балаларның меңеннән артыктыр. Димәк, күркәмлек йөздә булмаенча, күркәм холык вә гакылдадыр.

Димәк, балалар, сөемле вә мәхәббәтле буласыгыз килсә, гүзәл холыклы булырга тырышыгыз. Мәктәпләргә йөреп сабак укырга тырышып, китаплар карарга гадәт итсәгез, яхшы холыклар илә ярамас холыкларны аерырсыз һәм күркәм холыклы булып, бөек дәүләтләрне табарсыз.

2. ГАДЕЛЛЕК

Күркәм холыкларның иң гүзәле, вә яхшы сыйфатларның иң олугы — гаделлектер. Һичбер кешенең хәтеренә карамый, хәтта үз файдаңны да күзләми тугрылык илә эш итү — гаделлектер. Гаделлек — ислам динендә генә түгел, бөтендөнья халкы каршында күркәм күрелгән изге сыйфатлардандыр. Байларның малы, падишаһларның мөлкәте, хәтта бөтен дөньяның төзек торуы гаделлек аркасында гынадыр. Пәйгамбәребез: «Дәүләт ислам илә тормас, бәлки гаделлек илә торыр», — димештер.

Ягъни мөселман булып, никадәр яхшылыклар кылсаң да, гадел булмасаң, дәүләт синең кулыңнан ычкыныр. Дөньяга никадәр олуг падишаһлар килеп, җир йөзенә хуҗа булып торсалар, һәркайсы гаделлек аркасында тормышлардыр. Золымлылык илә һичбер мәмләкәт вә һичбер дәүләт дәвамлы булмас, бик тиз һәлак булыр. Сез, балалар, мондый хөрмәтле күркәм холыклы булырга кечек вакытыгыздан ук өйрәнегез. Кечек вакытта өйрәнгән нәрсә ташка язылмыш кеби, һич югалмас, даими сездә калыр. Гадел булсагыз, бөтендөнья халкы сезгә рәхмәтләр укып, җир вә күк әһеленнән дога вә фатиха булып, дөнья вә ахирәт изгеләреннән булырсыз.

3. ЗОЛЫМ

Кешене кул вә тел илә рәнҗетү, яки кешенең малын вә нәрсәсен талап алу — золымлыктыр. Гаделлек — никадәр күркәм сыйфатлардан исә, аның киресе — золымлык — шулкадәр олуг җинаять вә ярамас сыйфатлардандыр. Залим, ягъни кеше рәнҗетүче — дөнья вә ахирәт хараплыгына төшкән бәхетсез кешедер. Бер кеше үзенең кардәшенә усаллык кылса, кирәк аның малын вә нәрсәсен алу илә булсын вә кирәк аның хакында яман сүз сөйләү илә аның зарарына йөрү илә булсын — болар барчасы золымлыктыр. Пәйгамбәребез: «Залим кеше — мөфлис**» диде. Кеше рәнҗетүче дөньяда бай яки түрә булса да, ахирәттә аның кылган изгелекләрен рәнҗегән кешегә алып бирерләр дә бу кеше һич гамәлсез, изгелексез калып, дөньяда бер тиене булмаган гаҗиз, мохтаҗ кеше кеби кыямәт көн мөфлис булып калыр. Галимнәр гөнаһларның арасында золымнан (кеше рәнҗетүдән) олуг гөнаһ юктыр, диделәр. Башка гөнаһларның җәзасын Аллаһы Тәгалә ахирәткә калдырса да, кеше рәнҗетүченең гөнаһына сабыр итмәс, бәлки аны дөньяда ук җәза кылыр. Золымлык — бәрәкәтне бетерер, адәмнәр арасына фетнә салыр. Ул җирнең һәлак булуына сәбәп булыр. Әмма золым итү илә һичкем файда күрмәс, бәлки золым итүче үзенә дә һәм кешегә дә зарар гына китерер.

Әүвәл заманда Мисыр шәһәрендә бер кешенең хөрмә куагы һәр ел алтмыш капчык хөрмә бирә иде. Шул заманның падишаһы бу куакка кызыгып, куакны иясеннән җәберләп тартып алды. Әмма ул елда куак бер хөрмә дә бирмәде. Димәк, золымлыктан файда юктыр.

Дәвамы бар

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде* ■

** Мөфлис — бер тиене юк, иң фәкыйрь, мохтаҗ, гаҗиз кешедер. Авторлар искәрмәсе.

И, ТУГАН ТЕЛ...

2014 елның 10-13 августында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан татар теле һәм әдәбияты укытучыларының VI Бөтенроссия корылтае үткәрелде.

Корылтайда татар теле һәм әдәбияты укытучылары, мәгариф оешмалары җитәкчеләре, мәгариф өлкәсендәге муниципаль идарә органнарының милли мәгариф һәм төбәкара хезмәттәшлек буенча методистлары, югары уку йортлары һәм фәнни оешма, милли-мәдәни автономияләр һәм Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре катнашты. Рос-

сия Федерациясенең 30 төбәге һәм Польша, Литва, Казахстаннан 200 делегат һәм Татарстан Республикасыннан 400 делегат килде.

Пленар утырыш 2014 елның 11 августында Татарстан Республикасының Фәннәр Академиясендә узды. 12 августта Саба муниципаль районы җирлегендә секция утырышлары үткәрелде, корылтай эшенә йомгак ясалды. ■

1998 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Ислам Әхмәтҗанов

«Роальд Сәгъдиев «Идел-Пресс» басмаханәсенә беренче тапкыр Россия Дәүләт Думасы депутаты Фатыйх Сибагатуллин белән килде. Цехларда йөрдек. Роальд Зиннуровичның сораулары күп булды: тәүлегенә ничә сумлык продукция бирәсез, татар китабына ихтыяҗ бармы, тиражлары күпме, нигә безнең китапларны Мәскәүдә дә күреп булмый? Академигыбызның соңгы соравы нык кызартты үземне: ник дигәндә, Мәскәүдә түгел, Казаныбызда да татар китабын сата торган кибетләр саны бер-икедән дә артмый лабаса! Чәй янындагы сүзебез дә татар әдәбияты, аның бүгенге хәле тирәсендә тәгәрәде. Роальд аганың олырак яшьтәге язучыларыбыздан, аларның әсәрләреннән хәбәрдар булуы мине бик сөендергән иде.

Түгәрәкләп шунысын да әйтим: сөйләшү газиз ана телебездә барды. Дөрес, академик абзыебыз кайчагында тәңгәл сүз эзләп тукталып калгалады, әмма без, әңгәмәдәшләре, аны сөйләмнең бер бизәге рәвешендә генә кабул иттек».

1996 ел

«Вакыт агышын, ике куллап ябышсаң да, туктатып булмый. Чаба да чаба ул. Баксаң, безнең — Татарстанның — «Аэростан» авиакомпаниясенә караган ИЛ-76 самолёты экипажына кагылышлы вакыйгага да (1995-1996 еллар) инде егерме елга якын вакыт узган икән.

Татарстан очучыларының 379 тәүлек дәвамында әфган талиблары әсирлегендә булганлыгын хәтердә яңартыйк. Әфганстан гаскәрләренә корал ташуда гаепләгәннәр иде аларны.

...Егетләребез, әсирлектә булуларына карамастан, кул кушырып ятарга теләмиләр. Аэропорттагы очкычлар ничек урнашкан, эш тәртибе ничек, сакчыларның уяулыгы тәүлекнең кайсы вакытында кими төшә — тәүге карашка вак тоелган бернәрсә дә игътибардан читтә калмый. Һәм көннәрдән бер көнне, сакчыларның ваемсызлыгыннан файдаланып, үзләренең очкычларына утырып, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә очалар.

Әлеге фоторәсем 1996 елның 18 августында Казан аэропортында гаярь егетләрне каршылау вакытында төшерелгән. Халык хәйран: якыннары, республика җитәкчелеге, журналистлар. Беравыктан сораулар «ява» башлады. Үзенчәлекле пресс-конференциягә әйләнде бу очрашу».

«МИНЕМ ШӘҖӘРӘДӘ –
БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫ» КОНКУРСЫ

УФАЛЛА АРБАСЫ

Мин Бөек Ватан сугышында катнашкан бабайны күреп белмим. Аның турында сөйләгәннәре генә колак төбендә чыңлап тора. Әниемнең этисе — дәү әтием Рәүф Закиров тумышы белән Апас районы Keчe Болгаер авылыннан. Шунда туган, шунда гомер кичергән. Инде менә җитмешне узып сиксән ягына чыкты. Үз әтисен күрергә насыйп булмаган аңа. Шуңа күрә ул сугыш турында киноларны да яшь аралаш карый. Ашаганнан соң берәр оныгы ипи кисәген калдырса, орышып та ала. Кулларыбызны чаккан кычытканга да мөнәсәбәте үзгә: чабып атмый ул аларны, ә калын җепләр белән себерке итеп бәйләп, маллар өенә — абзарга кертеп элә. «Кычыткан безне ач үлемнән саклап калды», — ди. Безнең өчен тәмсез булган әрем исен дә яраттырды, бабайның дару үләне дип таслап җыеп, чоланга куябыз хәзер. Алабута күргәч, һәрберебез бабай шигырен мәзәк итеп кабатлый: «Алабута, алабута. Аны ашагач, эч авырта. Ипи бирегез!» Әмма бабай көлми, авыр сулап кына куя. Ачуланмый да. Кайвакыт печенье-кәнфитләр тотып чабып үтсәк, аркабыздан сөеп кала. Кичләрен һәммәбез дә телевизор каршына җыелгач, кайбер көнне яшьлеген искә ала ул. Аеруча Габделфәт Сафинның «Уфалла арбасы» җыры клибын караганда күңеле нечкәрә. Җитмәсә, үзебез дә бертуктаусыз сораулар бирәбез: «Уфалла арбасы да буламыни?», «Нигә печәнне трактор гына кайтармый?».

Авыр язмыш кичергән минем бабай. 1941 елның көзендә этисе — дәү бабам Габделәхәт фронтка китә. Дүртенче баласын көткән дәү әбием Камәриянең ниләр кичергәнен чамаларга гына кала. Өйләре җиргә сеңгән, салам түбә... Әнә, уракка дип киткәч, биш яшьлек кызы, уенга бирелеп, карап торган бердәнбер самавырын яндырган. Өч яшьлек улы, саламнан йомарланып ясалган туп тибеп, тәрәзәсен ваткан. Кышкы салкыннар җитә, ничек итеп яктылык чыганагы булган тәрәзәсен ясатырга? Җитмәсә, «продналог» дип үзәккә үтәләр. Сыерын асрарга да хәленнән килми ичмасам. Колхоз кырларын тырмаларга барган җирдән тырмага басып, аягын имгәткән сыеры 5 көн дигәндә җан бирә. Сталин «сыеры» — кәҗә юнәтеп, җан асрарга туры килә. Шул авырлык давылында 1942 елның мартында бабам дөньяга аваз сала. Озак та үтми Габделәхәт Закиров яу кырында хәбәрсез югалды, дигән кара кәгазь килә. Аның кая югалганы соңгы елларда гына билгеле булды. Волхов фронтына эләгеп, әсирлеккә төшкән икән. Менә шунда ачлыктан интегеп, вафат булган бабай. Таза гәүдәле була ул. Әле хәзер дә авылда аның турында риваятьләр йөри. Имеш, ат арбасына ашлык төялгән олауларын бер кулы белән генә күтәреп куя икән. Хезмәттәше исән кайткан, дәү әбиемә ул сөйләгән. Имеш, бабайның мәетен

5-6 немец солдаты камерадан сөйрәп чыгып, туганнар каберлегенә күмгән, ди. Узган елны ул каберлекне дә таптык. Дәү әтинең бертуган апасы, сугыштан соңгы авыр елларда бәхет эзләп, Украинага чыгып китә. Гаиләле булгач, шунда яшәп кала. Әнвәр исемле улы дәү бабайның күмелгән урынын эзләп таба, фотосын безгә дә җибәрде. Сүз уңаеннан, шунысын да әйтим, Славянскида гомер кичергән Әнвәр абый Украинадагы мәхшәр вакытында зыян күреп, хастаханәдә ятып чыкты. Сугыш булган да беткән түгел, сугыш хәзер дә дәвам итә, димәк. Тик мин аның нәрсәгә кирәк булуын гына ачыклый алмыйм әле. Анысы башыма сыймый.

Асилә Закирова,
2 нче гимназия укучысы.
Казан шәһәре ■



Минем нәсел шәҗәрәм

Смоленскиның Аристовка авылы янындагы туганнар каберлегенә куелган һәйкәлдә Габделәхәт Закиров исеме дә бар

КЕМ УЛ – АБДУЛЛА БАТТАЛ?!

Фәрит Баттал

Аргументлар булмагач, Абдулла абыйның артык ышанучанлыгына хәтта без дә ышана башладык. Фәрит абый белән бу хыялыбызның тиз арада тормышка ашуы әле дә шикле (инде ул да вафат). 50 нче елларның ахырларында «җәлилчеләр»дән «хыянәтче» тамгасын бетергәннәр, тик Батталга гына аны «беркатлы» дигән тамгага алмаштырганнар. Шулай килеп чыга…

Рафаэль Мостафин әйтүенчә, легиондагы Шамбазов исемле әсир-рәссам, допросларда имеш-мимешләргә сылтап, Җәлилне җәзалап үтермәгәннәр, ул немецлар белән бергә Көнбатышка качкан, дигән. Шамбазов күрсәтүенә таянып, Җәлилне хыянәтче дип санап, 1946-1952 елларда аңа каршы җинаять эше кузгаталар. Бу сылтаманы тикшерер өчен «компетентлы органнар»дан хәтта Көньяк Америкага да махсус кеше җибәрәләр… Нигә соң әле Җәлил турында ишетелгәнне шулай нык тикшерәләр, ә Баттал турында гайбәт дәвам иттерелә — яшерен булмаган шундый чыганаклар була торып та?! Артык ышанучанлыгын монда кем күрсәтә соң, «мөхтәрәм язучыларыбыз һәм тарихчы галимнәребез» түгелме?

***

Әсирлектә Җәлил шәп шигырьләр язган, шуңа күрә дә аның патриотик шигырьләренең бер өлеше туган иленә кайта алган, дип уйлыйм. Шуннан соң Җәлилне яшерен төркемнең оештыручысы һәм ялгышмый торган җитәкчесе,

дип саный башлаганнар. Иконников хатларында, дата итеп, 1980 нче ел күрсәтелгән, ә Рафаэль Мостафин аларны беренче мәртәбә 2006 елда гына бастыра. Димәк, бу тарихи вак-төякләр киң җәмәгатьчелек өчен егерме алты ел буена сер булып торган!

Иптәшләренә биргән сүзендә торып, Фәрит Солтанбәков Баттал турындагы хатирәләре белән 2001 елда гына, китап язып, уртаклаша алган, анысы да (китап чыгаруы) балалары һәм бер киявенең матди ярдәмендә. Фәрит абый сөйләгәнчә, Абдулла абый үз мәзәкләре, шаян сүзләре белән иптәшләренең күңелләрен гел күтәреп торган, дуслары төшенкелекне, тоткынлыкта булуларын да онытып җибәргән. Рафаэль Мостафин әйтүенчә, шуның өчен фашистлар Батталны ае-

Ахыры. Башы журналның 8 нче санында

Муса Җәлил көрәштәше Абдулла Батталның абыйсы очучы һәм шагыйрь Салих Баттал белән дә дус булган. 1929 еллар

рым камерада тотарга тырышкан. Әллә шундый киң күңелле, җор холыклы булганга — Абдулла абыйны бүтәннәр өчен «яшен уздыргыч» итеп сайлаганнармы, дип тә уйлый башладым мин.

Тарих фәннәре докторы, Абделхан Әхтәмҗан «Муса Джалиль и его соратники в Сопротивлении фашизму» исемле китабында Баттал турында болай дип яза: *«Именно к нему, человеку доверчивому, эсэсовцы подсадили провокатора, который и навёл на след подпольной группы»* (94 бит); Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» спектаклендә дә Баттал иптәшләре алдында үкенә: *«Сез бит беләсез, мин бит ышанучан кеше. Әнә шул ышанучан булуым аркасында монда килеп каптык! Мине бит кешеләргә ышанырга өйрәттеләр; кеше булгач — минем өчен барысы яхшы. Кемнең чын кеше, кемнең сатлык җан икәнен аера алмыйм...».* Шагыйрь Ренат Харис «Җәлилчеләр» поэмасында Батталның гаеп хисеннән өзгәләнүен күрсәтергә тырыша:

— Сатлык җанны таный алмадым
һәм күрсәттем җепнең очын мин.
Вөҗдан газабының ялкынын
йотып янам шуның өчен мин...

...Бу юллар әле ихтирам белән язылган, ә менә Диас Вәлиевнең «День «Икс» пьесасында (1986 елда сәхнәдә бер куелып, ул тиз онытылган да) Абдулланың иптәшләреннән берсе ярсулы тавыш белән: *«Ну, почему Баттал ляпнул, что восстание состоится четырнадцатого! Ну, почему...»,* — дип кабатлый. Минемчә, Кормаш төркеме әгъзалары турында «яңа ачылган», ә чынбарлыкта күптән билгеле булган фактларга таянып язылган пьесаның өченче варианты килеп чыгуы дөрес булыр иде.

Юриспруденциядә: *«Шикле фаразлар гаепләнүче файдасына юралырга тиеш»,* — дигән кагыйдә бар. Нигә соң җинаять ясаганнарга карата кулланыла торган бу кагыйдә патриот булып танылганнарга карата кулланылмый? Менә шулай, Кормаш белән Баттал

әлегә төркемнәрендә ике «полюс» булып кала: беренчесен шуның җитәкчесе итеп танып бетермиләр, икенчесен исә халыкта Германиядә булган бөтен яшерен челтәрне беркатлылыгы аркасында ачкан кеше, дип саныйлар.

2008 елда Мари Республикасында урнашкан «Кичиер» санаториесында ял иткәндә, мин санаторий китапханәсендә Мари Республикасы районнарына багышланган берничә китап күрдем. Мәсәлән: «История сёл и деревень Республики Марий Эл. Сборник документальных очерков». Бәрәңге районына багышланган китапның 158 битендә, Кормаш укытучы булып эшләгән Куян авылы турында шундый юллар таптым: *«Немало подвигов совершено куянковцами на фронтах и в тылу. Особое предпочтение жители деревни отдают своему земляку Гайнану Курмашеву, боровшемуся с фашистами в плену рядом с поэтом-героем Мусой Джалилем. Г.Курмашев героически погиб, возглавляя антифашистскую подпольную группу в концлагере».* Күргәнегезчә, авторлар бөтен нәрсәне үз исемнәре белән атарга оялмаганнар һәм Җәлил ролен кечерәйтеп күрсәткәнбез, дип санамыйлар. Ә авторлар итеп монда «координационный и редакционный советы, комитет Республики Марий Эл по делам архивов, Государственный архив Республики Марий Эл, администрация муниципального образования «Параньгинский район», дип язылган.

***

Алты елга якын әзерләнеп, 2009 елда мин кызым Наилә белән, ниһаять, Германиягә барып кайттым. (Кызыбыз Наилә инглизчә иркен сөйләшә, ә немецлар бу телне аңлый.) Берлинда таныш тәрҗемәчебез Джон Нокс белән өчебез Штауффенбергштрассе урамындагы Герман Каршылык музеена бардык; Татар-башкорт мәдәни үзәгенең рәисе Венера Вәгыйзова, безгә юл күрсәтеп, Кормаш төркеме әгъзалары җәзалап үтерелгән урынны — Плетцензее төрмәсенең мемориаль өлешен карадык, хәтта Берлинның Шарлоттенбург районы ЗАГСында Абдулла абыйның үтерелүе турындагы таныклыкны да ала алдык. Герман Каршылык музееның компьютер базаларында Җәлилнең балачак рәсемнәреннән башлап, бөтен иҗаты диярлек чагылган, ә иптәшләренең — рәсемнәре дә, «үлем карточкалары» гына. Музей хәзмәткәре Андреас Хәрбст әфәнде (Andreas Herbst) Абдулла Баттал турында бөтен булган мәгълүматны үзенә җибәрүебезне үтенде. Казанга кайткач та без, аңа немец теленә тәрҗемә итеп, Абдулла абыйның биографиясен, берничә фоторәсемен юлладык. Берлиннан моңа җавап — «herzlichen Dank» алдык.

Гайнан Кормаш музее җитәкчесе Фәйрүзә Вәгыйзова белән элемтәгә кереп, шул ук елның декабрендә улым Камил белән әлеге авылга барып кайттым. Музейларын карап, мәктәп балаларына Берлинга баруыбыз хакында сөйләп, Кормашның туганнарына да кереп чыктык. Җәлил иптәшләренең үлгәннән соң орден белән бүләкләнүен монда белмәгәннәр дә, район үзәгендә — Бәрәңгедә Кормашка һәйкәл кую мәсьәләсе дә тынып калган.

2011 елның 25 августында, митингтан соң, Михаил Черепанов* мине абыйның фамилиясе телгә алынган хатлар белән таныштырды. Язучы Рафаэль Мостафинның легионерлар белән язышкан хатлары иде бу. Рафаэль әфәнде шуларны аңа васыять иткән булган. Хат авторлары язганча, Сәйфелмөлеков, Батталов, Хәсәновны немецларга хыянәтче Җәмалетдинов (Ямалетдинов) саткан.

Шул елны Михаил мине тагын бер «кызык» кәгазь белән таныштырды. Бу — Эстрин Е.А. исемле

* «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы Музей-мемориалы» мөдире.

берәүнең 2011 елның 15 гыйнварында Россия президенты аппаратына җибәргән «идеологик диверсия»се, «Казанның үзәгендә ун хыянәтче һәм фашистларның астыртын булышчыларына урнаштырылган барельефлар» турындагы әләге. М.Черепанов үтенече белән, мин аңа Татарстанның мәдәният министрлыгына тапшырыр өчен, Эстрин язуына бәя биреп җибәрдем. Аның бу соңгы хатына, юридик бәя дә биреп, массакүләм матбугат чараларында бастырырга тәкъдим иттем — әлбәттә, автор фикерен үзгәртер дип түгел, гайбәт ташкынын туктатып карар өчен генә. Аның бу «кисәтүләр»е белән җәнҗаллы, «Барбаросс инкыйразы» исемле, суд бәяләмәсе буенча Муса Җәлилнең намусына кагылган пьеса арасында нинди аерма бар соң?! Кызганыч, бер аерма бар монда: пьеса буенча Татарстандагы РФ Прокуратурасы каршындагы тикшерү комитеты яла факты нигезендә җинаять эше кузгатса, ә Эстрин «исх. 2015-221 от 13.04.2011» номерлы «белгечләр»дән генә чираттагы җавап ала. Шул җавап аны чираттагы «сигнал» язуыннан туктата аламы соң?

Ә 2011 елның 9 сентябрендә, ниһаять, миңа «Моңлы бер җыр» пьесасының авторы Туфан ага Миңнуллин җавап бирде. Аның белән очрашып сөйләшергә мин күптәннән тырыша идем. 25 августта митингта үзен күргәч, мәкаләмне кәгазьдә бастырып аңа тапшырырмын, дип килештек. «Син барысын да дөрес язгансың, шуңа күрә Абдулла Батталны гаепле итеп күрсәткән урынны пьесадан алып ташлармын», — диде Туфан ага. Күренекле драматургтан шундый сүзләрне ишетергә мин өметләнмәгән дә идем… Чыннан да, «Яңа Гасыр» телеканалы фондындагы пьеса язмасыннан ул урын юкка чыккан.

Кормаш төркеменең тарихын ныграк беләсе килеп, бервакыт, моны немецларның үзләреннән сорашып була бит, дигән фикер башыма килде. Берлиндагы Герман Каршылык музееның 2009 елдан бирле безгә таныш хезмәткәре Андреас Хәрбст әфәндегә шундый сорау белән мөрәҗәгать иттем: «Бу темадан «Geschichtes Stunde» — «тарих дәресе»н алыр өчен безгә нинди дә булса белгеч белән очрашып булмасмы икән?» — дидем. Хәрбст әфәнде безгә Бернд Флорат (Bernd Florath) исемле хезмәткәренең электрон адресын биреп, аны нәкъ шул төркем тарихы буенча эксперт, диде.

Ниһаять, 2013 елның 23 июлендә мин кызым белән икенче мәртәбә Берлинга очып килдем. Кызыбыз Наиләгә карап, бу юлы чит илгә барыр алдыннан хәтта мин дә бераз немец телен өйрәнеп, хәл кадәри сөйләшеп тә йөрдем. Икенче көнне без Хәрбст әфәндегә кереп, аннан алган адрес буенча Флорат әфәнденең эш урынына киттек. Ул — «элекке

«Син барысын да дөрес язгансың, шуңа күрә Абдулла Батталны гаепле итеп күрсәткән урынны пьесадан алып ташлармын», – диде Туфан ага.

ГДРның хөкүмәт куркынычсызлыгы хезмәте документлары буенча федераль вәкаләтле вәкил» булып чыкты («Der Bundesbeauftragte für die Unterlagen des Staatssicherheitsdienstes der ehemaligen DDR»).

Бернд Флоратның безнең сорауларга биргән җавапларының асылы шул: 2002 елда Прага архивында Кормаш төркеме әгъзаларының «рейх дошманнары» булуын исбатлый торган мәгълүмат табылганнан бирле бүтән яңалык юк. Бу төркемгә кагылышлы бердәнбер документ (ассызымлап әйтәм — сүз нәкъ документлар турында бара) — тоткындагы кешеләрнең теркәү карточкалары. Герр Флоратның эш урыны — федераль архивның бер өлеше. Хәрби архив Фрайбургта ур-

Язма авторы Фәрит Батталл Туфан ага Миңнуллин белән әңгәмә вакытында. Уртада – галим Рәмил Исламов. 2011 ел, 25 август

нашкан. Хәрби суд архивы сугыштан соң Прагага күчерелгән, ләкин аның зуррак өлеше югалган, төркем әгъзаларыннан сорау алу протоколлары да сакланмаган. Легион солдатлары өчен төркем чыгарган газеталары да Фрайбургта булырга тиеш, тик алар хәзер дә укылмаган, чөнки рус, татар, гарәп хәрефләре белән бастырылган текстларны аңлаучы Германиядә табылмаган. Бу газеталарны профессор Абделхан Әхтәмҗан карап алырга җыена иде.

«Идел-Урал» легионындагы төркем немецларның пропаганда ячейкасы булып саналган. Ләкин татарлар һәм башкортлардан төзелгән беренче батальон Кызыл Армия ягына күчкәннән соң, гестапо, ул немецларга каршы агитация алып бара, дип шикләнә башлый һәм төркем әгъзаларын кулга алырга шул шик җитә дә. Гестапо өчен алар арасында аерма булмаган, барысы да «хыянәт» өчен хөкем ителгән. Төркемнәре фаш ителүендә дә кемнеңдер гаебен күрсәтә торган

Кемгәдер нахак гаеп тагылса, һәм бу гаепләнүче сезнең туганыгыз булса, ни эшләргә?!

фактлар юк. Җәзалап үтерер алдыннан барысын да коточкыч рәвештә газаплаганнар…

Германиядән кайткач та кайберәүләр мондый фикер әйтте: имеш, анда музей белән төрмәгә кереп чыгар өчен генә вакыт, акча әрәм итәсе идеме?! — диделәр. Алай икән, нигә соң кешеләр үз туганнарының каберләре янына барып, аларны чистартып кайта?! Сугышта катнашучыларның оныклары, торыннары, бабаларының һәлак булган урыннарын беләсе килеп, эзләп йөри?! Яу кырында ятып калганнарның сөякләрен эзләүчеләр экспедицияләргә китә?! Ни өчен архивлар эшли?! Кемгәдер нахак гаеп тагылса, һәм бу гаепләнүче сезнең туганыгыз булса, ни эшләргә?! ■

НИЗАМЕТДИННЫҢ ИКЕ УЛЫ

....
Рашат Низами

Бөек Ватан сугышында безнең нәсел-нәсәптән, төгәлрәге, Низаметдин бабамның гаиләсеннән ике улы катнаша – Мияссәр һәм Шәйхаттар.

Мияссәр — минем әтием була инде. 1918 елны Саба районының Олы Мишә авылында туган. Сугышка кадәр олау-кәрваннар белән Мишәбаш лесхозыннан Кукмара станциясенә утын, такта, агач материаллары, мылтык сабына прикладка дигән махсус пүләннәрне ташый идек, дип сөйләгәне бар.

Армиягә аны 1939-40 еллар арасында алалар. Фин сугышы барган вакытлар. Казанда 6 ай бронетанковый училищеда укыганнан соң, шофёр-тракторист «права»сы биреп, аларны Баку якларына илтеп урнаштыралар. Бервакыт төнлә, бу урыннан кучереп, Украинаның Сума өлкәсе Шостка шәһәренә алып китәләр. Шунда тягач, ягъни 77 мм.лы зенит тупларын тартып йөрү һөнәренә өйрәтәләр.

Берзаманны таң алдыннан тревога: сугыш! Немецлар юлына очраган һәр шәһәрне мототехника белән 15-20 чакрым читтән урап ала. Каты бәрелешләр һәм чигенүләр башлана. Әти тягач-трактор белән зенит тупларын тарттырып йөри. Еш кына немец самолётларын да бәреп төшерәләр. Сугышларның берсендә, ничек икәнен юньләп хәтерләми, машина газыннан исереп, җәйге болын уртасында төшеп кала ул. Аны икенче бер часть сугышчылары табып ала. Аңына килсә, сул кулы беләктән өзек, аның тирәсендә ак халатлы санитар кызлар кайнаша...

Аның портретын тулыландыру өчен, үткәндәге бер вакыйганы сөйләп китү урынлы булыр кебек. 1942 елның җәендә булса кирәк, Низаметдин бабам (Тукай яшьтәше — 1886 елда туган) йортына 25 яшьлек солдат-фронтовик кайтып төшә. Газиз уллары кайткан! Сугышта бер кулын терсәк төбеннән диярлек өздерсә дә, ул бит тере, исән-сау, аягында йөри — ничек инде моңа шатланмыйсың ди?!. Менә шул хөрмәткә идән асты туфраксасыннан адарынып куелган «чикүшкә»не табып алалар да өстәлгә чыгаралар.

Хәл-әхвәл сорашып, азмы-күпме пирәшләп алганнан соң, әти чирәмле ишегалдына чыга. Кинәттән күңеле тулып, янбакча рәшәткәләрен кочаклап елый башлый бу:

— Шушы яшемнән кулсыз килеш калдым... Чулак Мияссәр дип йөртерләр микәнни мине? Кызлар яны-

Мияссәр Низамиев. 1940 ел

Шәйхаттар Низаметдинов. 1945 ел

на ни йөрәгем белән барырмын?.. Их, шушы Гитлер сугышының әшәкелеге!..

Яшьлек хисләренә бирелеп, үзен юкка гына битәрләгән ул. Тота да, Балык бистәсенең Күки авылыннан Асия исемле кызны ярәшеп кайта. Яши торгач, ике малай һәм өч кыз үстерәләр. (1946 елгы Җәүдәт абыем хәрби очучы иде, самолёт сынаганда авиация фаҗигасенә юлыгып, 24 яшендә Россия күгендә һәлак булды.)

«Чулак» дигән сүздән куркуы да юкка гына... Баштарак завхоз, аннары озак еллар амбар мөдире булып эшләде, абруе-дәрәҗәсе бар, аңа бары тик «Мияссәр абый» дип кенә эндәшәләр иде.

Мин урта мәктәптә укыган елларда әтинең болай дип сөйләгәне бар: «Кышкы ачы җилләрдә сиңа берәү дә мендәр-карават әзерләп куймаган. Плащ-палатка, яисә шинелеңә төренәсең дә, йоклап китәсең. Кар астына казып төшсәң, бигрәк тә шәп, җылырак, җил юк, өшетми. Ләкин, иртән уянып киткәч тә, селкенә алмый җәфаланасың, чөнки буыннар кәбестә күчәнедәй каткан була. Ул гынамы, хәтта ипи дә бозланып каткан була. Аны күпвакыт пычкы белән турый идек».

Еллар узгач, мин әти турында «Яра» дигән шигырь яздым. Аның азагы болай тәмамлана:

Ерак булган сугыш... Ә ялкыны
Безнең дә бит җанны ялмаган.
Әткәйләрнең кулын кискән фашист,
Илнең кулын кисә алмаган!

Әти җитмеш яше тулар-тулмаста бакыйлыкка күчте. Ни кызганыч, мин аңа сугышта күргәннәрен, истәлек-хатирә итеп, аерым бер дәфтәргә язарга «заказ» бирә белмәгәнмен. Бик үкенәм. Юкса, бик күп хикәяләргә «тере» сюжет һәм детальләр тапкан булыр идем.

Соңрак, менә шуларны уйлаганнан соң, миңа акыл керде: аның бертуган энекәше Шәйхаттар абыйдан сугышта күргән-йөргән хәлләре турында махсус язуын сорадым. Рәхмәт аңа, язды

ул аны. Калын тышлы әлеге дерматин дәфтәр архивымда саклана. Андагы деталь-күренешләрне мин инде кайбер хикәя-повестьларыма кертеп тә җибәрдем.

Аның да туган елын әйтү фарыз: 1927 елгы. 17 яше тулгач, 1943 елда армиягә алалар. Мәскәү яны тирәсендә элемтәче һөнәренә укыталар. Ленинград фронтында финнарның Маннергейм линиясен өзгәндә, ул элемтә чыбыклары сузып, беренче сугышчан чыныгу ала. «Хельсинкига капка ачабыз!» дигән транспарантлар әле дә күз алдында», — дип көлә-елмая сөйли ул миңа.

Менә шуннан соң ул, Белоруссия һәм Украина җирләрен уза-уза, үз сүзләре белән әйткәндә, Берлинга хәтле җәяүләп барып җитә. Без, 50-60 килограммлы яшь солдатлар, 40 кило авырлыктагы элемтә катушкаларын ничек күтәреп йөрдек икән, хәзер дә гаҗәпләнәм, дип сөйләде ул миңа. Аның истәлек язмасыннан кайбер юлларны укып китик: *«Берлинга җитәрәк, немец самолётлары безнең өскә бик күп листовкалар ташлый иде. Янәсе, илебездән ераклашкан саен, үлемгә таба якынаябыз. Безгә бу листовкаларны укымаска кушалар иде. Ләкин җиңүнең якын икәнен болай да бик яхшы тоя идек. Безнең элемтә — «правительственная связь» дип атала. Димәк, ул Мәскәү-центр белән сөйләшү өчен даими-төзек, эшләп торырга тиеш. Командирыбыз Леонид Воля минага эләгеп һәлак булды. Берсендә, һич уйламаганда, ике антифашист солдат очрады безгә. Коралларын ташлаганнар, «Гитлер капут! Исән каласыбыз килә», — диләр. Без, аларның автоматларын җиргә күмдек тә, ирекклә җибәрдек.*

8 май төнендә сугыш авазы кимеде. Иптәшләрем ял итә... Менә шулчакта мин сугышның туктатылуы турында телефоннан беренчеләрдән булып ишеттем! «Безоговорочная капитуляция!» Уятып әйткәч, командирым баш астыннан пистолетын тартып чыгарды да, түшәмгә атып, беренче салютны бирде... Шулвакытта гына мин сугыштан исән калганыма ышандым».

Шушында туктатам. Шәйхаттар абыйның бу язмасында бер повестьлык материал бар. «Мин Сталинны унбиш метр чамасы яныннан күрдем» дигән сүзләренә ачыклык кертәсем килә.

1945 елның 17 июлендә халыкара Потсдам конференциясе ачыла (Берлиннан ерак түгел). Моның өчен 36 бүлмәгә һәм конференц-залга капиталь ремонт ясала. Бирегә Сталин, Трумэн һәм Черчилль килергә тиеш була. Шундый зур дәүләт эшлеклеләрен шушы илнең хәрбиләре өч боҗра белән уратып сакларга тиеш икән. Алдагы иң беренче боҗрада, билгеле ки, совет солдатлары урнаша. Рядовой Шәйхаттар Нәҗметдинов менә шулар арасында үрә катып сакта басып тора! Сталинны һәм Молотовны якыннан күрүе менә шушы тарихи мизгелләргә бәйле аның.

Герман җирендә ул тагын биш ел хезмәт итә. 1950 елның көзендә генә туган авылына исән-имин әйләнеп кайта. Миңа ул вакытта җиде ай чамасы булган. Колхозда эшли. Механик. Каян-ничек өйрәнгәндер, теләсә-кайсы маркадагы сәгатьләрне ул «ә» дигәнче сүтеп җыя һәм төзәтә иде. Кулында, һичшиксез, Германиядән алып кайткан саллы лупа булыр. Авылда иң беренче булып велосипед, соңрак мотороллер алучы да ул иде. Кайчакны, немецча сөйләшеп, авылдашларын һәм мине дә шаккатыра иде.

***

Бүгенге көндә 87 яшьлек Шәйхаттар абый Алабугадагы улы Инсаф һәм килене Сания гаиләсендә яши. Хәбәрләшеп торабыз. Бу язмам аңа, туганнарга сәлам һәм бер истәлек булып ирешсен! ■

ДАНЛЫ ЮЛ ЭЗЛӘРЕ

Хәнәфи Бәдигый

Милли каһарманыбыз Муса Җәлил һәм җәлилчеләр узган данлы юл – халкыбызның горурлыгы ул. Тамчыда кояш чагылгандай, анда милли яшәешебезнең тарихы да калку гәүдәләнә. Шуңа күрә герой-шагыйрьнең үлемсез иҗаты, җәлилчеләрнең тиңдәшсез, героик көрәше безнең өчен бүген дә гаять зур әһәмияткә ия.

Герой-шагыйрьнең тууына йөз ел тулуны билгеләп үткәндә Россия РФ Президенты Владимир Путин: «Каһарман шагыйрь иҗаты күпмилләтле, бай Россия мәдәнияте — аның кыйммәтле әдәби мирасының аерылгысыз өлеше, ә тормышы үз-үзен аямыйча югары әхлакый максатларга хезмәт итү, патриотизм, батырлык, каһарманлыкның чын, асыл үрнәге. Аның күңелгә үтеп керә торган шигырьләре бүген дә укучыларның йөрәгенә тәэсир итүдән туктамый, тарихи хәтерне һәм буыннар арасындагы ныклы бәйләнешләрне саклауда аеруча гүзәл миссия башкаралар», — дигән иде.

Билгеле, герой-шагыйрьнең тиңдәшсез иҗатын һәм героик көрәшен берничә җөмлә белән генә бәяләп бетерү мөмкин булмаса да, ил башлыгының каһарман шагыйрь иҗатына һәм тормышына карата биргән мондый югары бәясе безнең өчен бик кирәкле һәм аеруча кыйммәтле. Шуның белән бергә Муса Җәлил кебек герой-шагыйрьне үстергән татар халкының ил һәм дөнья мәйданында зур абруйга ия булуы үзеннән-үзе аңлашыла. Димәк, безгә ил башлыгының шул сүзләренә нигезләнеп тә, Муса Җәлил дигәндә татар халкын, татар халкы дигәндә, шагыйрь исемен тиешле урыннарда ешрак кулланырга кирәк!

Һәлак булуларына 70 ел үтеп баруга карамастан, герой-шагыйрь һәм аның тугрылыклы көрәштәшләре турында хәтер-истәлекләр яңарып, халкыбызның бу соклангыч батыр йөрәкле улларына карата булган ихтирам хисләренең арта баруы шул хакта сөйли.

Әйе, аларның тиңдәшсез батырлыклары ерак гасырларны кичеп, әдәби-гыйльми, кино, сәхнә, рәсем сәнгате телендә генә түгел, легенда-риваятьләргә, бәет-дастаннарга күчеп яшәрлек. Шуның белән бергә, җәлилчеләрнең уртак көрәшенә кагылышлы байтак рәсми доументларны эзләп табып, алардагы мәгълүматларны өйрәнеп,тәртипкә китереп, тулыландырып энциклопедик хезмәт әзерлисе бар. Кызганыч ки, бу турыда рәсми сөйләшүләр, киңәшүләр булса да, эшнең урыннан кузгалып киткәне юк әле хәзергә.

Сүз монда Муса Җәлилнең чынбарлыкта булган, әмма әлегәчә безгә килеп ирешмәгән «Моабит дәфтәрләре»нең тагын икесе, яисә башлангыч чордагы — Оренбург матбугатында басылып та, табып өйрәнелмәгән шигырьләре турында гына түгел, (гәрчә алар бик кадерле чыганаклар булса да), бәлки аларның яшерен оешма эшчәнлеге белән бәйле, эзләп табасы байтак җитди документлар турында бара.

...Бөек Ватан сугышы башлангач, Муса Җәлилнең тулаем иҗаты фашизмга каршы аяусыз көрәшкә чакыру-өндәүгә багышлана. 1941 елның 13 июлендә Муса Җәлил Ватанны саклаучылар сафына баса, 1942 елның 26 июлендә әсирлеккә эләккәнгә кадәрге шул бер ел эчендә ул «Соңгы көрәшкә»дән башлап, «Яулык» шигырен дә кертеп, 41 әсәр иҗат итәргә өлгерә.

Фашизм тоткынлыгында 1942 елның июлендә язган «Кичер, илем!» шигыреннән башлап, безгә мәгълүм булган соңгы — 1944 елның 1 гыйнварында язган «Яңа ел теләкләре»н кертеп, шагыйрьнең 94 шигыре «Моабит дәфтәрләре» дигән исем белән ике дәфтәре туган илгә кайтып ирешә.

Әмма аларның шулай ук тагын ике дәфтәргә теркәлүе билгеле. Аның берсе Римдагы илчелек аша Мәскәүгә тапшырылып теркәлгән, тик әле һаман да аның эзенә төшә алганары юк.

Шагыйрь тоткынлыкта 791 көн газап чигә. 1944 елның 12 февралендә Дрезденда җәлилчеләргә карата суд була, нацистлар аларны үлем җәзасына хөкем итә һәм алар 1944 елның 25 августында һәлак ителә.

Шагыйрь тотынлыкта фашистларның берсеннән-берсе хәтәррәк төрмә-лагерьлары, пычрак, сазлы абзарлары, ныгытма-бараклары, салкын, тар, юеш таш подвалларында газап чигә. Ул нацистлар басып алган Ленинград өлкәсенең Рождественский, аннан соң Двинский, Польшаның Демблин ныгытмасы, Варшава, Берлинның Моабит, Тегел, Шпандау күчмә төрмәләрендә газап чиккәннән соң, соңгысында — Плетцензеедa һәлак була.

Муса Җәлил иҗаты, һәм баштагы чорда аның исеменә карата булган ышанычсызлыкның бетерелүе, беренче чиратта әсирлеккә эләгеп тә, сугыш мәхшәреннән әйләнеп кайту насыйп булган йөз меңнәрчә фронтовикларны мыскыл итүләрдән, рәхимсез эзәрлекләүләрдән коткара. «Халыклар атасының» минем әсирләрем юк, хыянәтчеләр һәм сатлыкҗаннар гына бар» дигән мәкерле гыйбарәсе киң юл ачкан була ул эзәрлекләүләргә.

Шул үлемсез иҗаты, тиңдәшсез батырлыгы өчен шагыйрь Муса Җәлилгә 1956 елда Советлар Союзы Герое, 1957 елда Ленин премиясе бирелә. Берьюлы мондый иң югары ике бүләк бирелү әлегә кадәр бердәнбер очрак булып тора.

Герой-шагыйрь Муса Җәлил һәм аның тугрылыклы көрәштәшләре узган юлдан, аларның эзләре буенча йөреп, эзләп табасы документлар бик күп әле. Боларга шагыйрьнең тагын ике дәфтәре, Оренбург чоры шигырьләре, 825 нче батальон документлары, «Кормашев һәм башка 10» эше, Гиббельс карамагындагы «Винета» радио-студиясе, Розенбергның «Идел-татар легионы» архивы материаллары, «Идел-Урал» гәҗитенең һәм «Татар әдәбияты» альманахының табылмаган саннары һәм башкалар керә. Бу эзләр буенча йөреп, яңа мәгълүматлар табу — бүгенге һәм киләчәк буыннар эше.

Шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре»нә кергән 94 шигыре, кырык үлемне кичеп, могҗиза белән дип әйтерлек, туган илгә әйләнеп кайталар. 19 исемдәге шигыре ике дәфтәрдә дә кабатлана. Үзенең язуы буенча, 1942 елның октябрь аеннан 1943 елның ноябрь аена кадәрге чорда ул 125 шигырь һәм поэма иҗат итә. «Ләкин кая языйм? Үзем белән бергә үләләр», — дип яза шагыйрь ачынып.»Моабит дәфтәрләре»ндәге безгә мәгълүм булган соңгы — камерадашы, бельгияле Андре Тиммерманска багышлап язган «Яңа ел теләкләре» исемле шигыре 1944 елның 1 гыйнварында язылган. Шуннан башлап, 1944 елның 25 августына кадәрге иҗаты безгә билгесез булып кала бирә. Итальян патриоты Рионеро Ланфредини һәм төрмә рухание Г.Юрытко сүзләре буенча, Муса Җәлилнең тагын ике дәфтәре булган. Аның берсе Римдагы илчелек аша Мәскәүгә — Чит илләр министрлыгына тапшырыла һәм аның журналга теркәлүе мәгълүм. Аннан соң ул дәфтәр һәм андагы язулар тикшерү өчен, контрразведка Баш идарәсенә тапшырыла. Шуннан соң аларның язмышы билгеле түгел. Әлбәттә, ул чордагы яшерен архив «кешеләре» гади генә хезмәткәр булмаган һәм алар аны шул буталчык чорда аерып алып, каядыр махсус урынга куйган булулары мөмкин. Ике дәфтәрнең, фашист төрмә-лагерьларын кичеп, әйләнеп кайта алганны, аларны үзебездә юкка чыгармаганнардыр, дип ышанасы килә. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

....

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ҮГДЕЛМЕШ ОЛУГ ХАҖИПЛЕККӘ НИНДИ ИР КИРӘКЛЕГЕН СӨЙЛИ

Җавапта Үгделмеш сайратты телен:
– Узсын рәхәт килеш илбик, мең елың.

Олуг хаҗипнең һәр эше чын булсын,
Чынлыгын юнәлткән нәрсә дин булсын.

Аслы изге, уңай булсын кылмышы,
Ай-көн кебек илне яктыртсын эше.

Төбе изге булса, күр, изге булыр,
Илгә һәм халыкка игелек кылыр.

Изге заттан килә илгә игелек,
Ашау-эчү; изге гамәл мәңгелек.

Холкы уңай хаҗәт сайла үзеңә,
Чыкмасын сүзеңнән, барсын эзеңнән.

Ачкүз түгел, оят белгән, әдәпле,
Түмән төрле белек әһле, сәләтле.

Ришвәт алмас күзе тук бәк кешедән,
Ришвәт алган хаҗип калыр көлкегә.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
** Курсив илә язылган юллар нәкъ оригиналдагыча, тик сүзләрнең фонетик йөзе генә борынгыча.

Төзек эшне бозык итә ул ришвәт,
Ишелгәнне кире сүтә ул ришвәт.

Оят белсә хаҗип, булса холкы төз,
Гел изгегә булыр анда гамәл, сүз.

Оят белгән яман эшләрне кылмас,
Кара якмас, аңар кара ягылмас.

Яраша мал-мөлкәт юньле бер иргә,
Яраша зур бәхет изге күңелгә.

Белекле булган ир язмас юлыннан,
Моңаймас мал дип, эш килсә кулыннан.

Ни шәп әйткән олуг бер зат электә:
Белеклегә акыл тия өлешкә.

Белеклеләр эшкә кирәк бийләргә,
Белексез кирәкмәс, күр, һичберәүгә.

Берәү мәхрүм булып калса, белектән,
Аны тере димә, сана үлеккә.

Төзек эшне бозык итә ул ришвәт,
Ишелгәнне кире сүтә ул ришвәт.

Белек илә инсан үсә, дан ала,
Сүзе үтә, эше алга барала.

Белексез хезмәткәр – коры сыр, бизәк,
Белеклеләр рухи күкләрдә гизә.

Эш төбе белем һәм уяулык, диләр,
Афәт элгәртелер уяулык белән.

Бигүк файдасы күп фәһемлелекнең,
Фәһем – төп нигезе һәр игелекнең.

Фәһемсез кеше ул җимешсез агач,
Җимешсез агачтан ни ашасын ач?

Фәһемле – өлешле ике дөньяда:
Изгелек данын да фәһемле ала.

Фәһемле белекле генә чын кеше,
Фәһемледән чыга халык башчысы.

Яраша мал-мөлкәт юньле бер иргә,
Яраша зур бәхет изге күңелгә.

Йөз күрке өстенә булсын буе да,
Лачындай ир даны һәм абруе да.

Чырай матурлыгы уңай тәэсирле,
Батыр кыяфәтең ота һәр җирдә.

Кыяфәтле ирнең була сөрсеме,
Сөрсеме хөрмәтле итә кешене.

Фикерле һәм дине пакь булу зарур,
Ару булса холкың, эшең дә ару.

Аңлылар бүтәннәр өчен кайгырыр,
Аңлы зат инсанның яхшырагыдыр.

Хаҗип һәрчак кеше белән эш итә,
Күрер күзгә матур булсын ничек тә.

Күрекле йөз күргәч, шуның нурыннан,
Күңелләр ачыла, җаннар җылына.

Белкәләр бу хакта болай сөйлиләр
(Белкәләр сүзен тот, и, холкы гүзәл):

«Кешенең күрке йөз, йөзнең күрке күз,
Ике нур чишмәсе булсын ике күз».

Күрекле йөз күргәч, кеше уйлана —
«Эшем барса кирәк, — диеп, — уңайга».

Күрекле затка чын акыл да кирәк,
Һәвәсле дә булса, тагын ямьлерәк.

Һәвәсле кеше ул сүзен онытмас,
Һәвәссез кеше ул – үз сүзен тотмас.

Күңел сөймәс эшне ир башкаралмый,
Акылы кушса да, эше баралмый.

Коры кабык кебек күңелсез кеше,
Күңел бирсәң генә эш булыр эшең.

Белексез хезмәткәр – коры сыр, бизәк,
Белеклеләр исә күкләрдә гизә.

**Фикерле һәм дине пакь булу зарур,
Ару булса холкың, эшең дә ару.**

Тигез алчак, тыныч холыклы булып
Эш ит, ярлы-толга шәфәгать кылып.

Канун куллануда зирәклек кирәк,
Һәрбер эшне матур итәдер зирәк.

Тыныч бул, һәркемгә күрсәт кечелек
Йомшак булсын телең, шикәрдәй сөчек.

Йөзең якты, көләч булу өстенә,
Кылмышың файдалы булсын кешегә.

Ишет, әнә, ни ди кеше алчагы:
«Кече булсын күңлең, и, ир кыпчагы[1]».

Күңлең тыйнак булса насыйбың булыр,
Көләч йөз янына кеше җыелыр.

**Коры кабык кебек күңелсез кеше,
Күңел бирсәң генә эш булыр эшең.**

Якты йөз, яхшы сүз күңел эретер,
Кешене яхшы сүз итәдер әсир.

Сабыр булу кирәк мөгамәләдә,
Кирәкмәгән сүзләр сөйләнгәләмә.

Колак сак, акыл һәм белем киң булсын,
Кылык төз, күңленә теле тиң булсын.

Эшен дә булдырсын, китап та язсын,
Белемен гамәлдә куллана алсын.

Бу ирдәмлек белән гыйлем бербөтен
Булу нурландырыр хаҗипнең йөзен.

Хезмәтләрнең иң-иң нечкә һәм төрле
Гыйлем сораганы хаҗип эшедер.

Хаҗип дигән исем алдыңмы, димәк,
Халыкка юлбашчы булырга кирәк.

Моңа тагын дәлил – бар шагыйрь сүзе
(Шигъри сүз белемсез кешегә күзлек):

«Хаҗип булу мөмкин шул сыйфат булса –
Күз үткен, күңел киң, колак сак булса».

И, илбигем, озак яшә син үзең,
Олуг хаҗибеңнең шат булсын күзе.

Сәясәт һәм канун – нечкә эшләрне
Хаҗипкә тапшырсаң, юллы эшләнер.

Бу бапта хәтердә бер белкә сүзе
(Күңел биреп тыңла әле син үзең):

«Олуглыкны таләп итә хаҗиплек,
Аны башкарыр тик ныклы вә иплe».

Хаҗипкә һәм бийгә дә囲 эштә кирәк
Эшбашкаручылар – олы, кечеләр.

Казначы, бетекче, чара күрүче,
Һәм тунчы[2], ишекче, эш бетерүче.

Ялавачны кабул итү, озату,
Бүләкләү шуларның төп вазифасы.

Ашавы-эчүе ничек илчене?
Тәэмин итү кирәк көнен һәм төнен.

Күрсәткәндә шундый затка үз юлын,
Ярым-йорты кылмау фарыз юрыгын[3].

Ярлы, тол-ятимнәр сөйләсә зарын,
Булырга кирәктер бик игътибарлы.

Тикшерү чорында шикаятьләрне
Дә буш калдырмаска кирәктер әле.

**Йөзең якты, көләч булу өстенә,
Кылмышың файдалы булсын кешегә.**

[1]Бу бик кызыклы фразема – *ир кыпчагы: кыпчак* сүзенең «батыр, герой, егетлекле» мәгънәсе дә булган икән.
[2] Тунчы монда киң мәгънәсендә – «кием-салым, обмундирование белән тәэмин итүче».
[3] Юрык – «әхлак», монда – халыкара аралашу кагыйдәләре.

Янə күрсəң эчке-тышкы юньсезлек,
Тый көчлəшүчене, якла мескенне.

Менə бу эшлəргə бераз, гадəттə,
Олуг хаҗип кулы тия, əлбəттə.

Бу эшлəрдə хаҗип тиешен кылыр:
Эш бозылса, нəкъ ул гаепле булыр.

И, илбик, хаҗипкə сак булу зарур.
Кайбер очракта бик тыйнак булсын ул.

Беренчедəн, хаҗип сүздə нык торсын,
Икенчедəн, нəфсен-һəвəсен тыйсын.

Өченчедəн, бик тə күзəтсен үзен –
Телдəн ычкынмасын кирəксез сүзе.

Ришвəт-фəлəн алмый һичбер эшендə,
Бийгə тəкъдим итсен кирəк кешене.

Ярлы, тол-ятимнəр сөйлəсə зарын, Булырга кирəктер бик игътибарлы.

Түбəндəге ике гадəт күрсəтсə,
Гөнаһ булмас кусаң хадимне хəтта:

Берсе — ялган сүзлəр чыкса теленнəн,
Икенчесе — үзен зур куйса синнəн.

Бу ике кыланыш кемдə күренсə,
Якын да юлатма, илбик, үзеңə.

Хезмəткəрдə була өч ноксан тагын
(Шулар белəн кеше ашый үз башын):

Берсе – сүз ишетеп, шуны фаш кылу,
Икенчесе – ноксан күреп, күз йому.[4]

Ни ди акылдар һəм батыр белкə бəк
(Бу сүзне эшкə тот – булыр бик əйбəт):

Һəрнəрсəнең чагы-вакыты килə, Вакыты җиткəнче «күз күрер», дилəр.

Бий серен сөйлəмə: башыңны сакла,
Һəм ил-көнгə яман чабын таратма.

Кара халык белсə, башыңа булыр,
Мəкаль бар: азгын тел-тешне сындырыр.

Күргəнем бар – шундый тотнаксыз кеше
Илгə сөйлəп йөрде – киселде башы.

Күп ишеттем: артык сүзчəн бер ирнең
Бийнең йөрəк сере ярган иренен.

Əйткəн элекке бер бөкə – акылдар:
Тотнаксыз кешелəр үз башын ашар.

Хаҗиплəргə бигрəк сак булу фарыз,
Күзең күрсен күбрəк, азрак булсын сүз.

Вакытсыз чагында бийгə кермəскə,
Чакырусыз барып, үтəк[5] бирмəскə.

Ни ди, ишет, əнə, ушлы зат теле
(Ушлылар телендə мəганə тулы):

«Форсат килсə генə керсен бийлəргə,
Сораганда гына кирəк сөйлəргə».

Һəрнəрсəнең чагы-вакыты килə,
Вакыты җиткəнче «күз күрер», дилəр.

Шуларны белсə һəм үтəсə һəркөн,
Олуг хаҗип үзен сизəр бик иркен.

Шушы иде, илбик, барча белгəнем,
Сораганыгызны гына сөйлəдем. ■

[4] Төп текстта өченче ноксан турында берни дə əйтелми.
[5] Үтəк – КБ телендə үтəлеш, «отчёт». Күрəсең, борынгы идарəви термин.

СОЛДАТ

Гаяз Исхакый

(роман)

III

Аштан соң атларны карап Садыйк капка төбенә чыкканда аргы якта гармун тавышы берлә сузып-сузып көйли торган йыр тавышы, югары очтан моң гына сызгыру тавышы авылның икенче кырыенда анасыннан адашкан бәрән тавышы берлә әллә нинди бер малайның «әһү, әһү!» дип ат эзләү тавышы йокларга хәзерләнгән авылның тынычлыгын боза иде.

Садыйк, акрын гына шул төрле төсле тавышлардан хасил булган авыл музыкасын тыңлый-тыңлый, кая барганын уйламаенча югары очка менә башлады. Авыл йокламый иде, һәр өйдә кечкенә генә лампа яна, һәр тәрәзәдә чебен уты кебек кенә яктылык күренә иде. һәр өйдә аш эчү күренә, балалар тавышы, ишетелә, һәр өйдә хатыннарның кызуланып-кызуланып аш хәзерләүләре яисә ашны җыештырулары күзгә ташлана иде. Болар һәммәсе дә озак аштан соң тамакларын туйдыргач йокларга, иртәгә тагы шундый 16 сәгатьлек эш көненә чыгарга хәзерләнәләр. Шул көнне исән-сәламәт каршы алыр өчен хәл җыярга ашыгалар иде. Кайсы өйдә түр башында карчыклар яисә картлар бер торып, бер ятып намаз укыйлар, кайсы өйдә балалар җык килеп сөт ашыйлар, кайсы өйдә хатыннар күтәреп-күтәреп кабартып түшәк җәяләр иде. Менә Садыйк Афзалларга җитте, аларда да шул эш, аларның да өйләрендә шул манзарә булса да, бүлмә тәрәзәсе башка өйләрнекеннән якты, башка өйләрнекенә башка иде. Аларның бүлмә тәрәзәләре кызыл яулык берлә корылганга, җиделе лампа берлә яктыртылганга ул бөтен урамга икенче төс бирә иде. Садыйк тагы югары очка таба китте. Аның күзенә тагы кызыл яулык корылган зур лампа берлә яктырылган тәрәзәләр очрый башлады.

Ул бу тәрәзәләрнең ник якты икәнлекене, ник кызыл яулык корылган икәен бик яхшы белгәнгә, ул кызыл яулыклар, якты лампалар авыл кызларының авыл егетләренә үзләренең барлыкларын, үзләренең кызлыкларын, үзләренең күңелләренең сөяргә, сөешергә хәзерлекләрен күрсәтә торган галәмәт икәнен белгәнгә, бу кызыл утлар аңарга бер дә гаҗәп төсле күренмәде. Шул тәрәзәнең кызын уйлап, ул кызның үзләренең авылларының фәлән егет берлә андый-мондый бармак селкешүләрен, күз кысышуларын гына хәтеренә китерде. Менә Зөһрәнең тәрәзәсе төбенә җитте, аның тәрәзәсенә карарга тотынды, аның тәрәзәсе дә башка кызларныкы кебек яктыртылган, аның тәрәзәсе дә башка кызларныкы кебек пәрдә берлә капланган иде. Ләкин бу тәрәзә, бу яктылык, бу пәрдә Садыйкка әллә нинди башка тәрәзәләрдән, башка пәрдәләрдән, башка утлардан аерым кебек күренде. Бу тәрәзә, бу тәрәзәнең иясе, бу тәрәзәнең хуҗасы башка кызлар кебек шат, ачык түгел төсле күренде. Садыйкның күңеленә Зөһрәнең сөйгән егете Сафа килеп төште. Сафаның да Садыйк кебек быел солдатка каралуы, аның да Садыйк кебек тазалыгы, аның да солдатка китү ихтимал барлыгы, Зөһрәнең Гайниҗамал кебек үзенең сөйгәненнән аерылып калуы хәтеренә килде. Ул тагы тәрәзәгә карады, тәрәзәдәге ут та, тәрәзәне каплаган пәрдә дә, пәрдә артындагы кыз да щуны уйлаган кебек тоелды. Шуның кайгысыннан Зөһрә дә хәзер кәефсез

кебек, шуның хәсрәтеннән лампа да караңгы кебек күренде. Садыйк: «Солдат, солдат! Сафа да китсә, мин дә китәм! Зөһрә дә кала, Гайниҗамал да кала», — дип кычкырып җибәрде. Ул шул минутта үзенең китүенә, Сафаның китүенә шулкадәр ышанды, аны бу вакытта нинди дәлил берлә дә шул уеннан кайтартырга мөмкин түгел иде. Ул үзенең китүенә ышанганга, көннәре актык көннәр дип беркетеп куйганга, үзенең шул кайгысын бүләр өчен, үзенең шул калган көннәрен мөмкин кадәр шатлыкта үткәрер өчен, Гайниҗамалны мөмкин кадәр күбрәк күрер өчен, аның берлә күбрәк сөйләшер өчен, аның берлә күбрәк сөешер өчен түбән очка таба борылды. Шул ара да булмады, аңар каршы тәрәзә яктысыннан бер шәүлә селкенә башлады, шәүлә якынлаша башлады, менә шәүлә Мөхәммәдиләр тәрәзәсенең яктысы тугрысына җитте. Садыйк бу шәүләнең Сафа икәнен белеп, Сафаның ни уйлаганын белер өчен аның йөзенә карарга тотынды. Аңарга аның йөзе дә кайгылы төсле, аның башы да әллә нинди уйлы төсле күренде, тагы аны караңгылык каплады. Менә акыртын гына Сафаның сызгыруы ишетелә башлады. Зөһрәнең тәрәзәсендә пәрдә селкенде. Сафа да килеп җитте. Садыйк Сафага үзенең кем икәнлеген белдерер өчен тамак кырды. Сафа акыртын гына Садыйк янына килеп исәнләште. Садыйк Сафаның ни өчен килгәнлеген белгәнгә, аның ни өчен сызгырганын аңлаганга: «Бар, бар, юлыңда бул!» — дип, Сафаны озатмакчы булды. Сафа: «Тукта, ашыкма, мин хәзер чыгам, син Шаһиләр өй артында көт, аръякка чыгамыз, бүген Әхмәтҗаннарда кунак кызы бар», — дип, акыртын гына Зөһрәләргә таба сызгыра-сызгыра китте. Садыйк аны-моны уйламаенча гына, Шаһиләрнең өй артларына бармаенча, Зөһрәләрнең лапаслары буена баганага барып сөялде. Лапас эчендә чулпы чылтыравы ишетелә башлады. Менә тагы тавыш бетте. Бераздан соң тагы чылтырарга тотынды. Акыртын гына Зөһрәнең: «Монда!» — дигән тавышы ишетелде. Үзенең барлыгын белдермәс өчен Садыйк бер дә селкенмәенчә баскан урыныннан кузгалмады. Менә лапас эчендә Сафаның тавышы, чулпы тавышы, үбешү тавышы ишетелә башлады. Шактый гына вакыт үткәннең соңында Зөһрә тавышы, аның артыннан Сафаның пышылдавы ишетелә башлады. Садыйкның күңеленә үзенең Гайниҗамалы тагы төште. Ул Сафа берлә Зөһрә сөйләшүен түгел, барлыкларын да онытып, үзен, үзенең Гайниҗамалын уйларга тотынды.

Ул үзен, үзенең каялыгын онытты. Ул үзенең шул уена чумды, үзенең шул татлы уе берлә ләззәтләнә башлады. Лапас эчендәге: «Син китәрсең шул!» — дигән Зөһрәнең сүзе аңарга әллә нинди тәэсир итте. Ул элгәре шул сүзнең мәгънәсен аңламаган кебек, кая китү тугрысында сөйләнгәнне белмәгән кебек булды. Озак үтмәде, яшен ташы кебек аның күңеленә «солдатка!» дигән сүз килеп төште. «Әйе, солдатка китәрсең шул! Мин дә китәрмен шул!» – дип, шул уйны сузарга тотынды. Тагы лапастан: «Мин калырмын!» – дигән сүз ишетелде. Аның уена тагы бер койрык ялганды. «Мин калырмын! Син китәрсең, син китәрсең, мин калырмын», – дигән сүзне авызында әвәләтә башлады. Тагы чулпы чылтыравы, тагы үбешү тавышы аны уятты. Озак үтмәде, Сафа да чыкты. Ул Шаһи өенә таба бара башлады. Садыйк үзенең каялыгын белдерер өчен сызгырды.

Садыйк Сафаны күрүе илә, бер сүз дә әйтмәенчә: «Малай, китәбез бит!» – диде.

Сафа ни әйтергә белмәенчә, ачуланган тавыш берлә: «Син тилеме, түгелме? Бүген аны уйлыйлармы? Кая барсаң да бер кояш! Без генә китмәгән, ата-бабадан калган йола», – дип, сүзне борыр өчен: «Әхмәтҗаннарга кунак кызы килгән, әнә, ишетәмсең, безнекеләр ничек җырлыйлар», – диде. Садыйк Сафаның ахыргы сүзләрене ишетмәгән кебек: «Ата-бабадан калган да, синең Зөһрәң кала! Минем...» – диде.

Сафа ачуланып: «Син бүген тирес торган ахырысы! Әллә Зөһрә урынына Зөһрә

беткәндерме!» – диде. Садыйк каршы бер җавап та бирмәенчә үз уена чумды. Озакламады, гармун уйный торган иптәшләре янына килеп җиттеләр. Садыйклар барып җиткәч, гармунчы җиңел көй уйный башлады. Бу көй Садыйкның уен борды. Ул үзенең ямьсез уйларын онытып, иптәшләре берлә көлешергә, сөйләшергә, җырлашырга тотынды. Озак үтмәде, салышып, чәй эчәргә уйладылар, һәм дә, тиз генә салышып бал чәкчәге, алма, күмәч алырга җибәрделәр. Үзләре барысы да Гарифә әбигә кереп самавыр куйдырдылар. Чәй янында егетләр авылның бөтен кызы хакында, кунак кызы хакында әллә нинди сүзләр сөйләделәр, әллә никадәр көлделәр, берсеннән-берсе арттырыр өчен, үзләре әллә никадәр кыз күргән итеп күрсәтер өчен, үзләренең кызлар алдында бик кадерлелекләрен исбат итәр өчен әллә никадәр ялганладылар. Ишеткән бер хикәяне үзләре күргән, үзләре кылган дип сөйләделәр.

Сафа да үзе тугрысында сөйләде, ул да үзен әллә кемнәр сөйгәнен сөйләде, ул да алдады, аны да тыңладылар. Кыскасы гына, монда бөтен кеше алдый, бөтен кеше сөйләүченең алдавыны белә, бөтен кеше ләм-мим дип сүз кайтармый иде. Болар арасында кызлар сөешү тугрысында алдау шулкадәр җәелгән иде, бу алдау боларга каннарына шулкадәр сеңгән иде, алар шул алдаудан башка мәҗлеснең ямене тапмыйлар, тормышның ләззәтене белмиләр иде.

Садыйк боларның алдауларыны тыңлады. Боларның әллә ничәшәр кат ишеткән хикәятләрен тагы ишетте. Ул да алар кебек ышанган кебек бер сүз әйтмәде. Ул да алар кебек көлде. Ул да алар кебек ялганлады. Бу ялган аңарга да үзенең ямьсез уйларын онытырга, үзен-үзе алдарга, үзен-үзе кәефле кебек иттереп уйлатырга сәбәп булды. Озак үтмәде, Садыйк күкрәгендәге бүләгене исенә төшереп, Гайнижамал янына барыр өчен, ялган хәйлә табып, чыгып китте. Озакламаенча, Гайнижамалның тәрәзәсе төбенә килеп тә җитте. Аның да тәрәзәсе башка кызларныкы кебек пәрдә корылган, башка кызларныкы кебек яктыртылган иде. Ул тәрәзә янына килеп карарга тотынды. Пәрдә ашасыннан Гайнижамал күренмәсә дә, пәрдәдәге аның шәүләсе ап-ачык күренә иде. Аның кулының селкенүе, аның йөзе, авызы, хасыйле, һәммә әгъзасы беленә иде. Садыйк бу әгъзаларның барысын да бик күптән бирле таныганга, аның Гайнижамал нишләгәндә авызы нинди булуын, күзе ни төсле булуын белгәнгә, ул пәрдә аша күренә торган Гайнижамалны бик озак карап торды. Ул Гайнижамалның һәр хәрәкәтеннән, аның һәр селкенүеннән әллә никадәр ләззәт алды. Карап туйганның соңында ул акыртын гына тәрәзәне чиертте. Менә пәрдә селкенде, тәрәзәдән Гайнижамал күренде. Ул акыртын гына башын селекте. Садыйк аның ни әйткәнен аңлап, лапас астына керер өчен Гайнижамалларның күршеләре йорты аша аларнын артларына чыкты. Сарыклар курыкмасын өчен акыртын гына басып лапас астына керде. Өй ишеге ачыла башлады. Садыйкның йөрәге леп-леп сикерә башлады. Озак үтмәде, комган күтәреп, Гайнижамал чыкты. Ул акрын гына лапаска таба килә башлады.

Садыйк акрын гына сызгырды. Озакламады, Гайнижамал Садыйкның кочагына керде. Алар тагы бик озак сөйләштеләр. Тагы бик озак сөештеләр. Тагы берсеннән-берсе аерылмаска булып, вәгъдәләр кылыштылар. Тагы үбешеп аерылыштылар.

Тагы Садыйк өенә кайтып үзенең лапас астына аскан чанасына менеп ятты, тагы иртә торып эшкә тотынды, тагы кич берлә йөрергә чыкты, тагы Гайнижамал янына барды, тагы, атна саен иген берлә шәһәргә барып, Гайнижамалга бүләк алып кайтты. Шулай итеп көннәр үтте. Набор җитте.

IV

Набор башланды. Садыйклар да бөтен авыл егетләре берлә шәһәргә киттеләр. Бөтен авыл моң, күңелсез төскә керде. Урамның ул очында да, бу очында да ишетелә торган егетләрнең йыр тавышлары, аларның бертуктамый гөрли торган гармун тавышлары ишетелми башлады. Тәрәзәләрдәге кызыл яулыклар да тоныграк, аларның артындагы кызлар да моңрак кебек күренә башлады, һәр өйдә карчыклар, картлар бик тырышып әллә нинди хуҗаларга догалыклар укый башладылар, әллә нинди изгеләргә угылын калдыру яисә фәлән абыстайның киявен калдыру, йә фәлән кызның сөйгәнен калдыру тугрысында догалар ычкындыра башладылар.

Мулла абзый да һәр намаздан соң әле аның өчен, әле моның өчен дога кыла башлады, һәр өйнең йә угылы, йә кияве, йә дусты кергәнгә бөтен авыл өмет берлә өметсезлек арасында яши башлады. Төшче әбиләрнең курслары күтәрелде. Муллаларның төш тәгъбирләре өйдән өйгә йөри башлады. Бөтен авыл шәһәрдән хәбәр көтә башлады. Бөтен авыл шул уй, шул фикер берлә генә яши башлады. Әүвәлге көнне берни булмаганны, икенче көнне тикшерү (кличка) булганны, өченче көнне шобага алуны ишеттеләр, һәркемнең авызында шобага сәфәрләре әвәләнә башлады. Барысы да шобага җитәрлекме, түгелме, шабаш (шатбаш)ка калырлыкмы, түгелмелегене уйлый башладылар. Садыйкның да шобагасы беленде, аның шабашка калу ихтималы барлыгы бөтен авылда сөйләнә башлады.

Гайниҗамал бөтен авылның карчыкларына төшлекләр, ниятләр таратты. Әллә никадәр хуҗаларга әллә ничәшәр күкрәкләр, сөлгеләр, салфетлар нәзер итте. Каралу башланды. Иң әүвәл һич уйламаган, авылда таз дип калырга хөкем ителгән бер егет алынды. Аның артыннан тагы бер, тагы бер алынды. Бу өч солдат авылның кайсы өйләрендә өметне өметсезлеккә әйләндерде. Күп өйләрдә күз яшьләре түктерә башлады. Икенче көнне бөтен авыл утлы күмер өстенә баскан кеше кебек тагы яңы алулар, яңы калуларны көтә башлады, шәһәрдән кайткан бер кешене чормап, следователь кебек сораша башлады. Кичкә таба бу көтү тагы куәтләнде. Күп аналар шәһәр юлына чыгып кайтучыларны көтә башлады. Зөһрә дә, Гайниҗамал да, авылның башка кызлары да бу көнне бик авыр үткәрделәр. Кич берлә тагы дүрт кешенең алынуы, алар арасында Сафаның булуы бу кайгының тагы күбрәк өйгә җәелүенә сәбәп булды. Төнлә берлә соң гына шәһәрдән Закир да кайтты. Ул әниләренә, якын карендәшләренә Садыйкның бүген каралмавын, Садыйкның иртәгә соң гына каралуын, аның шабашка калуы бик ихтималлыгы хәбәрен китерде. Садыйкның анасы, Гайниҗамал тагы яңы нәзерләр әйттеләр.

Тагы яңы өметләр берлә йокларга яттылар. Икенче көнне үткәрү Гайниҗамал өчен бик авыр булды. Аңарга үзенең бу кайгысыны кайгыртудан битәр, ул кайгыны кайгыртмаган төсле булып күренү кайгыдан да авыр тоелды. Ул шуның өчен әллә никадәр куәт сарыф кылырга мәҗбүр булды. Менә кич тә булды. Шәһәрдән бер хәбәр дә алынмады. Гайниҗамал урынында утырып тора алмый башлады. Ул үзенең аналарыннан яшерер өчен, үзенең дус кызына кич утырырга китте. Анда да йөрәгенә урын таба алмады. Аңарга минут сәгать кебек, сәгать ел кебек озак үтә башлады. Менә кыңгырау тавышы ишетелде. Ул әллә никадәр вәгъдәләр кылып, дустының сеңелесен белешергә җибәрде. Күңеленнән тагы нәзерләрен зурайтты. Актык минут та җитте! Гайниҗамал әйтеп бетерә алмаслык бер сабырсызлык берлә хәбәр көтә башлады, кыз кайтты. Ишектән керер-кермәс: «Садыйк абзый киткән!» – диде. Бу сүз Гайниҗамалны яшен суккан кебек ясады. Ул үзен-үзе тыя

алмаенча, үзенең хиссиятен яшерә алмаенча, үкереп-үкереп еларга тотынды. Бик озак елаганнан соң Гайниҗамалда әллә нинди бер куәт берлә Садыйкны күрәсе теләү хисе уянды. Ул үзенең бу хисене сакларга теләсә дә, бу теләүне булдыруны бүген үк, хәзер үк нинди авыр идекен белсә дә, җалынып-җалбарып, тагы теге кызны Садыйкка җибәрде. Озак үтмәде, кыз да кайтты. Аннан соң тәрәзә дә шылтырады. Бераздан Гайниҗамал Садыйкның кочагына атылды. Ул: «Киттеңмени?» – дигән сүздән башканы әйтмәенчә, Садыйкның битене кайнар яшь берлә юарга тотынды. Бик озак уйлаганнан соң, бик озак суырып-суырып үпкәннән соң, әллә ничәшәр мәртәбә бер-берсенә көтешү вәгъдәләре кылышканнан соң, Гайниҗамал бераз басылып өйгә керде. Ул хәзер үзенең шул кайгысы берлә, үзенең шул бәхетсезлеге берлә килешә башлады. Садыйк Гайниҗамалның кочагында тагы үзенең киләчәк ямьсез тормышын баштанаяк уйлады. Карт солдатлардан ишеткән дөрест-ялган хикәяләрне һәммәсенә дә бер күз берлә карап, ни булса да сабыр итәргә, ни күрсә дә шул Гайниҗамал өчен онытырга, һәрвакытта Гайниҗамал өмете берлә шатланырга уйлап куйды. Озак үтмәде, бөтен киткәннәрне тагы шәһәргә җыйдылар. Аларның һәммәсенә кая китүләрен белдерделәр. Садыйк үзенең Лодзяга китүен белеп кайтты. Тагы авылның урамнары йыр берлә, гармун берлә яңгырарга тотынды. Ләкин бу йырлар элгәреге кебек шатлыклы, өметле йырлар булмаенча, кайгылы, моңлы, аерылу йырлары иде. Элгәреге йырлар пәрдә артындагы кызларда шатлык хисе уяндырган кебек, бу йырлар аларда кайгы, өметсезлек хисе уяндыра иде. Бик күп өйләр кайгы төсен алды. Бик күп аналар иртәдән кичкә кадәр күзләреннән яшь агыза башлады. Әлеге төшче карчыклар угылларының сәламәт кайтуы өчен, бәхете берлә илгә кайтуы өчен тагы догалар кыла башладылар. Ниятләр укый башладылар. Китәр көн дә җитте. Садыйк кич берлә Гайниҗамал янына барып, аның берлә саубуллашты, аның берлә янә ныклап вәгъдәләште, аның берлә көтешергә, бер-берсеннән башкага кияүгә чыкмаска сүз алышып, бәхилләшеп кайтты. Озак үтмәде, Садыйк иптәшләре берлә билгеләнгән шәһәренә китте.

V

Садыйк аркасына күлмәк-ыштан, башка әйберләрне тутырган капчыкны асып әллә никадәр үзе кебек капчыклар аскан рус, чуаш, татар егетләре берлә юлга чыкты. Әтиләре бик озакка кадәр озата килделәр. Бик озын иттереп, әллә ниләр сөйләшмәкче булдылар, ләкин берсе дә сөйләргә сүз таба алмаганга, бер-берсенә карашып кына бардылар, Менә аталарына кайтырга вакыт җитте. Әтисе: «Угылым, хуш!» – диде дә еларга тотынды. Садыйк никадәр нык төсле күренергә теләсә дә, ул да чыдый алмады. Аның да күзеннән яшьләр мөлдери башлады. Әтисе тагы бераз елаганнан соң кесәсеннән озын баулы янчыгын чыгарды да, бакыр акчалар арасыннан актарып-актарып бер өчлек кәгазь чыгарып: «Мә, угылым, тагы берәр җиреңә ярар, акча кирәк булса, хат яз. Анда больницага-фәләнгә керә алмамсың, майларлык юл булмасмы», – диде дә кызу-кызу акчасын кесәсенә тыгып куйды. Садыйк әтисенең сүзләренә бер җавап та кайтармаенча, үзенең башын катырыр өчен ап-ак кар берлә томаланган сахрага карарга тотынды. Аның күңеленә тагы авыллары, авылларының урамнары, авылларының кызлары, Гайниҗамал, әнисе, сеңелләре килә башлады. Алар барысы да моны озаталар, алар барысы да эч күңелләреннән кайгырталар, алар барысы да әнисе берлә бергә еглашалар кебек күренде. Аның күз алдына еглаудан күзләре кызарган әнисе, сеңелләре, Гайниҗамал күренгән кебек булды. Аның куллары аларның кайнар кулларын кысып күрешкән кебек булды. Аның авызы Гайниҗамалның авызын үпкән ке-

бек булды, аның бите Гайниҗамалның кайнар яше ага торган битләренә тигән кебек булды. Ул үзен-үзе тыя алмады, еларга тотынды. Әтисе, аның янындагы энесе Закир да еларга тотындылар. Еглап-еглап очына чыга алмаганның соңында Садыйкның атасы атны борып: «Угылым, хуш, тәүфыйк, бәхетең берлә кайт», – дип, Садыйкка карамаенча гына кулын сузды. Садыйк: «Хуш, әти!.. Әнигә сәлам әйт! Гайшәгә сәлам (сеңеле) әйт. Гайниҗамал... ны... җибәр... мәңез», – диярге өлгермәде: «Ярар, ярар, угылым», – дип, атасы Садыйкның әйтеп бетерә алмаган уен тутырды. Закир да абзыйсы берлә күреште, алар акрын гына атларына утырдылар да киттеләр. Садыйк яңадан күз яшьләрен яңартмас өчен бик озак артына карамаенча барды. Ул никадәр артына карарга теләсә дә һәр минутта, һәр секундта да артында әллә нинди бик кадерле нәрсәсе калган кебек хис итсә дә, артында гомеренең иң матур вакытлары, балалыклары, егетлекләре калганлыгын, аларның мәңгелеккә кайтмаска калганын белсә дә, ул хисеннән котылыр өчен, ул уйдан качар өчен ул күзен һаман алга юнәлтте. Ул үзенең авылын, үзенең балалык вакытларын, үзенең егетлеген, үзенең Гайниҗамалын онытыр өчен иптәшләре берлә сөйләшергә теләде. Ләкин алар да үзләренең артларында үзләренең авылларын, аталарын, аналарын, хатыннарын, сөйгәннәрен калдырганга, аларга да шул аерылышу кайгысы, шул үткән матур көннәр хәсрәте кергәнгә, алар да Садыйкның күңелен ача алмадылар, алар да моның кебек сөйләшмәскә, сөйләшсә, үткән тормышны хәтергә кертмәскә, йокларга ята торган аерылу кайгыларын уятмаска тырышкан кебек, сүз арасында ул мәсьәләнең янынннан үттеләр.

Менә әллә нигә атлар туктады. Садыйк озын обозның бер башыннан икенче башына таба карый башлады. Алда боларны алып бара торган өч солдатның әллә нигә туктап бергә сөйләшүләре, тәмәке кабызуларыннан башка берни күрмәде. Артка карады. Анда тагы бер солдатның еглап-еглап аерылышу манзарасы күзенә ташланды. Ул күптән түгел генә үзенең дә, шул хәлдән үткәнен хәтеренә төшереп, артта калган әтиләрене эзләргә тотынды. Әтиләре әллә кая ерак киткәннәр. Әнә үргә таба менәләр... Әнә чабалар. Алар шул хәсрәттән аерылыр өчен, шул кайгы берлә аларның арасындагы җирне ерагайтыр өчен атны кыйнап-кыйнап чабалар. Садыйк атны кызганды, ат мескен бик өшәнер инде, йөрүдән туктаганы юк, дип уйларга тотынды. Аттан соң Садыйкның уе әтисенә, әнисенә, аннары тагы Гайниҗамалга барып җитте. Бу ноктадан уза алмаенча шунда катты. Ул хәзер үзенең Гайниҗамалдан чынлап аерылганын, Гайниҗамалны дүрт елсыз күрүе ихтималы юклыгын, Гайниҗамалны дүрт елсыз үбү-кочу ихтималы юклыгын, бәлки бөтен гомергә аның югалуын хәтеренә китерде. Ул үзенең ничек бу солдатка китүен, китмәс өчен ник бер юл да эзләмәвен, ник бүтәннәр кебек колагын тишмәвен, аягын бозмавын уйлый башлады. Ул вакытта ул калыр иде. Ул хәзерге вакытта Гайниҗамал берлә бергә булыр иде. Ул вакытта ул озакламаенча Гайниҗамал берлә туй итәр иде. Ул вакытта ул Гайниҗамал берлә кияүлебикәчле булып йөрер иде. Ул вакытта хәзерге кебек күз яшен буып тотмас иде. Ул вакытта ул бу озын обоз берлә аркасына капчык тагып әллә кая бармас иде төсле күренде. Ләкин шуның артыңнан ук үзләренең авылларының бозып калган кешеләре күз алдына килә башлады. Аларның кайсысының авызы чалышлыгы, кайсысының аягы аксаклыгы, кайсысының күкрәге череклеге хәтеренә төшеп, үзенең тап-тазалыгы, үзенең шәм кебек турылыгы, яшь имән кебек ныклыгы хәтеренә төшеп, бозмавына шатланды. Ул ихтыярсыз: «Мин бозмадым, мин киттем, мин исән кайтырмын, алар гомергә авыру булырлар», – дип уйларга да өлгерә алмады, аларның авылларының бай малаеның моңардан да таза булса да калуы, аның соңында боларның күршеләренең угылының бозмаенча калуы хәтеренә килде. Аларның хәзер өйдәлекләре, аларның хәзер үзләренең сөйгән

кызлары берлә көрешеп йөрүләре, өйләнүләре күз алдына килде. Ул: «Ник соң мин китәм? Ник соң мин солдатка барам? Ни өчен?» – дип уйларга тотынды. Аның башында боларга бирсенә дә җавап булмаганга, ул ата-бабадан калган йола инде, дип җавап бирде. Тагы күңеленә: «Ник болай булган! Менә ат чабыштыру йола булган, менә казлар йолкырга кызлар йөри, кызлар янына егетләрнең керүе йола булган. Бу да шундый йоламы? Сабан туенда иренә, хатынына, егетенә, кызына шатлык була. Сабантуй өчен беркем дә үзенең туган йортыннан, үзенең сөйгән кызыннан, сөйгән егетеннән аерылмый. Кызлар янына егетләр керү дә аларның бармак санаш, йөзек яшереш уеннарында да беркемгә дә бертөрле дә хәсрәт-кайгы булмый. Юк, бу солдатка китү андый гына йола түгел. Бу – башка», – дип уйлап куйды. Ләкин ник башкалыгы, ник солдатка монның китүе, ник солдатка бу кадәр яшь егетләрнең китүе, ник аларның ул колакларга да кермәгән әллә нинди Лодзя Лавес кебек шәһәрләргә җибәрелүе моңарга һаман шул хәл кылынмаган көенчә сөаль булып калды. Ул үзләренең авылларындагы иске солдатларның шул хакта-сөйләүләрен, башка картларның сөйләүләрен уйларга тотынды, аннан да бер җавап та таба алмады. Ул ничек тә җавап таба алмагач, язмыш шулайдыр дип, эшне бетермәкче булды. Ләкин аның башына тагы: «Ник язмыш алай?» – дигән сөаль килеп, тагы җавап сорый башлады. Ул сөальгә җавап бирергә үзенең көче юклыгын белгәнгә обозның уртасында йырлаучы егетләр янына барып, йырларга кушылды. Әүвәле үзенең күңелендәге тавышны басар өчен, аның туктамаенча бирә торган сөальләрен ишетмәс өчен авызын бик тутырып йырларга тотынды. Йырлый-йырлый фикерләр башкага әйләнде. Баягы сөальләр башка килми башлады. Арадан берсе киләчәктә солдат булып торуны бик матур буяулар берлә бизәкләп күрсәтеп сөйли башлады. Садыйк та үзен солдат иттереп үк хис итә башлады. Озакламады, тимер юл стансәсенә барып җиттеләр, һәм тимер юл берлә Лодзяга таба киттеләр.

VI

Лодзяда боларны шәһәрнең кырыенда гына бик озын, бик күп тәрәзәле ак пулатка илтеп, һәммәсен берәм-берәм исемнәре, фамилияләре берлә кычкырып казармага керттеләр. Әйберләрен карарга, күлмәк-ыштаннарын санарга, китапларын тикшерергә тотындылар. Бик озак шул эшләр берлә боларны борчыганнан соң, иске солдатлар, җилкәсенә җиңенә тасма теккән унтер әфисәрләр боларны урынлаштырдылар. Озак үтмәде, аш вакыты җитте. Звонок булды. Солдатлар берәм-берәм кухняда аш алырга чыга башладылар. Садыйкка бу озын, очы күренми торган өй, бу исәпсез тезелгән караватлар, бу бертуктамаенча ашханәдән аш күтәреп керә торган соры шинельләр кигән, кара казакилар кигән яшь егетләр, бу кәбестә исе бөтенләй ят булганга, бу өй, бу кешеләр, бу ашлар моның элгәреге тормышына аз гына да охшамаганга, ул вакыт-вакыт үзенең кайдалыгын онытып җибәрә иде. Менә аларга да ашлар китерелде, аларга да зур кашыклар бирелде, менә алар да ашый башладылар. Бөтен казармада тагы төче ис күтәрелде. Садыйк мондый рус ашын ашаганы юкка, рус ашын күңеленнән генә бик тәмсез була дип хөкем итеп куйганга, ашамаска да уйлаган иде. Ләкин озак торып ашыйсы килүе аны җиңде. Ул чирканып кына, җирәнеп кенә ашарга тотынды. Эшти артыннан ботка да ашалды. Аштан соң әллә нинди бер укалырак солдат кереп, боларны берәм-берәм чакырып, иске шинельләр, иске казакилар, иске итекләр бирә башлады. Садыйк та җиң төбе әллә ничә җирдән ямалган кара казаки, иләк кебек үтә күренә торган соры шинель, бик ямьсез форма берлә тегелгән, тупас итек алды. Аның соңында аларны бары-

сын да мунчага җибәрделәр. Әллә никадәр кайнар, салкын су краннары берлә тулган, умарта корты кебек ялан өст кешеләр кайный торган, һәр почмагыннан кайнар су буы күтәрелә торган, идәннән шылтырап сабынлы йылы су ага торган бу мунчада үзен ят төсле күрде. Ул бу кадәре ялан өст кешеләр арасында юынырга мунчага керергә бераз җирәнә, бераз ояла. Ул, өйдә вакытта булса, яисә хәзер дә керү-кермәү аның ихтыярында булса, ул шөбһәсез хәзер дә кермәс иде. Ләкин аның хәзер солдат булуы, солдатның кушкан бер эшне тотарга тиеш булуы аның күңеленә, әлбәттә, кермәү уены китерми дә иде. Ул юынып чыккач, тартып-төртеп казакисын, чалбарын төймәләде. Итеген нык итеп киде. Ул үзенең солдат киемендә нинди идекен күрер өчен көзгегә карады. Аңарга ул хәзер тәмам бөтенләй башка кеше кебек күренде. Бер җирендә аның өстендәге аннан җыерылган, моннан җыерылган казаки, әллә ничә төшеннән кара җеп берлә тегелгән иске чалбар аны бөтенләй үзгәрткән иде. Ул үзенә үзе исе китте, ул үзен үзе көчкә таныды. Аңарга бу кием берлә әти-әнисе, Гайниҗамалы танымас кебек була идс. Ул шул уйларны уйлап, көзге янында катып тора башлады. Бер карт солдат, «Әй, новобранец! Нәрсә каттың? Төймәләреңне яхшы төймәлә», – диде. Садыйк уянган кебек булып, калган төймәләрен дә төймәләде. Ул шуннан соң үзен элгәреге Садыйк түгел кебек, элгәреге Садыйк әнә шул иске чалбар, иске казаки астында калды кебек хис итте. Кайтырга дип шинельне кигәч, аның ул хисе тагы куәтләнде. Кич берлә аларның занятиеләре башланды. Аларның әфисәрләре кем идекен, полковниклары кем идекен өйрәтә башладылар. Икенче көнне боларны бишәр-бишәргә бүлеп, карт солдатларга өйрәтергә бирделәр. Садыйк бик тырышып өйрәнә башлады. Карт солдатлар боларга мужик дип караганга, монда авылны сөйләү, авылны мактау начар солдатлыктан хисап ителгәнгә, Садыйк яхшы солдат булыр өчен авыл тугрысында сөйләми, Гайниҗамалны уйламый башлады. Ул бик тырышып өйрәнә башлады. Өч ай эчендә Садыйк әфисәрләр, полковниклар, генераллар, тагы шундый әллә кемнәрнең эполетлары ни төслелеген, аларның кайсысы «Его благарудия», кайсысы «Высакаблагарудия» икәнлеген өйрәнде. Уенны да тәмам өйрәнеп җитте, һәр көнне иртә берлә әллә ничә карт солдатның итеген чистартып, аларның да мәхәббәтләрен җәлеп кылды. Ләкин күңелендәге теге сөаленә монда да җавап таба алмады. Ник солдатка алалар? Ник бу кадәр зур казармаларга шул яшь егетләрне җыеп, соры шинельләр кигезеп, эшти ашаталар? Ник әфисәрләрнең укаларын нидилеген өйрәтәләр? Боларның әфисәрләре боларга: «Сез хәзер инде солдат булдыгыз, солдат булу бик зур эш! Солдатның честен саклау – сезнең вазифаңыз, сезне падишаһлыкны дошманнан саклар өчен, падишаһка хезмәт итәр өчен монда китерделәр», – дисә дә, Садыйк: «Нинди дошман? Ник дошман? Сугыш бармы икәнни?» – дип тә уйлап караса да, тагы элгәреге бикләнгән рамнан үтә алмады. Ул хәзер аны-моны уйламаенча, ник солдат булганын исәпләмәенчә яхшы солдат булырга, әфисәрләрдән «спасиба» алырга уйлап куйды. Шул фикер берлән ул беркемгә дә карышмаенча хезмәт итә башлады. Вакыйга озак үтмәде, Садыйк дядькалар, унтер әфисәрләр алдында яхшы солдат исемен ала башлады.

Дәвамы бар ■

Салкын Себернең җылы җанлы кешесе иде ул. Каратут йөзле, ирләрчә чибәр. Һәр бөртеге дүрткырлы куе күмерсу чәче, таралмыйча, бер дулкында муенына төшеп тора. Коңгырт күзләре һәммә нәрсәнең кызыгын табып, чаткыланып яна. Әдәби телебездә ул әйбәт кенә сөйләшә-яза белсә дә, себер татарларына хас акценты кайчакта сизелеп китә; «т» авазы кысылыбрак чыга, «без» диясе урынга «пес», сүс (сүз), антый (андый), нигәмәде (нигә), эшләйде (эшләде), дип әйтү рәвешләре аның сөйләм теленә үзгә бер аһәң, серлелек төсмере биреп тора иде. Онытылып, кызып киткәндә, бишектән сеңгән ана теленә бөтенләе белән күчә дә, бераздан исенә килеп, туктап кала, уңайсызланып кына «казанчага» күчкәндә теле бераз «аксаклап» ала.

КҮЧЕМ ХАННЫҢ ОНЫГЫ

Марсель Галиев

Әгәр Голливуд режиссёрлары күрсә, заманында Америка кыйтгасына басып кергән тәреле байраклы Аурупа башкисәрләренә каршы күтәрелгән атабас халыкларының көрәшен сурәтләгән фильмга аны апачи атаманы роленә алырлар, ул җәясен, уклы садагын иңенә асып, атта мәгъруур утырыр иде. Хәер, ул болай да, аты-ияре булмаса да, табигате белән бәйсез-горур иде, үзе үтә дә самими-беркатлы, тиз ышанучан. Зөлфәт шигырендәгечә, аюга пычак белән барасы ир-егет саллы учында — нәзберек йөрәге сулкылдап типкән былбыл йөртә иде. Былбыл хәтле шагыйрьлек җене… Бу аның бәхете дә, бәхетсезлеге дә булгандыр…

Җаным кебек бик кадерле миңа
Туган җирнең изге туфрагы.
Бу дөньяда Себер агачының
Мин бер серле, моңлы яфрагы.

***

Булат (Бикбулат) Вәли улы Сөләйманов 1938 елның 28 маенда Төмән өлкәсе Вагай районы Сопра авылында сигез балалы гаиләдә дөньяга килә.

Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, ул сәяхәткә чыгып китә. Кесәсе юка булганлыктан, ул күз күрмәгән җирләр белән хозурланып кына йөри алмый шул, җиң сызганып, эшләп алырга да мәҗбүр була. Буяучы һөнәрен дә үзләштерә, буыннары ныгыгач, Омск, Салехард шәһәрләрендә ул — йөкче, бетончы.

Зур капчыклар иңгә тигәндә
Калтырансам да,
нәзек таллар кебек
Бөгелмәдем, түздем имәндәй,

— дип яза ул, бергә өйсәң, пирамидалар хасил итәр тыгыз капчыкларны иңенә салып ташыганын искә төшереп.

Тотрыклы нигезе булмаган, илмирдән җыелган чуар холыклы, тупас эшче-күлән арасында озакка калса, күңелендә бөреләнгән нәзберек хисләрне харап итәсен сизенә яшь егет. Биштәрен алып юлга кузгала. Калын тайга урамнарын кисеп кергән тимер юллар аны туган төбәгенә ашыктыра. Төмән районына кайтып, ул Карагай мәктәбендә китапханәче булып эшкә керә. Китаплар дөньясына чума. Гидайлыкта йөреп күпме вакыт сарыф ителгән. Хәзер инде менә үз-үзеңне куып җитәргә кирәк.

Урта мәктәпне тизләтелгән программа буенча тәмамлап ул: «Мин Тукай телендә язачакмын», — дип 1961 елда Казанга ашыга. Атаклы университетның студенты булуга ирешә.

Борынгы бинаның ак колонналары янында барган горур егеткә карап-карап калалар. Әллә соң Себер аюын җитәкләп барамы, юк, биштәрендә — язылып бетмәгән шигырьләр, күңелендә — сүзләр өермәсе, күзләрендә — казанлы булу бәхете.

И Казаным,
Туган анам кебек,
Кочагыңа ал син гомергә.
Ярсып чапкан
Минем чал Иртешем
Кушылып аксын синең Иделгә.

Себер татарларының теле белән әдәби телебез арасында охшашлык чамалы гына, эченә керсәң — чытырман; ераклыклар, чорлар, гадәтләр буталган. Күз алдына китереп, аңларга тырышып карыйм: шагыйрьгә ике тел арасындагы ызанда бәргәләнү бик кыенга туры килгәндер. Мисалга бер сүзне генә алыйк: шагыйрь урманны сурәтләгәндә болан дип әдәби телебездәгечә язарга мәҗбүр. Ул аны балачактан ук болан дип түгел, ә «аң» дип җан-тәненә сеңдереп үскән. Ә мондый сүзләр аерымлыгы — йөзләрчә. Димәк, шагыйрь балачагыннан имеп үскән сүзләрдән ваз кичеп, әдәби тел кысаларына кергәндә, гадәти күнегелгән киемнәрен салып

ташлап, скафандр кигән кебек була. Нишлисең бит, кышлак теле кышлакта кала, әдәби тел исә Казан биеклегеннән яулана. Димәк, меңъеллык әдәбияты булган милләтнең ана телен мәктәптән үк өйрәнергә кирәк.

Туган ягында Булат Казан төбәгеннән килгән укытучылардан күнекмәләр алган була. Әмма тел хикмәте тирән вә киң шул, аргы яры күренмәгән кырыс дәрья. Секундның меңнән бер өлешендә сүздән — уйга, уйдан сүзгә сикерә алу тизлегенә ирешү өчен Булатка Казан мохитендә шактый чиләнергә туры килә.

Матбугат битләрендә беренче шигырьләре басыла башлауга ук аны күтәреп алалар. Татар бугазыннан алып, Карпатка кадәр җәелгән элеккеге Алтын Урда кыйтгасында ана телебез кысыла бару сәбәпле, Тукай чорындагы сыман әллә кай төбәкләрдән каләмле затлар килүе юк дәрәҗәсенә төшкән бер дәвердә... Урал аръягыннан калыккан шагыйрь Казанга үрелсен әле! Моңа беренчеләрдән булып Хәсән ага Туфан шатлана. Сибгат ага Хәким, Нури Арслановлар хуплап каршы ала. Егет буларак та әнә нинди бит! Күчем ханның «оныгын» яратмау мөмкин түгел. Студент шагыйрьнең матди ягы мөшкел икәнен аңлап, егетне «Казан утлары» журналына эшкә алырга ниятлиләр. Редакциянең Яңа елны каршылау мәҗлесендә Булат — үзәктә, Булат — Шаһзадә! Бүтән редакциянең хатын-кызлары да, аны күрергә дип кереп, тәкатьсез калалар. Холлда танцы бара. Булат кызларны, берәм-берәм йолкып алып, очыртып вальска бии. Бар да әйләнә: уй-хисләр әйләнә, башлар әйләнә, бөтерелмә итәкләр... Булат учында дөнья үзе әйләнә.

Кинәт... Хыял уты сүнә, дәртле аһәң ядрә тигән кош сыман, сулыгып, караңгылыкка төшеп югала. Ни булды? Шомлы сорау: Булат кайда? Булат?!

Бәйрәмнән соң беренче эш көнендә таба алмыйлар Булатны. Кулга алганнар икән, дигән астыртын хәбәр, мең сорау ияртеп, таралып та өлгерә. Юк, нинди дер хәтәр әшәкелек кылмаган Булат (андыйга ул тумыштан сәләтсез иде). Тулай торакның караңгы баскычында гыйшкы белән кочышып торган чакта, кайнар пышылдаулар уй-сүзне көйдерерлек хәлгә җиткән мизгелдә, сылукай, аның каршына тезләнеп, ләззәти хәятнең капкасын ачып керим дигәндә... Гомерендә күрмәгән, ишетмәгән Булат бу хәлне үзен мәсхәрә итү, кыргыйлык дип кабул итә, кинәт ярсып, кубарылып, давыллап ала, шул давылга кызның да итәге кушылып китә...

Нихәл итәсең, Камасутраны «өйрәнеп», Париж тәрбиясе алмагач, тайганың эчкерсез дуамал егете шулай итеп университет белән гомерлеккә хушлаша. Аның илһамлы аяз күген бер елгамы, ел ярымгамы рәшәткәле, чагыр тәрәзә белән томалап куялар.

Халык җырларында шундый хикмәтле юллар бар бит әле: «Утырып уйлар уйлар өчен үскән икән буйларым». Булат Сөләйман холкы йөремсәк иде шул. Аңа көтелмәгән борылышлар, ургылып аккан елгалар, ташлары убылып төшәргә кыҗраган упкынлы таулар булсын. Аның кайнап-бөтерелеп, давыллап ала торган күңеленә каршылык кирәк. Шул каршылыкны җиңәргә омтылыш дәрте аны яшәтә, алгысыта, илһам-дәрман-ныклык бирә, рухын сындырмый.

Булат Сөләйман, еллар аша, кабаттан инде Казанга кайтыр алдыннан, сәяхәт итеп, бер «кагынып» ала. Фрунзе шәһәрендә балта остасы, Бакуда нефтьче оператор булып эшли.

Ниһаять, ул Казанга кайтып, иҗади яшәү әлифбасын кабаттан «А» хәрефеннән башлап җибәрде.

Син дә мулла, мин дә мулла... дип атка печән сала алмый торган тәкәббер-иренчәк казан татарыннан аермалы буларак, Булат теләсә нинди эшкә чирканмыйча, Гариф Ахунов әйтмешли, «черәшеп» тотына иде.

Булдырды егет, Казанның үзәгеннән фатир алуга иреште. Ул аны кул көче белән эшләп алды. Коралы — себерке. Бурычы — ишегалдын чиста тоту. Подвал саналса да, тәрәзләренең өске өлгеләре урамга карап тора. Якты, җылы, иркен. Чиста. Стенасының штукатуркасы купкан урынында борынгы исән кирпеч теземнәре күренеп тора. Үзе бер сәнгать. Бүгенге дизайнерлар кызыгырлык. Бу фатирда без Горький, Тукайлар чорына кайткан кебек дөньялыктан аерылып гөр киләбез. Булат ярлы гына табынны да бай итә белә. Кесәләре — юмарт тишекле, соңгы тиенен дә тотып кала алмый. (Бу бинада хәзерге көндә банк урнашкан. Булатның бүлмәсендә, бәлки, мул акча көшелләре өелеп ятадыр.)

Шул чорда ул Мәскәүнең М.Горький исемендәге Әдәбият институтында читтән торып укый иде. Елга берничә тапкыр сессияләргә барып, Мәскәүне «тез чүктереп» кайта.

Булатны күргәч, хатын-кызларның тән күзәнәкләре алышына башлый. Үзен ямьсез дип йөргәннәр дә чибәрләнеп китә, ягымсызлар елмая башлый. Сүрән күзләргә ут кабына, телләре язылып китә. Булат сайланып тормый, турыдан бәреп сөйләшә. Кайчакта тупасрак кыланып куйса да, үзенә килешеп тора. Тайгадан чыккан экзотика! Менә шул үтерә дә куя ханымнарны. Бу сиңа «Джойс», «Кафка» дип үзеннән акыллы булып сөйләшергә тырышкан арык гәүдәле, салам бармаклы шәһәр шагыйре генә түгел. Бу — арыслан белән күзгә-күз очрашкан, атып алган бүресен сыртына салып кайта торган Себер егете!

Әлеге җәһәттән, профессор Хатыйп Миңнегулов сөйләгәннән бер эпизод китерик. 1973 елда аны бер айга Мәскәүгә стажировкага җибәрәләр. Ул Әдәбият институтының Добролюбов урамындагы җиде катлы тулай торактан бүлмә алып урнаша. Күршесендә — Булат Сөләйманов. Биек үкчәле, төз аяклы, кыска итәкле, сулышка ка-

барлык гаҗәеп чибәр кыз белән иртә дә, кич тә гел бергә болар. Модый чибәрлекне яшереп яткыру гөнаһ дип, мактанасы килептер инде, Булат Хатыйп аганы (ул чакта ассистент) чәйгә дәшә. Өстәлдә — әллә кай илләрдән килгән, күз күрмәгән ризыклар, һәм урысча, инглизчәдән кала Булаттан берничә татар сүзе өйрәнеп алган сылу кыз...

— Тәмле ашасам, мин тагын да шәбрәк булам, — дигән идем, ташый гына күчтәнәчләрне, — дип Булат көлә.

Берничә көннән соң Хатыйп аганың ишеген вахтёр шакый:

— Сезне Иосиф Кобзон чакыра, — ди.

Хатыйп ага аптырап кала. «Ялгышадыр, атаклы җырчы каян инде мине белсен».

— Аста көтә ул сезне, тиз булыгыз, — ди вахтёр. Хатыйп ага аскы катка төшә, күзенә күренәме, чынлап та Иосиф Кобзон басып тора. Шәп костюмнан, пөхтә, затлы.

— Сез Казаннанмы? Булатны беләсезме? Аны таба алмыйсызмы хәзер?

Хатыйп ага кылт итеп исенә төшерә. «Булат теге кызын «Кобзонка» дип таныштырган иде бит. «Бөек Кобзонның» сәркатибеме, сөяркәсеме дигән иде, шыттыра егет, дип аның сүзе әллә ни игътибарга алынмаган ул чакта. Менә бит, үзе эзләп килгән».

— Булатның ике-өч көн инде монда күренгәне юк, — ди Хатыйп ага. Кобзон ачу белән кулын селкеп, ишеккә борыла һәм кара «Волга»сына утырып китеп бара.

— Шул вакыйгадан соң, «Сатмагансың мине, егет икәнсең, гомергә онытмам», — ди Булат. Хатыйп аганы якын итеп күрешә торган була. Хатыйп ага: «Үзең дә молодец! Знай наших!», — дип аны үсендереп куя.

***

Булат Сөләймановның беренче шигырьләр җыентыгы — «Таңнар фонтаны» 1980 елда аксакалыбыз Сибгат ага Хәкимнең бисмиллалы сүзе белән Казанда басылып чыга.

Икенче китабы шулай ук Татарстан китап нәшриятында 1986 елда дөнья күрә.

«Казан утлары»нда проза бүлеге мөхәррире булып эшләгәндә мин аның «Абу баба» дигән хикәясен редакцияләгән идем. Себер тормышыннан, вакыйгаларга куе, кедрлы, карагайлы урман кебек тирән рухта язылган иде ул. Бу хакта Булат үзенең «тайгадашы» «Иртеш таңнары» кебек саллы роман иясе Якуб Зәнкиевкә болай дип яза:

«Рафаэль Мостафин үзенең докладында «Абу баба» хикәясе 1983 елда чыккан иң яхшы әсәр, диде. Дезертирлар турында повесть яки роман язарга исәбем бар. «Абу баба» шуннан бер өзек» (1984).

Булат Сөләйманов узган гасырның җитмешенче еллары уртасында күчмәнлек биштәрен иңеннән төшереп, Төмән шәһәрендә тын култык табып яши башлады. Өлкән язучыбыз Якуб ага Зәнкиев истәлегеннән бер өзек китерик:

«Иртеш таңнары»ның икенче вариантын язып маташкан мәлдә, үзенең хөр холкы белән шаулап-гөрләп Булат килеп керде. Шулчак тар бүлмәмнең эче киңәеп-зураеп киткәндәй булды. Чөнки бу терекөмештәй хәрәкәтчән, үткен коңгырт күзләре елмаеп, нур балкытып торган таза егет беренче күрүдә үк миңа ошады...

Без чәй янында дустанә сөйләшеп утырдык. Булат шаяртып әйтеп куйды: «Күрәм, Якуб абый, сез тавык кетәгедәй җирдә, урыс әйтмешли, әкияттәгечә, «в избушке на курьих ножках»та гомер сөреп ятасыз икән. Минем хәл дә шуңа охшашалы иде. Мин моңа түзеп тора алмадым, бер зур җыелышта Обком секретаре алдында чыгыш ясадым. Биек трибунадан әйтеп салдым: «Мин — Себер татарларының беренче шагыйре. Фатирым булмаганлыктан шигырьләремне Төмән күпере астындагы ташка куеп язам. Инде фотокорреспондет чакырам да, шул хәлемне фотога төшереп, ООНга җибәрергә мәҗбүрмен. Шул чыгышымнан соң бер ай да үтмәде, үзләре мине чакырып алып, ике бүлмәле фатирга ордер тоттырдылар. Хәзер менә шунда киерелеп-сузылып иҗат итеп ятам».

Әмма тынгысыз җанлы Булатны «арканлый» алмыйсың шул. Төмән язучылар оешмасында, пропаганда бюросында эшләве сәбәпле, ул командировкаларда еш була, Себер киңлекләрендә йомылып калган авыл һәм шәһәрләрне үз күзләре белән күреп, андагы тормыш хәлләрен күңеленә салып бара.

Төмән-Казан поезды, үзе әйтмешли, «песи битен юынган арада» килеп җитсә дә, ул инде хәзер сирәк кунак иде. Аның килеп төшүе — үзе бер бәйрәм була иде.

— Булат, Булат кайткан,
Бүләк алып кайткан, —

дип «Зәңгәр шәл»дәге арияне җырлап каршы ала идек. Булат канәгать. Үзе дә безне сагынган, без дә аны сагынганбыз. Эре бөдрә йонлы, киң якалы

кайры тун кигән Булат, Шишковның «Хәсрәт дәрьясы»ндагы Прохор Громов кебек басып тора. Күзләрендә — төнге учаклар җемелдәгән тайга рухы.

Бераздан инде табын оеша. Затлы балыклар алып килмәсә, Булат Булат түгел инде ул. Җаена карап, төрле елларда ул безне төштә дә күрмәгән әллә нинди балыклар белән сыйлады. Енисейдан тотылган таймень, линь, Таймыр ярымутравындагы саф сулы елгаларда йөзеп үскән гаҗәеп муксун, чиста күл балыгы пелядь, үзенең Иртеше мактанычы — тел өстендә шаулап эреп, турыдан-туры канга күчә торган нельма — болар һәммәсе тәме белән хәтердә кала торган, дөньяви бәһа алган балыклар иде.

Бу нигъмәтләрне «мырлый-мырлый», мактый-мактый, мыектан маен агызып ашаганда десертка яңа шигырьләр чыга.

— Син үзеңне Себернең берләнбер шагыйре дип йөрисең дә, артыңнан икенче себер егете — Шәүкәт Гаделша куып килә, — дип Булатны котыртып куябыз.

— Мин прозага күчәм. Роман язачакмын, — ди Булат.

Рабит Батулла Булатка махсус атап язылган көлкеле, маҗаралы хикәясен укый. Көлешәбез. Төн урталары җиткәндә Булатның кунакханәдә урын белешмәгәнлеге билгеле була. Үзе кебек эчкерсез Рөстәм Мингалим аны кунарга үз фатирына алып китә. Шулай итеп, атна буе сайланмыйча сыйланып-сыйлап йөри торгач, Себер бае булып килеп төшкән Булат бер атнадан инде «таланып», Казан хәерчесе булып, Төмән поездында китеп бара.

***

Сиксәненче еллар азагында, илнең асты-өскә килгән болгавыр дәвердә Булат Сөләйманов сәясәткә кереп китте. Табигатендә артистлык, икейөзлелек ятмаган Шагыйрь йөрәкле кешегә хәтәр юл иде бу!

Мең кыенлыклар күреп, ул Себер татарлары тарихына караган кыю, тирән эчтәлекле мәкаләләр чыгарып (рус газеталарында) шау кузгатты. «Сибирские татары — кто мы?», «Нет языка — нет народа», «Язык — культура — автономия» исемле язмаларында ул халык тарихын бөек һуннар учагына илтеп ялгады. Зирәк аң-акыл бик акырынлык белән уяна барган җәмәгатьчелек аның бу тәвәккәл чыгышларын бик сагаеп, шикләнү катыш курку аша кабул итте. Дөресрәге, кабул итә алмады. Ул дәвердә аның тарафдарлары берән-сәрән генә фанатиклар иде.

Булат Сөләйманов Себер татарлары теле белән дә, гореф-гадәте, мәдәнияте белән дә тамырдан аерым халык, казан татарлары белән бернинди уртаклыгы да юк, дигән фикерне алга сөрә башлагач, язучылар да аның бу адымына шикләнеп карадылар. («Тукай телендә язачакмын», дип күтәрелгән шагыйрь телебезгә хыянәт итәме?)

Бу хакта ярсып бәхәсләшкәнебез хәтердә.

— Син бит Себер татарларын фаҗигагә алып барасың. Меңнәрчә еллык тарихы, язма әдәбияты булган төп ана милләттән аерылып нишләмәкче буласыз?

— Без анда җирле милләт булып саналмыйбыз, әнә, Казаныгыз бар, шулар ярдәм итсен, диләр безгә. Хантларга, мансиларга төрле ярдәмнәр күрсәтелә, финанс ягыннан да. Ә безгә — берни юк.

— Без казан татарларыннан телебез белән дә, гореф-гадәтләребез белән дә аерым халык, дигәч, Мәскәү: «И-и, нигә күптән әйтмәдегез аны?!» — дип, кочаклап алып, Себер татарларының башына алтын яңгыры яудырачакмы?!

— Без бу хәлдә яши алмыйбыз. Бетеп барабыз бит. Соңгы талпыныш бу!

— Халыкны халык түгел, ә берике кеше саташтыра. Үз файдасын кайгыртып... Мисалга Зәки Вәлидине генә ал. Амбиция көчле тегенең. Казан-

да беренче зат була алмасын аңлагач, Урал ягына китеп, гаскәр туплый, кече Башкортостан республикасы оештыра. Хан буласы килә, беренче буласы килә! Син дә, Булат, аерымлансак, мин себер татарларының Тукае булам, дип йөрисеңме әллә? Тукай булу өчен Тукай булу кирәк бит әле!

Кызып, кыргый халәткә кергәндәй кайнарланып, учын — йодрыкка, йодрыгын учка бәргәли-бәргәли йөргән Булатым, шул мәлдә сабырланып калды. Күз төпләре дымланып чыкты.

— Син ничек минем хакта шулай уйлый аласың?.. Мин үзем өчен дип йөриммени... Ничек аңлатырга сезгә. Менә килеп кара үзең, Себер татарларының үтә алмаслык сазлыклар арасында ничек интегеп яшәвен. Сез бит казаннар, аңламыйсыз безнең хәлне...

Бу сөйләшүдән без авыр тойгылар белән аерылыштык. Ул чакта кесә телефоннары юк иде шул. Төмәндә төрле елларда ике тапкыр булсам да, күрешә алмадык. Булат командировкада иде...

Төмәндә күренеклерәк урыннарны казан татарлары биләгән. Җирле татарлар алар өчен әллә бар, әллә — юк. Гореф-гадәтләре ниндиерәк, асылына төшеп карарга мөмкинлек булмады, себер татары — басып торышы (осанка), йөз-кыяфәте, йөреше, мөгамәләсе, холык-фигыле (телне әйткән дә юк!) ягыннан безнең белән чагыштырганда, бөтенләй икенче «камырдан» әвәләнгән. Бу халыкның чишмә башы — империяләр, каганатлар төзегәндә татар байрагы астына кергән кайсыдыр монгол кабиләсенә карыйдыр кебек...

1990 елның декабрендә Төмән өлкәсе татарлары корылтайга җыела. Көн тәртибендә: «Сыбыр» татар җәмгыятен төзү каралачак икән. («Сыбыр» — Булат Сөләйманов тәкъдим иткән исем. Ул чакта кытай чыганакларын тәрҗемә иткән Паркер китабы чыкмаган иде шул. Һуннарда СИБИР — сәргаскәр исеме булган. Нык ир мәгънәсендә.)

Менә шул Корылтайга Булат килеп кергәч, аны алкышлар белән каршы алалар, Президиумга утыртырга дип тәкъдим белән чыгалар. Күкрәге белән амбразураны капларлык фидаи Булатның болай таныла башлавы кемнәрнеңдер касыгына тия. Өлкәнең Исполком комитеты урынбасары трибунага чыгып, халыкка «бомба» ташлый: зур бер чарада биек мөнбәрдән Булат: «Себер җирендә сез руслар — килмешәк халык», дигән икән бит!

Котырган үгез кебек, залның күзен кан баса. Зәки Зәйнуллин әйтмешли, «тапыйлар» Булатны. Бигрәк тә кушканны күндәм үтәүче куштан татарларыбыз.

Булатның рухы сына, канатлары салына. Ул берьялгызы өенә кайтып китә. Шул көннән соң ул берәүгә дә күренми. Мондый чакта ир кеше нишли, гадәттә, йөрәк ялкынына хәмер утын бөркеп, һәлакәт упкынын якынайта.

1991 елның 11 гыйнварында ул, фатирында ялгызлык иңенә башын салып, дөньядан китә.

Тукай фикеренчә, инде «үлеп аңлаткач», шагыйрьнең иҗат чишмәсеннән илһам алу тамчылап-тамчылап кына, милли-рухи мәсләгенә якынаю адымлап-адымлап кына барды. Сагаюлы, икеләнүле, шикләнүле еллар аша, бик акырынлык белән генә төшенү килде.

Хәзер инде ел саен Төмән китапханәсенең милли бүлегендә «Сөләйманов укулары» дигән конференция үткәрелә. Монда Төмән һәм Тубыл Педагогия университеты галимнәре, студентлар, мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр, укытучылар катнаша. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты хакында фәнни хезмәтләр, истәлекләр укыла. (Әле быел гына Төмән университеты тарафыннан ЖЗЛ сериясеннән «Булат Сөләйманов» дигән китап бастырылган.)

***

Ул елда... Булатның үлеме хакында хәбәр килгәч, тетрәнеп калган идем. Нинди тәкъдиргә дучар булган бит. Тәненнән аерылган җаны, гарешкә очып китә алмыйча, бикле ишек-стеналар арасында ай ярым чарасыз бәргәләнгән. Көтелмәгән ялгыз үлем... аянычлы гомер соңы... Тетрәнүемә юаныч эзләп, мин ул чакта каләмгә тотынган идем. Менә ул шигырь юллары:

Кучем ханның соңгы оныгы син,
Соңгы могиканы Себернең.
Шәһре Казан хан итмәде сине, —
Сыра саттың, урам себердең.

Себеркеңне ташлап, каләм алдың,
Шагыйрь булып киттең Казаннан.
Кыл урталай бүленсен дә җаның...
Андыйларны шөһрәт казанган?..

Юк, барыбер, ялгышларың белән,
Хаталарың белән Бар идең!
Себер җилен егып көрмәкләшер
Мәйданнарың гына тар иде.

Карагайлы урман куенының
Аюлары уянган мәлдә —
Шул эзләрне эзләп чыккан булсаң,
Аумас идең ташлы мендәргә.

Кичерерме заман, — маңгаеңда
Сырланмыйча калган елларны?
Идел белән Иртеш арасында
Җырланмыйча калган җырларны?

Бар да алда, диеп яшәгәндә
Күңел менә сыктап айкала.
Син дә кинәт шулай үлә белгәч,
Бу тормышта безгә ни кала?

БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВ ШИГЫРЬЛӘРЕ

ХАТЛАР

Бу җилләр хәтернең түреннән,–
Үзләре шәп-шәрә, бик арык –
Үткәннең сандыгы төбеннән
Хатларны чыгарды актарып.
Саргайган ул хатлар хәтердә –
Күбәләк шикелле дерелди.
Син бит ул, нигә соң дәшмисең?
Ул көннәр яңадан терелде.
Караңгы төндәге яшен күк
Ялтырый, югала хәтердә,
Һәр юлы – яшьлекнең тарихы:
«Булырбыз, булырбыз без бергә!..
Хәтернең өрәге булма син.
Кил бире, алыйм мин бер кочып.
«Сөямен», дип язган сүзләрең
Хатлардан киткәннәр шул очып.
И хәтер! Син җәллад түгелсең.
Тоз сипмә ярама син берүк.
Кайтса да яшьлектән ул хатлар,
Безгә бит яшьлеккә кайту юк.

***

Күренми шул Себер Казаннан,
Анда карлар, җилләр уйныйдыр.
Ә тайгада болан баласы
Адашкан да ялгыз елыйдыр.

Хет җилләре хәбәр бирсәче:
Ничәнче көн эзли анасын?
Аерылу авыр кемгә дә,
Тайга киң шул, каян табасың!

Эзләреннән бүре киләдер,
Борылыр да иде ирегә,
Юк, ярамый, алга ыргылды,
Балачагын калдырып бүрегә.

Шулайдыр ул хәлләр минем дә:
Эзләремне карлар көридер.
Адашкан да тайга эчендә,
Балачагым елап йөридер.

***

Мин – төп Себер татарымын
чыгышым белән,
Гомер сөргән монда
минем бабаларым.
Чал Иртышның үзе кебек,
борынгыдан
Яшәп килә монда татар балалары.

Мин килмешәк түгел монда,
туган җирем,
Гомерлеккә сине ташлап китә
алмам.
Җирнең тарту көчен җиңдек,
и Себерем,
Ләкин синең тарту көчең
җиңә алмам.

НИГӘ МИНЕ АЛЛА КЕШЕ ИТКӘН?

Мин тауларга карап сокланам гел,
Таулар горур, таулар бик биек.
Нигә мине Алла кеше иткән?
Кеше булып, булмам мин бөек.

Урманнарга керсәм, хәйран калам,
Каян ала урман моңнарын?
Нигә мине Алла кеше иткән?
Кешеләрдә моңның иң тары.

Кырга чыксам, үлән арасында
Чикерткәләр йөри серләшеп.
Алар да бит миннән бәхетлерәк,
Һәр көн саен үтәм көнләшеп.

Нигә мине Алла кеше иткән,
Булмаганмын агач йә үлән?
Шагыйрь күңелем түзмәс
бу хурлыкка,
Йә, хушыгыз, дуслар, мин үләм!

БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВ ХАТЫ

Хөрмәтле редакция!

Бу хатны мин үзем кебек кайбер иптәшләрнең соравы буенча язам. Без Казанда чыга торган «Совет әдәбияты» журналын ел саен алдырабыз. Аның һәр номерын зур түземсезлек белән көтеп алабыз һәм бик яратып укыйбыз. Яраткан язучыларыбызның яңа әсәрләре белән танышабыз. «Совет әдәбияты» журналының соңгы битләрендә «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» урнаштырыла. Анда төрле кичәләр, иҗат секцияләре булганлыгын журнал аша булса да ишетеп куанабыз, ләкин шунысы кызганыч, алар бер генә җирдә, бары тик Татарстанда гына булалар. Ә бит татарлар анда гына түгел, бер Төмән өлкәсендә генә әллә ничә меңләгәне яши, ә бөтен Себердә күпме алар!

Поэзиягә беренче адымнарын ясап караучы, поэзия белән кызыгучы *(кызыксынучы. — Л.Л.)* иптәшләрне юк дип әйтерлек түгел. Алай булгач нигә бездә, Себердә иҗат секцияләре узмый икән? Тоболда үткәрергә була бит ләбаса. «Совет әдәбияты» 1961 елның беренче санында «Яшь язучылар семинары»н укыдым. Анда менә мондый сүзләр язылган иде: «Әдәбиятыбызга килә торган яшь көчләрне тәрбияләп үстерү, аларның иҗат активлыкларын күтәрү буенча Татарстан язучылары союзы күп кенә чаралар үткәрә. Шундый әһәмиятле чараларның берсе башлап язучыларның иҗат семинарларын системалы рәвештә уздырып барудан гыйбарәт». Анда 40ка якын кеше чакырылган, ә шуларның арасында безнең Себердән берәр иптәшнең булуы икеле. Тагын башлап язучыларның семинары Мөслимдә уздырылган. Мөслимдә һәм Татарстанның башка районнарында башлап язучылар семинары үткәрергә мөмкин икән, ә нигә Себердә дә үткәрергә мөмкин түгел? Азмыни безнең татар язучыларыбыз, шагыйрьләребез, драматургларыбыз. Аларның бер-икесенә безгә килеп семинар үткәрергә була бит. Сез дә килмәсәгез, Себердә яшәүче яшь көчләрне кем тәрбияләп үстерер.

Без бары сездән генә ярдәм көтә алабыз. Безгә килеп китегез, хөрмәтле абыйлар!

Булат Сөләйманов. 10.02.1961 ел. *(Хат ахырына кемдер Б.Сөләймановның адресын язып куйган: Тюменская область, Дубровинский район. Б-Карагай. — Л.Л.).*

*Хатны басмага **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

Әсәрләр:

Патии К. «Әлгасрелҗәдид» журналына // Әлгасрелҗәдид. — 1907, 25 гыйнвар; Кәшшаф Патии шигырьләре. —Казан: 1910; Патии К. Тукыз чәчәк. — Казан, 1912; Патии К. Әшгарь. — Казан, 1915.

Әдәбият:

Татар шигърияте: XX гасыр башы. — Казан: Мәгариф, 2004. Б.200; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Библиографик сүзлек. — Казан, 2005. Б.276; Әскәров М. Патиевлар // Ватаным Татарстан. — 2000, 11 август.

ПАТИИ КӘШШАФ (Габделкәшшаф Шәриф улы Патиев) (1884-XX йөзнең I яртысы) — шагыйрь, педагог, мулла. Беренче китабы басылып чыгу уңае белән, «Идел» газетасы (1910, №241), яшь шагыйрьнең иҗатын зурлап, игълан-рекламада *«...гүзәл, милли вә тәэсирле шигырьләр. Кәшшаф Патии җәнабләре ошбу мәҗмугадагы шигырьләре илә Г.Тукаевтан соң беренче шагыйремез диюгә лаеклыдыр»,* — дип язган. Кызы Рауза Патиева сүзләренә караганда, Казанда укыган һәм әдәби иҗат белән шөгыльләнеп яшәгән 9 ел дәверендә (1907-1916) К.Патии Тукай белән дә таныш була, аралаша. Иптәшләре Кәшшафны Габдулланың сәламәтлек буенча «подшефные» итеп билгелиләр. Моның сәбәбе Кәшшафның университетның медицина факультетына ирекле тыңлаучы буларак лекцияләргә йөрүендә булса кирәк.Тукай иҗаты К.Патииның үзен дә шигырь язуга рухландырган. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 1 нче санында басылган «Әлгасрелҗәдид журналына» дигән шигырендә К.Патии журналны һәрьяклап мактый һәм аны чыгаруда төп фигура булган Тукайны: *«Ул тарафта аның кеби шагыйрь юктыр, һәр шигыре укучыны уйландыра»,* — дип искә ала.

К.Патии Г.Тукайның вафатын авыр кичерә. 1915 елда дөнья күргән «Әшгарь» исемле җыентыгында аның «Тукайга» дигән шигыре урын алган. Эчтәлегенә караганда, шигырьнең Тукай вафатыннан соң язылганы аңлашыла. Ул Тукайның талантын җемелдәп торган асылташларга тиңли, *«аның һәр язган сүзе бөек максатка юл ачучы»,* — дип белдерә. Шигырьдә халкыбыз һәм телебез яшәгәндә Тукай да яшәячәк, дигән фикер үткәрелә.

Әнисә Алиева,
филология фәннәре кандидаты

АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

Мәшһүрләр гомерендә әледән-әле расланганча, олуг шагыйрьләр һәрбер заманда да фикер ияләре буларак кабул кылынган.

Гомумән, мәгънәви сайлыктан калкына алмаган иҗат зур әһәмияткә ирешүдән ерак тора. Ә шигъриятнең үзәк тамырын тәшкил иткән образлы фикерләүне исә җанны җилкендерерлек канатлы сүзләрдән башка күзаллау бөтенләй мөмкин түгел. Табигый ки, хәкимлек биеклеген яулаган шагыйребез Габдулла Тукай иҗатында да мөһим хикмәти кыйммәтләрне үзенә сыйдырган гыйбарәләр күпләп күзәтелә. Дөрес, аның махсус рәвештә афоризмнар язарга җае чыкмаган, гәрчә әдәбиятта андый жанрның булуын белсә дә. Шуңа күрә Габдулла Тукайның аерым туплап бирелгән әлеге фикерләрен афоризмнарга тиңләмичә, аларны шагыйрьнең язма мирасыннан берәмтекләп җыелган фикри сөземтәләр итеп карарга кирәк.

Әлбәттә, тематик әңгәмәләр санынча биш бүлектән торган ошбу тупламда афоризм таләпләренә туры килгән хикмәтле «резюме»лар да байтак. Алары безгә яхшы мәгълүм. Төрле буыннар теленнән төшмәгән канатлы сүзләр моңарчы игътибар җитеп бетмәгән фикерләргә ялгана. Монда төрлесе очрый: зирәкләрчә әйтелгән гыйбарәләр дә, хөкемгә охшаш тәгъбирләр дә, үгет-нәсыйхәтле сентенцияләр дә, шигардәй яңгыраган өндәмәләр дә... Фикри тирәнлекләре белән сокландырган әлеге берәмлекләрнең һәркайсы заманча кабул ителеп, җәмгыятьнең көнүзәк проблемаларын эчтән яктыртып күрсәтә. Аларда ачы тәҗрибә аваз сала, аларда милләт гаме сыкрап тора. Һәм инде шунысын да ышанып әйтергә мөмкин, бөек шагыйребезнең иҗтимагый әһәмияткә ия булган бу канатлы сүзләре тапкырлыкны үз күргән газиз халкыбыз белән бергә киләчәккә бара.

I

● Бала шулай тәслим ителә[1]. Аның атасы яһүди булса, бала киләчәктә яһүд милләтенә хезмәт итәрлек рәвештә тәрбия ителә. Атасы нәсрани[2] булса, янә, нәсрани милләтенчә тәрбия кыйлынып, киләчәктә үз милләтенә файдалы бала булуы күзгә алына... Менә без, татар балалары да, татар милләтенчә тәрбия кыйлынганбыз.

● Без шушы олуг мәмләкәтемезнең сакчысы вә чын гражданы... булырга тиешлемез.

● Без дә кеше ич, итик гайрәт Алла гыйшкы хакына; бу дөньяны хәйран калдырыйк Алла гыйшкы хакына.

***

● Очып төш тә балалык бишегеннән, ябыш — аерылма мәктәп ишегеннән.

● Бәхетле нарасый... Тар бишек тә киң әле аңгар!.. Вәләкин бир заман, ул тик бераз үссен дә ир булсын; күренер киң җиһан аңгар кабердән һәм ләхеттән тар.

● Мәгариф бакчасында очып йөр, ашау-эчү өчен күңелең борчылмасын. Үзеңне «байлардан ярлы» дип санама; тыр-тыр итеп бәлешләргә йөгермә... Бәлеш белән гыйлем бергә җыелмас... Азыгыңны Алладан өмет ит.

● Тук корсак укуга бик йомшак, бик чукрак буладыр.

● Каз канатлары ак булыр,
Ир канатлары ат булыр.
Сабыйларның канатланыр вакъты
Мәктәпләрдә укыр чак булыр.

● Мәгариф — хәяттыр. Һәр бәхетне, һәр сәгадәтне, һәр нәҗатны[3]... голүм[4] вә мәгърифәттән генә көтмәк кирәктер.

● Өч наданга алмашынмас — бер язу белгән кеше; мәгърифәт эстәр, иренмәс һич — кеше булган кеше.

● Ялкаулык та наданлык — бүләк безгә Алладан.

● Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул; картаеп каткач буыннар, эш белү уңгайсыз ул!

● Эш беткәч уйнарга ярый.

● Наданлык таптамасын — яньчелербез, каләмгә каршы бармыйк — чәнчелербез.

● Надан булу — гарь, татар, аңгар дөнья тар, татар; алсаң өлеш һәр фәннән, бәхетең булыр яр, татар.

● Наданнарның дошманлыгы белән мактанырга кирәк; аларның һәр сүгүе — синең өчен мактаныч кына.

● Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк.

● Адаштым дип егълый күрмә: гыйлем чын эз табар әле.

● Булганы белән канәгатьләнмә, тәрәккый ит, алга бас; гыйлем диңгезләренең иң тирәне сиңа кояр.

● Ике юл бар бу дөньяда: бере будыр — бәхет эстәү; икенче шул: гыйлем гыйшкында булмак — мәгърифәт эстәү. Синең кулда: теләрсәң — мәгърифәтле бул, бәхетсез бул; вә яки бик бәхетле бул, ишәк бул, мәгърифәтсез бул.

● Бәхетле шул баладыр, ...кечеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурга юл бирсә, бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә.

● Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын; мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

● Укымак — дөрестнең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр. Укымак — фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. Укымак — үз яныңда булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. Укымак — үткәннәрне кичеп, киләчәкләр... тугърысында пәйгамбәрлек итмәк. Укымак — хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне чишү юлына ташламак димәктер... Укымак — үзеңне һәрнәрсәне белергә вә һәр максудка ирешергә вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр. Укымак — ...гакыл пычагын гыйлем вә мәгърифәт кайрагына чынлап кайрамак дигән сүздер... «Укымак» ләфзы[5] астында моның кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкымызга хезмәт итмәк дигән сүзгә кайтадыр.

● Милләт образауный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан[6] вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ.

● Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, ... яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ. Бу әйтелгәннәр булмаганда, безнең тормышымыз күңелсез, үлек чыккан өй төсле моңлы, тынсыз-тавышсыз, рәхәтсез булачактыр.

● Мәгариф тарату булсын бездә гадәт; бит шуңа бәйле бәхет-рәхәт.

● Мәктәпләр — сезнең арсенал, татар... Өмет анчак[7] мәктәпләрдә генә!

Сүзлекчә

[1] Тәслим ителү — кемгә дә булса тапшыру;
[2] Нәсрани — христиан динендәге кеше;
[3] Нәҗат — котылу;
[4] Голүм — гыйлемнәр;
[5] Ләфзы — сүзе;
[6] Мәнафигъ — мәнфәгать, интерес;
[7] Анчак — бары тик.

Дәвамы бар

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага
***Зиннур Мансуров** әзерләде* ■

УРЛАНГАН ТАКТА КЫЙССАСЫ

Мөбарәк Мусин

КЕМ УЛ ГОМӘР ГАЛИ?

Гомәр Гали — 1920 -1930 еллар татар совет әдәбияты үсешенә күп көч куйган күренекле әдипләрнең берсе. 1937 елда гаепсезгә репрессияләнә, 1955 елда гына аклана. Ул — күренекле татар совет язучысы, әдәбият белгече, публицист һәм тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе.

Татар әдәбияты тарихына Гомәр Гали үзенең «Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында һәм Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир булып эшләве белән, 15 китап һәм көндәлек матбугатта басылган йөзләрчә мәкалә авторы һәм үз заманының көчле әдәби тәнкыйтьчесе буларак кереп калган. Зур җаваплы җәмәгать эшләре алып барган. Аның 1925-1932 елларда яңа оештырылган татар пролетар язучылар ассоциациясенең рәисе булуын һәм бүгенге Язучылар берлеген оештыручыларның берсе булуын әйтү дә җитәдер. Сүзем бит Гомәр Галинең исемен мәңгеләштерү чараларының

берсе — аңа мемориаль такта кую турында иде.

МЕМОРИАЛЬ ТАКТА КУЮ

Буа якташлык җәмгыяте һәм язучының Казанда зур урыннарда эшләүче унлап якташы Татарстан мәдәният министрына, шәһәр хакимиятенә һәм республика Язучылар берлегенә 2005 елның июлендә хат юллаганнар иде. Хатта аның 1931-1937 елларда (репрессиягә кадәр) яшәгән Кави Нәҗми (Г.Гали аның белән 15 еллап бергә эшләгән) урамындагы 24/20 йорт бинасына мемориаль такта кую һәм Казан урамнарының берсенә аның исемен бирү турында да соралды. Мин аның нинди кыенлыклар белән куелуын язып тормыйм, чөнки ул

Татарстан Министрлар Кабинетының аерым эшләнгән кагыйдәләре буенча һәм бик күп оешмалар килешүе белән эшләнә. Ә инде истәлек тактасын ясатып урынына куйганчы да ярты елга якын вакыт үтте, тулаем алганда — бер ел дигән сүз.

Истәлек тактасын (авторы — сынчы Мәхмүт Маталит улы Гасыймов) ачу тантанасы язучының туган көне — 16 июньдә (2006 ел) булды. Тантанада Язучылар берлеге, Мәдәният министрлыгы вәкилләре, язучының кызлары һәм туганнары, Г.Гали исемен йөртүче Иске Тинчәле авылы урта мәктәбе җитәкчеләре һәм Казан шәһәре җәмәгатьчелеге актив катнашты.

Сүзем бит аңа куелган истәлек тактасының кыйссасы турында иде, шуңа күрә тантанадагы чыгышларга тукталып тормыйм.

ГОМӘР ГАЛИНЕ... УРЛАГАННАР

...Бер елдан артык вакыт үтеп китте. Очраклы рәвештә генә, Татарстан Милли архивында утырганда Буаның туган якны өйрәнү музее директоры Люция ханым Әхмәтҗанова белән очраштым. Безнең танышлык та шул ук Гомәр Гали аркасында, чөнки Буа музееның «Буаның данлыклы кешеләре» залында әдипкә багышланган аерым бүлек бар һәм репрессияләләр залында да аның фотолары урнаштырылган. Ул исән вакытта яшәгән йорты һәм аның

«Галимҗан Ибраһимов әдәбиятыбызның мәгънәви президенты, рухи җитәкчесе булса, Гомәр Гали – әдәбиятыбызның баш министры иде».

Хәсән Туфан

диварына эленгән мемориаль тактасы архивтан ерак булмаганга, Люция ханым аны күрсәтүне сорады. Бу 2007 елның ноябрь бәйрәме вакыты булгандыр. Сөйләшеп барабыз, килеп җиткәнне сизми дә калдым. Күтәрелеп карасам, истәлек тактасының юклыгын күргәч, аяктан егыла яздым. Ниндидер бәдбәхетләр, 90 кило бронзага кызыгып, сынчы тарафыннан ясалган, заводта коелган истәлек тактасын вәхшиләрчә каерганнар да, алып киткәннәр һәм металл ватыклары кабул итү пунктына тапшырганнар. Монысы инде соңрак мәгълүм булды. Бүгенге көнгә кадәр гаҗәпләнәм — ничек, күрә торып, язулы бронза тактаны (истәлек тактасын!) кабул итеп алырга кирәк?! Органнардан курыкмаса да, Ходайдан шикләнергә тиеш бит инде ул, миңа калса. Бу кадәресе әлегә билгеле түгел, кунакны үзен генә калдырып, мин милиция бүлегенә йөгердем. Биредә гариза бирергә тырышкач, мине:

— Нигә бу турыда мәдәният министрлыгыннан яки Язучылар берлегеннән рәсми рәвештә хәбәр итмиләр? — дип «хупладылар». Үземнең Буа якташлык җәмгыятенең идарә, Татарстан, Россия журналистлар берлекләренең әгъзасы икәнемне сиздергәч кенә, гаризаны кабул иттеләр. Югыйсә, аяныч күренеш турында хокук сакчыларына хәбәр итәргә теләсә кемнең хакы юкмыни?

Меңнәрне һәм миллионнарны төрмә тузанына әйләндергән репрессия тегермәне дә әниемнең энесен — татар язучысы Гомәр Галине, шәхес буларак, юкка чыгара алмаган бит. Ул, коточкыч кыен шартларда изелгәннән соң да, милләтенә хезмәт итәрлек хәлдә калган. Соңгы чиктә аны физик яктан юк иткәннәр. Төсле металл караклары менә кемгә кул күтәргәннәр?!

Эшнең алга баруын сизмәгәч, язучының кече кызы Гүзәл ханымга Мәскәүгә шалтыраттым. Хәлне аңлаткач, кичекмәстән Президентыбыз Минтимер Шәймиев исеменә хат язуын үтендем. Президент Аппаратыннан Гүзәлнең хаты, анда күтәрелгән мәсьәләләрне хәл итәр өчен, Премьер-министрның урынбасары — мәдәният министры Зилә Вәлиевага һәм эчке эшләр министры Әсгать Сәфәровка җибәрелгән. Дөрес, аңа кадәр дә, минем гаризам буенча, Вахитов районы эчке эшләр идарәсе җинаять эше ачкан иде инде.

Барыбер урланган мемориаль тактаны таба алмадылар. Аны, кискәләп, металлоломга тапшырулары, бер наркоман егетне тотып, шуның өчен 3 елга хөкем итүләре билгеле булды. Хөкем карары миндә саклана.

Кирәк бит, теге чакта ул тактаны минем күз алдымда, йөк машинасын дивар янына якын китереп, тактаны шушы машина кузовыннан дүрт таза егет, сыек металл кулланып, диварга беркеттеләр. Ике сәгатьләп вакыт үтте. Шул авырлыктагы металлны бер кечкенә генә буйлы наркоман егет дивардан каерып алып, илтеп тапшырсын инде?! Ә нигә аның иптәшләрен, кабул итүчесен кулга алмаска?! Бронзадагы барельефны да, истәлек язуын да күрә бит ул! Урамда аунап ята торган нәрсә мени?! Мондый язмалар: «Дөреслек җиңде!» — дип бетәргә тиеш тә бит, алай бетереп булмый. Вандаллык буенча бу бит беренче очрак кына түгел.

Шагыйрь Хәсән Туфанның истәлек тактасы да шундый мәрхәмәтсез язмышка юлыккан иде. Угры тотылса да, тимер белән суккалап янчелгән, сатарга әзерләнгән сынны яңадан элеккеге урынына куя алмадылар. «Элекон» заводы директоры, Социалистик Хезмәт Герое Лотфулла Гыйззәтдиновның да тактасы Гагарин урамының 89 нчы йортыннан ике мәртәбә урланды. Аптырагач, тимер-томыр җыючы «кәсеп»челәрне кызыктыра торган бронзаны мәрмәр тактага алмаштырдылар. Бары тик шуннан соң гына истәлек тактасы дивардан кузгатылмады…Әмма караклар иректә калдылар, бүтән «азык» эзләргә булдылар.

ИКЕНЧЕ ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ

Гомәр Гали истәлегенә әйләнеп кайтыйк әле. Буласы булган, дидек, иң әһәмиятлесе, Президент исеменә язылган хатны искә алып, шул ук урынга 2008 елның 3 июнендә Мәдәният министрлыгы тарафыннан яңа такта куелды. Бу икенче такта да Язучылар берлеге тарафыннан, әдипнең туганнары һәм шәһәр җәмәгатьчелеге белән берлектә, тантаналы рәвештә эленде. Бу турыда матбугат чаралары да читтә калмады. Татарчада бармы икән ул мәкаль, укыганым юк, ә руслар «Не было бы счастья, да помогло несчастье», — диләр. Бу истәлек тактасы бүтән материалдан ясалган, мәрмәр ташка бронза йомычкаларын кушып, белгечләр әйтүенчә һәм үткән тәҗрибә буенча да, җинаятьчеләрнең игътибарын җәлеп итәргә тиеш түгел. Материалы еректан яктырак күренеп тора, барельефы гына бронза белән каплатылган. Бу хәл мине уйланырга мәҗбүр итте. Шуңа, ведомстводан тыш сак хезмәтенә барып, сәнгать әсәрләренең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләсе белән кызыксындым. Алар миңа «бу хәлдән чыгу юлын» тәкъдим иттеләр: янәшәдәге берәр оешмага сигнализация урнаштырып, әлеге хезмәтне күрсәтергә әзер икәнлекләрен әйттеләр. Моның өчен, ай саен «фәкать» унар мең түләргә туры киләчәк (бу әле 2007 елгы тариф белән!) — Әмма әлеге чыгымны Мәдәният министрлыгы да, Язучылар берлеге дә күтәрә алмый, минем ише пенсионер — бигрәк тә. Тик, шулай да, сынчыга һәм коючыларга зур акчалар түләп ясаттырылган, җитәкчеләр катнашындагы урам җыенында җәмәгатьчелек хозурына тантаналы рәвештә тапшырылган әдәбият-сәнгать һәйкәл-истәлекләре, миңа калса, күз карасы кебек сакланырга тиеш. Димәк, хөкүмәтнең бу уңайдан хәлне уңай якка үзгәртерлек карар кабул итүе зарур.

ӨЧЕНЧЕ ТАКТА КУЕЛДЫ

Бу хәлләр турында «Не везёт Гумеру Гали» дигән язмам рус телендә «Звезда Поволжья» газетасында басылып чыкты. Мәкаләмне укып, миңа телефоннан шалтыратучылар күп булды, әмма алар хөкүмәт структураларыннан да, хокук саклау органнарыннан да түгел иде.

Дөрестән дә «не везёт ведь», бер дә эшләр җайга гына бармый. 2010 елның декабрендә ул урамнан узып барышлый, бу тирәдә булганда карап китәргә тырышасың бит инде, күзем тактадагы яхшы ук күренерлек ярыкка төште. Тактаның сул ягының урта бер җиреннән ярык бер 20-25 см уртага кергән һәм язылган текст аркылы аска кадәр сузылган. Тактаның дүрттән бер өлеше җиргә кителеп төшәргә мөмкин. Күп уйлап тормыйча, сынчы Мәхмүт Гасыймовка шалтыраттым:

— Яңадан туган «балабызны» тагын югалтабыз, — дим. Бер дә юкка гына Мәхмүт Маталит улы Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы түгел икән, оператив рәвештә, шул ук көнне килеп, мемориаль тактаны фотога төшереп, заводка белгечләр янына ашыкты. Берничә көннән тактаны егетләр «дәваларга» алып та киткәннәр.

Яңа ел каникулларыннан соң барып карасам, өр-яңа мемориаль такта шул ук урында эленеп тора иде. Шулай итеп, 2012 елның 15 гыйнварында Гомәр Галигә өченче мемориаль такта куелды. Казанда булмаган хәл! Бәлки, бусының, Гомәр исеме урынына «Гомер» дип язылганга, гомере озын булыр?! Гәрчә беренче тактасында да хата бар иде, «күренекле» урынына «куренекле» — дип язылган иде.

Укучым, мине гафу ит, кыйсса моның белән генә бетми бит әле. 2013 елны Гомәр Галинең мемориаль тактасы беркетелгән йортка Вахитов районы Идарә компаниясе капиталь төзекләндерү үткәрергә тотынган. Нигә шулай үткән заманда әйтәм, чөнки кемгә дә хәбәр итмичә, тактаны, беркеткән урыныннан алып, шушы йортның беренче катында урнашкан йогышсызландыру (дезинфекция) станциясенең профилактика бүлегенә кертеп куялар. Әле ярый бу маҗаралар вакытында андагы бер нечкә күңелле кеше — Людмила Васильевна белән танышып өлгергән идек. Ул йортны төзекләндерү вакытында тактаның иминлеген тәэмин итте. Эшләр тәмамлангач, ул төзекләндерүчеләр бригадасына истәлек тактасын яңадан үз урынына беркетү турында әйтеп тә карый, әмма аны кем тыңласын? Гәрчә, үзләренең кагыйдәләре буенча, алар ул эшне эшләргә тиеш! Бу хәлләрне белгәч, мин инде Язучылар берлегенә хәбәр иттем. Ул вакыттагы рәис урынбасары Вакыйф Нуриев Идарә компаниясенә кичекмәстән хат яза, кагыйдә буларак, истәлек тактасын урнаштырырга вәгъдә бирәләр дә... оныталар, аннары хатны да югалталар. «Не везёт» сүзен тагын кабатларга туры килә инде. Һәр эшен җиренә җиткерергә күнеккән Вакыйф Вәкил улы «тәртипсезләр»гә икенче хатны әзерләп бирергә мәҗбүр була һәм Гомәр Галинең өченче истәлек тактасы (баштан ук санаганда) дүртенче мәртәбә диварга беркетелә. Ошбу такталар кыйссасы шуның белән тәмам.

ГОМӘР ГАЛИ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

Язмамның башында искә алган Буа якташлык җәмгыятенең һәм язучының Казанда яшәүче якташлары хатында башкалабызның бер урамына Гомәр Гали исеме бирү турында да соралган иде. Татарстан Министрлар Кабинетының 2007 елның 28 апрелендә 155 санлы һәм Казан Муниципаль берәмлеге Башкарма Комитетының 2007 елның 22 июнендә чыккан 1353 санлы карарлары нигезендә, Идел буе районының «Трубная» дигән урамына Гомәр Гали исеме бирелде. «Не везёт» дип алда әйтелгән сүзем бу чарага да кагыла. Әлеге урамда Гомәр Гали исеме белән элмә такталары пәйда булуга ук, мин аларны күрергә ашыктым. Озын ук урамның йорт диварларына 5-6лап кына элмә тактасы эленүгә карамастан, күңелгә горурлык хисе иңде... Әмма дә шатланырга ашыкканмын. «Гомәр» сүзен ике хәреф хатасы белән «Гумар» дип язганнар. Кызганыч ки, 5 ел көтелгән элмә тактасына да хаталы сүз керткәннәр. Билгеле, мин аның белән килешә алмадым. Казан Аксакаллар Шурасыннан шәһәр топонимика комиссиясендә катнашып йөргән чак иде, Идел буе башкарма комитеты хезмәткәрләреннән нинди оешма ясаганын белешеп, хаталарны төзәттердек.

Язучының үткән ел Мәскәүдән кайткан кызы Гүзәлгә күрсәтергә дә күңелле булды. Чөнки Казанда шушы ике истәлек урыны гына калды бит аның: Гомәр Гали исемендәге урам һәм истәлек тактасы. Шундый күпкырлы шәхеснең каберенә чәчәк тә сала алмыйбыз, чөнки кабере генә түгел, ул җирләнгән Подпорожье авылы да әллә кайчан инде, Красноярск сусаклагычы төзелү аркасында, су астында калдылар... ■

МӨКАТДӘС ХӘЗИНӘ

Рамил Вәлиев,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты директоры, тарих фәннәре докторы, профессор

Ул хәзинә — бик хикмәтле:
гасырларның мирасы.
Шул мирасны саклаучылар —
бу тормышның хуҗасы!
Шаһинур Мостафин

ЧИШМӘ БАШЫ

Россия энциклопедистикасының ике йөз еллык тарихы һәм бай традицияләре бар. Беренче энциклопедия 1793-1794 елларда рухани Иоанн Алексеев тарафыннан төзелә, ул «Эшкәртелгән, уңыш бирүче иркен кыр, яки Гомуми тарихи оригиналь сүзлек» дип атала. Россиядә генә түгел, дөнья энциклопедистикасында да югары бәяләнгән гаять киң колачлы хезмәт булган Ф.А.Брокгауз һәм И.А.Ефронның «Энциклопедия сүзлеге»н (СПб., 1890-1907) атарга кирәк. Ул Россия империясендә энциклопедия фәне үсешенең иң бөек казанышы булып тора.

Советлар илендә энциклопедияләр бастыруга зур әһәмият бирелә. Әлеге басмалар дәүләттә большевиклар хакимиятенең нигезен һәм абруен ныгытуга, идеалларны тәгаенләүгә һәм раслауга хезмәт итәргә тиеш була. Шуңа күрә 1924 елда РКП(б) ҮК Политбюросы бу юнәлештә махсус карар кабул иткәннән соң, дистәләрчә еллар дәвамында өч тапкыр нәшер ителгән «Зур Совет Энциклопедиясе»ндә идеологик йогынты көчле булуы табигый күренеш иде. Әйтик, бу басмаларда кайбер халыкларның милләт булуы та-

нисбәттә Идел буеннан Йәмәнгә, Һиндстаннан Испаниягәчә сузылган җирләрне колачлый, ислам дәүләтләрендәге күренекле шәхесләр турында мәгълүмат бирә.

Ризаэддин Фәхреддиннең биобиблиографик рәвештә төзелгән, энциклопедия жанрына караган, 1900-1908 елларда беренче ике томы, 2010 елда өченче-дүртенче томнары нәшер ителгән, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында, шулай ук XVIII-XX йөзләрдә яшәгән 1200дән артык мәшһүр дин һәм җәмәгать эшлеклесе, галим һәм әдипләрнең биографияләрен үз эченә алган «Асар» җыентыгында Шиһабетдин Мәрҗани традицияләре үсеш кичерә.

1925 елда Казанда Исмәгыйль Рәмиевнең 1905-1925 елларда чыккан татар газета-журналлары, нәшриятлар, наширләр һәм мөхәррирләр турында системалы фәнни белешмә бирелгән «Вакытлы татар матбугаты» китап-альбомы дөнья күрә.

нылмады, аларга этник берәмлек («народность», «народ») буларак каралды. Үзебезнең тарихка килгәндә, мәгълүм ки, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Кырым ханлыгына карата берьяклы фикер хөкем сөрде. Бөек Ватан сугышына нисбәтле документларның күбесе яшерен фондларда сакланган шартларда, ул чор вакыйгаларына кагылышлы мәгълүматлар кылдан нечкә иләк аша уздырылып, укучыларга ирештерелде. Союздаш республикаларга 1960 елларда гына үз милли энциклопедияләрен әзерләп бастыруга рөхсәт бирелде, ә автономияле республикалар исә гомумән мондый хокукка ия булмады. Югыйсә, аерым алганда, татар-төрки энциклопедиясе төзү традицияләренең юлы сикәлтәле һәм озын, тарихы бай. Россиядә гомуммөселман энциклопедиясе төзүгә тәүге адымнар XIX йөздә үк, атаклы татар мәгърифәтчесе, тарихчысы һәм фикер иясе, дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗани тарафыннан ясала. Галимнең илле ел дәвамында эзләнү-тикшеренүләре нәтиҗәсендә алты томлык биобиблиографик «Вафийәт әл-әсляф тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләсе буынга сәламнәре») фундаменталь хезмәте языла. Ул хронологик яктан 663-1889 елларны, географик

Энциклопедик сүзлекчә буларак, тагын бер басмага — Әхмәтһади Максудиның фәнни һәм иҗтимагый-сәяси терминнарны туплаган зур хезмәте — «Фәнни камус» («Фәнни сүзлек») аңлатмалы сүзлегенә тукталу зарур. Автор 1 нче томның 2300 сүз һәм төшенчәне эченә алган дүрт кисәген генә бастырып чыгарырга өлгерә (10 мең терминны берләштергән 4 том эшләү ниятләнгән була). Туган якны өйрәнү юнәлешендәге фәнни белешмәлекләр төзеп чыгару эше менә шунда тукталып кала һәм бу өлкәдә дистәләрчә елларга сузылган торгынлык башлана.

1990 еллар башыннан Россия Федерациясендә төбәк энциклопедияләрен язу күтәрелеш кичерә: РФнең 52 субъ-

ектында 120дән артык төбәк энциклопедиясе (шуларның күпчелеге — соңгы унбиш елда) дөнья күрә.

Татар энциклопедиясе институты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан 1994 елның 3 маенда кабул ителгән «күптомлы «Татар энциклопедиясе»н әзерләү һәм нәшер итү буенча өстәмә чаралар турында»гы карары нигезендә ТР ФА структурасында оештырыла. Институт фәнни-тикшеренү һәм нәшрият учреждениесе буларак оешып, аякка басу чорында ТР Президенты Минтимер Шәймиевнең «Татар энциклопедиясе» программасы турында»гы 1997 ел 10 февраль Указы басылып чыгу гаять зур әһәмияткә ия вакыйга була. Указга ярашлы рәвештә, ТР Хөкүмәте тарафыннан 1997 елның 4 маенда кабул ителгән карар белән, «Татар энциклопедиясе»н эшләү максатыннан штат, финанс һ.б. мәсьәләләргә кагылышлы шартлар тудыру турында анык чаралар программасы раслана. ТР Министрлар Кабинетының 2007 ел 29 декабрь күрсәтмәсе энциклопедик басмалар эшләү һәм бастырып чыгаруның 2015 елга кадәрге чорны эченә алган программасын раслый. 1994 елдан 2010 елга кадәр Институт директоры вазифаларын күренекле дәүләт эшлеклесе, ТР Фәннәр академиясен оештыручы һәм аның беренче президенты, академик Мансур Хәсәнов башкара.

ТӘВӘККӘЛ ТАШ ЯРА

Беренче адымнарны ясау җиңел булмады. Штатларны тәгаенләү, сүзлекчә әзерләү, җиһазлар, финанс мәсьәләләрен уңай хәл итү бер хәл, күптомлы «Татар энциклопедиясе»н нәшер итү өчен җитлеккән фән, шулай ук икътисад, тарих һәм мәдәният тармакларына караган гомумиләштерүче фәнни хезмәтләр, камил фәнни терминология һәм төшенчәләрне бер телдән икенчесенә күчергәндә транслитерация ысулларының эшләнгән булуы шарт. Болар барысы да институт хезмәткәрләре алдына үтә җитди таләпләр куя — алар бер үк вакытта галим-авторлар да, мөхәррирләр дә, гыйльми экспертлар да, менеджерлар да: үзләре үк сүзлекчәләр төзиләр, авторларны һәм рецензентларны җәлеп итәләр, мәкаләләрне редакцияләләр һәм, корректор сыйфатында, хаталарын төзәтәләр, макет төзеп, хезмәтне басмаханәгә тапшыргач, нәшрият хезмәткәрләре белән эшнең соңгы ноктасын куялар. Узган юлга күз ташлап, бүген: «Иң зур һәм кадерле байлыгыбыз — уникаль хезмәткәрләребез, безнең коллективыбыз!» — дип горурланып әйтә алабыз. Чөнки институтта әтрафлы белемле, гаять бай тәҗрибәле белгечләр эшли. Хезмәт хаклары белән мактана алмасалар да, алар бүгенгәчә фидакяр хезмәт куялар. Өлкәннәр яшьләр белән тәҗрибә уртаклаша. Рус һәм татар телләрендә дөнья күргән «Татар энциклопедия сүзлеге»н эшләүгә керткән хезмәтләре өчен институтның бер төркем фәнни хезмәткәре — М.Х.Хәсәнов, Г.С.Сабирҗанов, Р.Н.Даутов, Р.М.Мөхәммәтшин, Р.В.Шәйдуллин, В.Г.Абзалова, А.В.Гарзавина Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендәге 2005 елгы Дәүләт бүләгенә лаек була.

Соңгы елларда «Населённые пункты Республики Татарстан. Краткий справочник» (1997), «Татарский энциклопедический словарь» (1999), «Татар энциклопедия сүзлеге» (2002), «Татарская энциклопедия» (т.1, 2002; т.2, 2005; т.3, 2006; т.4, 2008; т.5, 2010), «Татар энциклопедиясе» (т.1, 2008; т.2, 2010; т.3, 2012), «Республика Татарстан: природа, история, экономика, культура, наука» (2010), «Центральные органы государственной власти и управления Татарстана (1920-2010 гг)» (2010). XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасына бүләк итеп, 816 битлек «Татарстан. Иллюстрацияле энциклопедия» исемле белешмә әдәбиятлар нәшер ителде.

1990 нчы еллар башыннан Мәскәүдә Россия китап наширләре берләшмәсе (АСКИ) илебездә дөнья күргән иң яхшы китапларга даими рәвештә конкурс уздыра. 2013 ел йомгакларына багышланган әлеге бәйгедә Россиянең 39 төбәгеннән, 5 чит илдән килгән нәшриятлар катнашты, ягъни конкурска 170 нәшрияттан 548 басма тәкъдим ителде. «Иң яхшы сүзлек — энциклопедик басма» номинациясендә коллективыбызның ике ел дәвамында эшләгән хезмәте — «Татарстан. Иллюстрацияле энциклопедия» — утыздан артык китап арасында җиңеп чыкты. Безгә диплом белән бергә Россиянең тәүге китап бастыручысы Иван Фёдоров сыны ясалган гран-при да тапшырылды.

Институт тарафыннан нәшер ителгән басмалардагы күпчелек мәкаләләрнең авторлары — үз хезмәткәрләребез. Зарурлык туганда Татарстан Республикасы, Мәскәү, Санкт-Петербург, Россиянең башка шәһәрләре һәм төбәкләре фәнни оешмалары белгечләре дә хезмәттәшлеккә тартыла. Татар энциклопедиясе институты «Зур Россия Энциклопедиясе» дәүләт фәнни нәшрияты, Россиянең башка республика, край, өлкәләрендәге һәм шулай ук чит илләрдәге энциклопедик юнәлешле байтак кына нәшриятлар белән элемтәдә тора. Югары квалификацияле кадрлар әзерләү максатыннан, Татар энциклопедиясе институтында «Ватан тарихы», «РФ халыклары әдәбияты» (татар әдәбияты) һәм «Политология» белгечлекләре буенча аспирантура бар.

БЕЛӘГЕ ЮАН БЕРНЕ ЕГАР, БЕЛЕМЕ ЮАН МЕҢНЕ ЕГАР

«Татар энциклопедиясе» — күп буыннар тарафыннан тупланган мөкатдәс гыйльми хәзинә. Аны Татарстан, татарлар һәм илебез халыклары хакында китаплар китабы дип тә, шулай ук отышлы реклама, менә дигән күрсәткеч, дип тә бәяләргә мөмкин.

«Татар энциклопедиясе» толерантлык һәм милләтара татулык принципларын алга куеп төзелә. Энциклопедияне эшли башлаганда «барысы да — татарлар турында» принцибы белән бергә «барысы да — Татарстан турында» дигән принцип та нигез итеп алынды. Энциклопедиядә республиканың күпмилләтле халкының казанышлары, аның күренекле вәкилләре турындагы материаллар туплап бирелә. «Татар энциклопедиясе» милләтара татулыкны чагылдыруы белән дә бик кадерле. Шуңа күрә дә әлеге күптомлы хезмәтне республикабызның ике дәүләт телендә югары сыйфатлы итеп әзерләп бастырып чыгару һәм аны Татарстан халкына җиткерү — безнең изге бурычыбыз.

Татар энциклопедиясе институтының перспектив планында рус һәм татар телләрендә универсаль энциклопедияләр (алтышар томда «Татар энциклопедиясе») әзерләп нәшер итү кебек традицион юнәлешләр белән беррәттән, 2014-2018 елларда тармак энциклопедияләре («Казан: иллюстрацияле энциклопедия», «Татарстан Республикасының мәдәнияте һәм сәнгате: иллюстрацияле энциклопедия», «Татарстанның табигате һәм тарихи байлыклары: иллюстрацияле энциклопедия», «Татарстан Республикасының фәне һәм мәгарифе: энциклопедия», «Татарстан: тарихи энциклопедия» һ.б.) чыгару да каралган. Исемлекне «Татарстанның химия фәнни мәктәбе: фәнни белешмәлек», «Татарстанның математика фәнни мәктәбе: фәнни белешмәлек», «Россия Федерациясендә татарлар тупланып яшәгән урыннар: фәнни белешмәлек» (серия), «Татар теле: энциклопедия», «Казахстан татарлары: фәнни белешмәлек», «М.И.Мәхмүтов мирасы: персональ белешмәлек», «Муса Җәлил: персональ энциклопедия» һ.б. дәвам итә. Шулай ук Институт «Татар дөньясында ислам: электрон версия», «Татар иле: электрон энциклопедия» һәм башкаларны әзерләп дөньяга чыгаруны күздә тота. ■

ТР Милли музеенда сакланучы ошбу бик тә үзенчәлекле экспонат – Казан ханы Мөхәммәдәминнең сарай остасы Насыйр тарафыннан эшләнгән кувшин-чүлмәк. XV йөз ахырына-XVI йөз башына нисбәтле бакыр чүлмәк бик тә уникаль. Сарай шагыйре үзен «Насыйр – Әмин ханның фәкыйрь бакырчы остасы» дип таныштыра.

МИЛЛИ МУЗЕЙ ХӘЗИНӘЛӘРЕ

«Йөзеңне күрдем инде күзләрем белән,
Яннарыңда һич тә көтмәгәндә булачакмын,
Аның йөзен күрергә теләүче һәркемне
Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән.
Синең яхшылыгыңнан гасырлар буе сөенермен».

«Барлык кешеләрнең көчлесенә багышлап чокып яздым. Аның үзенә тартучан шат, ачык йөзе — азык, минем өчен (икмәктер)».

«И, Раббем! Синең (бөек) йортыңда, ягъни хан сараенда (яшәүче) тулы хокуклы гаскәр башлыгы, бәхетле Күбик иргә — оста Насыйрдан».

«Сугышлардан арыгач, син савытның авызын ачып, иренеңне тидереп, бөтен сусавыңны бас! Күбик ирне чын йөрәктән яратучы, аңа сәләмә, йон киемле дәрвиш (суфи) кебек чылбыр белән бәйләнгәндәй, (аны) көчле яратып, теләгенә (азатлыкка, тигезлеккә) ирешүче (омтылучы кеше) — мин эшләдем», — дигән шигъри юллар гарәп язуы белән гравёрланган.

Текстлар галим-археограф Әнвәр Хәйри укыган вариантта тәкъдим ителә.

***Руфия Мөхетдинова** әзерләде.*

ЯРТЫ ГАСЫР ЭЛЕК – ТАТАР МӘКТӘБЕ

4 февраль, 1966 ел.
Бауман урамындагы Матбугат йорты. Язучыларның проза секциясе. Утырышта, язучы халкыннан тыш, галимнәр белән журналистлар да катнаша (барлыгы 60 кеше).
Беркетмәне секция сәркатибе Мәдинә Маликова алып бара.
Секция җитәкчесе Атилла Расих утырышны ачып җибәрә:
– Безнең каршыбызда – Татарстан мәгариф министры иптәш Мирза Мәхмүтов. Аңа сүз бирәбез.

Мирза Мәхмүтов:

— Мин махсус әзерләнеп килмәдем *(министр шулай дисә дә, саннар-цифрлар белән дәлилләп чыгыш ясавына караганда, аның бирегә ныклап әзерләнеп килгәне күренә. — Л.Л.)*. Шулай да сезне кызыксындырган сорауларга җавап бирергә тырышырбыз. Мәктәпнең бурычы нәрсә? Элек белем бирү һәм коммунистик караш тәрбияләү дигән бурыч куелган иде. Хәзер бу бурычның берьяклы булуын күрдек. Хәзер бурыч: яшь буынга белем бирү, коммунистик караш тәрбияләү һәм фикер йөртү сәләте үстерү. Соңгысы булмаса — тәрбия үз максатына ирешә алмый. Элек без яшьләрне фикер йөртергә өйрәтмәгәнбез. Без бу бурычны куеп, үтәргә өйрәнеп йөрибез. Бу ансат эш түгел. Безнең педагогикада балаларның фикер йөртү сәләтен танып белү һәм үстерү буенча фәнни теориябез юк дәрәҗәсендә. Безнең үзебезгә практик эштә теориясен дә хасил итәргә туры килә. Берничә кеше Казаннан һәм Мәскәүдән шушы теория белән шөгыльләнә. Шулай итеп, бурыч: 1) коммунистик тәрбия, 2) ныклы белем, 3) мөстәкыйль фикер йөртү.

Бездә 3460 мәктәп, шул исәптән 27 интернат-мәктәп, 60лап махсус мәктәп бар. 70 мең бала балалар бакчасына йөри. 56 % мәктәпкәчә балалар дигән сүз. 618 мең укучы укый. Татарча 127 мең бала укый иде 1958 елда. Ул елны «Мәктәпләрне үзгәртеп кору» дигән закон *(1958 елның декабрендә СССР Югары Советының «Об укреплении связи школы с жизнью и о дальнейшем развитии системы народного образования СССР» дигән законы*

турында сүз бара. — Л.Л.) чыкты. Анда, 19 статьяда, балаларны нинди телдә укыту ата-ана теләгенә куелган. Мондый закон башка илләрдә элегрәк чыкты. Мин 1964 елда Тайландта булдым. Анда мин бу турыда белдем: мәсәлән, Һиндстан, Бирма, Әфганстан, Цейлон. Мондый закон тормыштагы объектив хәрәкәтнең чагылышы гына. Революциягә чаклы ук күп татарлар балаларын русча укыталар иде һәм соңга таба бигрәк тә Казанда мондый хәл күбәйде. Дөрес, башка өлкәләрдә, бигрәк тә татар мәктәпләрендә өлкән классларда русча укыталар. Ата-аналар күпчелек очракларда балаларын русча укытырга тели. Бу хәрәкәт 1960-1963 елларда көчәйде, хәзер бераз басылды. Ирек булгач — теләк бераз басылды. Шушы елларда татар мәктәпләренең бер өлеше русча укытуга күчте. Төрлесе булды: кайберсе өлкән классларда, 5 нче класстан яисә беренчедән үк. Кайбер мәктәпләрне, укытучылар җитмәгәнлектән, кире татарчага күчерергә туры килде. Әйткәннәргә карамастан, татар мәктәпләре шактый ныгыды, материаль базасы үсте. Казанда 1959 елда 4 урта, 8 җидееллык, 7 башлангыч мәктәп бар иде. Хәзер тагын бер татар интернаты эшли башлады. Яңа Бистәдәге мәктәп яңа дүрт катлы бинага күчте, барлык кабинетлар һәм җиһазлар бар. Без Академиядә милли мәктәпләр бүлегенең филиалын ачтык. Галимнәр тикшерү эшләре алып бара. 26 нчы урта мәктәпне алыйк. Биналары яхшы, заводта укучылар практика үтә. Директор — педагогия фәннәре кандидаты. 110 нчы мәктәп — Киров районындагы зур бинада, яхшы мәктәп. 80 нче мәктәпнең микрорайонынннан күп татарлар яңа районга күчеп китте. Хәзер биредә катнаш мәктәп.

Кичке мәктәпләр бар. 22 нче кичке мәктәптә татарча 720 кеше укый. Мәктәпләрне яңартканда читен мәсьәләгә юлыктык — кешеләрне сайлау. Мәктәпнең эше кешеләргә бәйләнгән. Яңаны аңлау кыен булды кайберәүләргә. Хәзер мәктәпләрдә директорлар югары белемле, тәҗрибәле. РОНОларда да шулай. Кадрлар яхшы хәзер. 4 ел элек Казанда махус интернат-мәктәп ачылды. 18 нче мәктәпне Жилплощадка тирәсенә күчердек тә, торак салып, интернат иттек. Аннары Ленин районында 960 урынлы яңа уку йорты салдык. Хәзер анда 612 бала татарча укый. Анда бик иркен. Аны татарлар өчен үрнәк үзәк итеп кормакчы булабыз. Анда 4 кабинет, 4 кинопроектор, радиоузел, телевизор, 4 магнитофон һ.б. бар. Программалаштырган укытуны башлыйбыз гына әле, бу дөньяда яңа нәрсә. Башка республикалардан килгән кешеләр безнең бу эш белән бик кызыксына. Без кешеләрдән артта калып бармыйбыз.

Авыл җирендә мәктәпләрне эреләндерергә тырыштык, шунлыктан мәктәпләрнең саны бераз кимеде. 3540 иде — 3460 булды. 127 мең (1958 нче елда) — былтыр 192 мең иде. Шушы 7-8 ел эчендә татарча укучы балаларның саны шактый артты. Татар мәктәбе ныгый, алга бара. Ел саен колхозлар исәбенә 150-160 мәктәп салына. Былтыр сафка баскан 147 мәктәпнең 34е — типовой, кирпечтән. Яртысы — татар мәктәбе. Кайбер елларда татар мәктәпләре күбрәк салына: Әлмәттә, Сарманда, Балтачта һ.б. Төзүчеләр җитми. Әлмәт районында, Тайсуганда 8 еллык мәктәп: таш бина, 16 класс бүлмәсе, кабинетлары, электростанциясе һ.б. Әтнә мәктәбен алыйк, урта мәктәп салынды. Татар теле һәм әдәбияты кабинеты да бар. Әтнә мәктәбендә былтыр 11 классны 69 кеше тәмамлап чыкты. 17 кеше ВУЗга, 3 кеше училищега кергән. Шәмәрдән мәктәбе. 3 сменалык мәктәп, русча укыйлар. Химия институтына керәләр. Кенәр татар интернат-мәктәбендә укыту эше бик яхшы оештырылган. Яңа Кәшердә — 330 кешелек бик яхшы интернат-мәктәп салдык. Азнакайда 500 кешелек интернат мәктәп бар. Апакайда 320 урынлы таш бина, укытучы-

Атилла Расих

Нәкый Исәнбәт

лар өчен 8 фатирлы 2 катлы йорт, 100 кешелек интернат салдык. 12 кабинет бар.

Республикада 32 мең укытучы, 1051е югары белемле. 14 меңе татар укытучылары. 2 меңе катнаш мәктәпләрдә, русча да укыталар.

Татар мәктәбендә русча укыту мәсьәләсе — бик авыр мәсьәлә. Безнең максат — бик әйбәт итеп рус телен өйрәтү. Соңгы өч елда татар мәктәпләреннән күп кенә кешеләр ВУЗларга керә. Азнакайда Ибраһимов дигән укытучы бар иде. Ул аерым балалар белән дәрестән соң да калып эшли иде. Ул укыткан бер бала математика олимпиадасында җиңеп чыкты һәм Мәскәү дәүләт университетына керде. Балалар арасыннан сәләтлеләрен сайлап алырга тырышабыз. Шулай ук укытучыларны да, директорларны да үстерергә тырышабыз.

Кайбер иптәшләр татар теле һәм әдәбиятына дәресләр кими дип үпкәлиләр. Әмма положение үзгәрә тора. Унберьеллык мәктәпне унъеллык итәбез. Гомер үтә — белем арта, ә уку срогы бер үк.

Татар теле һәм әдәбияты
1-4 классларда 5-8дә 9-11дә
1958 елда 35-30 16 4
Хәзер 30-26 16 5

Эш сәгатьтә дә түгел бит. Соңгы елларда татар теле һәм әдәбияты буенча яңа дәреслекләр эшләргә туры килде. Былтыр, ниһаять, «Әлифба» чыкты. Яхшы булды ул. Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләренең сыйфаты яхшы түгел. Галимнәребез, язучыларыбыз моның белән бик кызыксынмый ахры. Дәреслек начар булгач, матур дәрес биреп булмый. Дәреслекнең әһәмияте зур.

Сораулар:

Халитов (Гали?):

— Татарстаннан тыш булган татар мәктәпләренең хәле, аларга мөнәсәбәт, алар белән бәйләнеш ничек?

Ибраһим Нуруллин:

— Рус телендә укытуга күчү татар мәктәпләренең нинди нәтиҗәгә…

Фатих Хөсни:

— Укыту ата-аналарның ихтыярына карый һәм шуның белән үлчәнә дигән закон стихийностька юл куймый-

Зәки Нури

Фатих Хөсни

мы һәм бу закон яңадан карауны сорамыймы?

Укытучыларның үзләрен мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтәсезме?

Госман Бакиров:

— Якын елларда башлангыч мәктәп 3 еллык була диләр? Ни өчен?

Галимҗан Латыйп:

— Рус мәктәпләрендә татар балалары өчен аерым дәрес кертелә. Әмма анда теләгән бала гына укый, ирекле куела бу. Ни өчен бу ирекле куелган?

Зәки Нури:

— Татар телен укыргамы-юкмы дигәндә, бала ихтыярына куела, ә нинди телдә укыту ата-ана ихтыярында?

Мәхмүт Бөдәйли:

— Татар һәм рус мәктәпләрен бетергән кешеләрнең ВУЗларга керү мөмкинлекләре ничек?

Нәкый Исәнбәт:

— Ни өчен бер мәктәптән химик ВУЗларга, икенчедән ветинститутка керәләр?

Атилла Расих:

— Татар теленә һәм әдәбиятына мәхәббәт ничек тәрбияләнә?

Җавап:

Мирза Мәхмүтов:

— Читтәге татар мәктәпләренең бер өлеше, урта мәктәпләрнең күбесе русча укуга күчкән. Читтә 300 меңнән артыграк бала татарча укый. 100 меңнән артыгы — Башкортстанда. Без конференциягә аларны чакырдык, алар да чакырганнар. Әмма планда татар мәктәпләре телгә алынмаган. Башкортстанда башкорт мәктәпләреннән татарныкы күбрәк. Ел саен ике-өч төркем читтән килгән татар укытучыларын курсларда укытабыз.

Укытучыларны мөстәкыйль фикер йөртүгә бик күп өйрәтәбез, әмма аз тикшерәбез ахры. 7-8 бригада озакламый чыгып тикшерәбез. Конференциядә мең дәрес күрсәттек. Мәктәпләрнең барысын да күтәрергә тырышабыз. 320 терәк мәктәп бар. 99нчы мәктәптә фәнни эксперимент алып барабыз. Казанда — 30 терәк мәктәп. Бездә укытучыларның белемен күтәрү институты бар. Анда ел саен җәй көне 6 мең укытучы укый.

Милли мәктәпләр филиалы бар бездә. Бездә русча укытуга күчкән

мәктәпләрнең хәле тикшерелә, өйрәнелә. Ярдәм кирәгенә ярдәм итәбез.

ВУЗларга керү мәсьәләсе белән шөгыльләнүче юк. Данныйлар ел саен җыела, чаралары мәктәптә күрелә. Биредә тагын балаларны мөстәкыйль фикер йөртүгә өйрәтү дигән мәсьәлә килеп баса. Методикабызның, укыту системабызның гаебе бар, кимчелеге бар: мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтмибез. Моны үзгәртү җиңел түгел. Проблемалы укыту да каршылыкка очрый. ВУЗга керү мәсьәләсе — катлаулы мәсьәлә.

Күпчелек теленнән файдалану, ул телгә күчү — объектив закончалык. В.И.Ленинның бу турыда сүзләре бар: *«Экономик мөнәсәбәтләр күпчелек теленә күчәргә мәҗбүр итәчәкләр»*. Мисал: Әлмәт, Бөгелмә. Бу башка республикаларда да шулай. Һиндстанны алыйк. Без хинди-урду әлифбасын Неруга бүләк иттек. Ул дулкынланды. Анда 70 милләт яши, уртак тел — инглиз теле. Бенгалиядә мәктәптә атнасына 1,5 сәгать милли чикләнгәнлек сизелә. Аралашу чарасы булырга тиеш.

Фатих Хөсни:

— Үз телләрен онытмасыннар иде.

М.Мәхмүтов:

— 19 статья ул дөрес. Аны тормышка ашыру — икенче мәсьәлә. Без бик сак булырга тиеш. Беренче чиратта коммунистик караш тәрбияләү, белем бирү, фикер йөртүгә өйрәтү.

Кешелек дөньясының белеме арта, уку срогы кала. 1-4 классларда материал хәзерге заман баласы өчен җиңел. Методиканы үзгәртсәк, элекке 4 еллык материалны 3 елда биреп була. Ләкин милли мәктәп мәсьәләсе бар. Бәлки, кайбер мәктәпләрдә әзерләү группалары ачарбыз.

Татар балалары татарча белергә тиеш. 60-61дә рус мәктәбендә татарча укыту юк иде. Без ул планны үзебез уйлап чыгардык. Татар телен укыту шул ук 19 нчы статья нигезендә — ата-ана ирегендә. Бала ирегендә — түгәрәкләргә йөрү. Быел 10 мең бала рус телендәге мәктәптә татар теле укыйлар. Кайбер рус балалары да укыйлар. Татар телен өйрәнү өчен русча дәреслек юк, сүзлек юк. Рус мәктәбендә татарча укыту башланып китте.

Татар мәктәпләреннән укып чыккан балаларның ВУЗга керү проценты кимрәк. Рус теле тота. Кайбер укытучылар татарча да керү имтиханы кабул итәләр. 61 елда 27% ВУЗда татар студентлары, хәзер 33% татар студенты.

Татар теленә мәхәббәт мәсьәләсе. Һәр укытучы үз фәнен яраттырырга тырыша. «И туган тел, и матур тел», — дип Тукай гына язды бит. Кайсыгыз татар теленең матурлыгын ачып салды? Нинди укытучы образы тудырдыгыз? Мәктәпне күрсәткәнегез бармы? Сез безгә ул азыкны әледән-әле биреп тормасагыз, без элек язганнар белән генә канәгатьләнеп калачакбыз. Ә хәзерге тормыш кая? Балалар бакчасына алырлык китаплар аз. Күбрәк языгыз. Без рус балаларын татар халкының тарихы белән таныштыруны мәҗбүри итеп куйдык. Ләкин безгә материал кирәк. Әйтик, русча укыйлар, ди мәктәптә. Татар теле фән булып кала. Халык турында русча язучы бармы? Юк. Дөрес, язучылар мәктәпкә йөриләр. Ләкин азык та бирегез. Без Газинурны беләбез. Ә кая безнең тарихи романнарыбыз? Юк бит. Алар бик кирәк әйбер. Ә татар телендә фантастик әсәрләр? Юк. Безгә бергә эшләргә кирәк. Зелёный Долда яшьләрнең математик мәктәбе бар. Ә татар теле мәктәбе юк, татар әдәбияты мәктәбе юк. Әллә соң профессорлар юкмы? Сездән бик зур ярдәм сорыйбыз. Дәүләт бик күп акча бирә, яңа мәктәпләр ачабыз, техниканы бирәбез. Кешеләр белән эшләргә кирәк — галимнәрнең, язучыларның, интеллигенциянең ярдәме кирәк. «Казан утлары» журналында укучылар, укытучылар өчен нигә бер бүлек ачмаска? Укучыларыбыз бар, халык укый. Татар халкы татарча күп укый. Әдәбият аз, җитми.

Ибраһим Нуруллин

Мәктәпләр өчен сәхнә әсәрләре юк. Сезнең ярдәмегез бик кирәк. Сез бу мәсьәләне җыелышыгызда аерым тикшерсәгез иде. Татар мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятыннан имтихан бар, рус мәктәбендә — юк. Болай да перегрузка бик зур.

19 статья — бөтенсоюз законы.

Дербышкида яңа мәктәп салына. Элекке рус мәктәбен татарларга бирәбез.

Сорау:

— Татар әдәбиятыннан уку фильмнары чыгамы?

М.Мәхмүтов:

— Хәзергә бездә телевизион дәресләр бирелә. Фильм эшләү безнең кулдан килми әле. Татар әдәбиятыннан да телевизор буенча йомгаклау дәресе үткәрергә кирәк. Былтыр мең ярым пластинка эшләтеп җибәрдек. Анда татар музыкасы язылган.

Сорау:

— Орфографияне эзгә салу буенча чаралар күреләме?

М.Мәхмүтов:

— Без бу мәсьәләне мәктәптә тикшерәбез.

Зәки Нури:

— 1. Класстан тыш уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләрне туплап, китап итеп чыгару. 2. Язучыларның биографиясен, портретларын җыйган китап чыгарырга, яисә аерым фотолар итеп таратырга. 3. Язучыларның магнитофонга язылган сүзләре. Моны да үзәкләштереп эшләп бирәсе иде. 4. Мәктәп китапханәләрен китап белән тутыруга контроль кирәк. Мәктәпләрдә йөргәндә бу мәсьәләләр белән бик еш очрашабыз.

М.Мәхмүтов:

— Бибколлекторлар мәсьәләсе авыр. Бу мәсьәләләр белән бик күптән шөгыльләнәбез.

И.Нуруллин:

— Татар әдәбияты дәреслеген төзүгә язучыларны да катнаштырырга кирәк.

А.Расих иптәш Мирза Мәхмүтовка рәхмәт әйтә. Теләкләрне һәм тәкъдимнәрне министрлыкка язма рәвештә бирергә карар кылынды.

Секретарь: М.Маликова

Беркетмәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

РЕДАКЦИЯ ИСКӘРМӘСЕ:

«Бүген республикабызда 853 татар мәктәбе, 96 чуваш мәктәбе, 34 удмурт мәктәбе, 18 мари мәктәбе, 4 мордва мәктәбе бар, 1 мәктәптә башкорт теле, 1 мәктәптә иврит теле өйрәнелә. Моннан тыш 30 якшәмбе мәктәбендә 28 тел өйрәнелә».

ТР Премьер-министры урынбасары, мәгариф һәм фән министры **Энгель Фәттаховның** «Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Илфак Ибраһимов** белән әңгәмәсеннән. («КУ». — 2014. — №8).

БӘЯЛӘНМӘГӘН ТАЛАНТ

Марс Макаров

«Ак каеннар, ак каеннар
Тибри җилләрдә
Сагынабыз сине, дускай,
Моңсу күзләрдә».

1955 елда Казанның 26 нчы татар мәктәбендә укыган чагымда инде шактый танылган, күп кенә популяр җырларның авторы булырга өлгергән Ифрат абый Хисамов белән беренче очрашулар, танышулар һәм киләчәктә дә даими аралашулар гел сагындырып искә төшә. Исән вакытында, ни кызганыч, якын кешең турында еш уйламыйсын. Кеше үлеме, гомумән, вакыт тарафыннан таушалган хәтерне яңарта...

Ифрат абыйның безнең арадан китүенә дә инде ундүрт ел тулып килә икән. Кинәт кенә минем күңелемдә онытыла да башлаган, аның белән бәйләнешле, инде яшьлек офыгында калган хатирәләр калкып чыкты, үткән тормышының сират күпере янә хәрәкәткә килде сыман…

Алдымда чиста бит хәзерләнгән. Уйланам… Күптөрле һөнәр белгән үзенчәлекле кеше иде бит ул!

Якын дустым турында нәрсә язарга, нидән башларга?.. Башымда хатирәләр кайный… Якыннан белмәгән кешеләргә Аны ничек сурәтләргә? Мәктәп елларында, бала чакта беренче күрүдән, беренче танышудан башларга кирәктер, бәлки?!

…Авыр тормыш еллары иде. Класста утырабыз. Инде соңгы дәрес бетеп килә. Кинәт, дәресне бүлеп, кызыл галстук таккан, пөхтә киенгән, урта яшьләрдәге бер абый белән класс җитәкчесе Тәгъзимә Һадиевна килеп керде. Килеп керүгә үк:

– Игътибар, сезнең өчен белдерү бар. Безнең мәктәптә хор оештырыла. Таныш булыгыз, бу абыегыз – «Ак каеннар» җырын язган композитор Ифрат Хисамов. Ул сезнең хор җитәкчегез булачак. Атнасына ике тапкыр хорга йөрерсез! Әгәр йөрмәсәгез, бернинди хор да чыкмас, хур гына булырбыз, – диде.

Шуннан соң сүзне композитор абый алды. Саф татарча, мөгаллимнәрчә сөйләм, бәрхет тавыш, Атлантида кешеләренеке сыман затлы гәүдә, җитди йөз, киң учлар, гадәттән тыш озын бармаклар, аягында дәү туфли – 45 нче размер тирәсе бардыр, валлаһи! Озын бармак дигәннән, озын бармаклар белән баянда уйнавы бик җайсыз. Әле дә исемдә: Ифрат абый гомере буе озын бармаклары белән баянда тиешенчә уйный алмыйча интегә иде, ә фортепианода октавадан тыш, хәтта тагын өч тонны да арттырып ала иде. Бер пианист та андыйны булдыра алмаганы бөтен музыкантларга

да мәгълүм. Без шакката идек шуңа. Хәер, уйларым алга йөгерде бугай…

Бу тайпылу киләчәктә булган эпизодка карый. Әле генә язган, композиторга караган сурәтләүләр ул кадәр әһәмияткә дә ия түгелдер, бәлкем. Иң мөһиме – ул халкына мирас итеп үзенең җыр җәүһәрләрен – сабан туйларында, җыеннарда, туй мәҗлесләрендә җырлар өчен берсеннән-берсе күркәм лирик, мәзәк вә шаян җырлар иҗат итеп калдырды.

Җыр-музыкага мөнәсәбәте әллә ни уңай булмаган берәр татар кешесеннән: «Кем ул Ифрат Хисамов?» – дип сорасаң, бәлки, ул аны белмәс тә иде, әмма дә «Утыр әле яннарыма» дигән җырын җырлап күрсәтә алыр иде, мөгаен. Аның колакка тиз кереп, күңелгә тиз сеңә торган гади генә сүзләргә корылган үзенчәлекле мелодикасының профессионал композиторлар әсәре дәрәҗәсендә булуын вакыт-хөкемдар үзе исбат итте. Ифрат Хисамовның ярты гасырдан артык элек язылган җырлары — әле дә профессионал җырчыларыбызның репертуарында. Нидә хикмәт? Ни өчен балачактан бирле һәркемгә таныш булган «Әпипә» көен көйли белмәгән, «Туган тел» җырын җырлый белмәгән татар юк?! Минем уйлавымча, бөтен хикмәт — көй авазларының логик төзелешендә. Күңелләрдә онытылмыйча озак яши торган барлык көйләр дә хис белән сугарылып, математик төгәллек илә халык тарафыннан иҗат ителгән ләбаса!

Фикерне бәйләп, шуны әйтәсем килә: Ифрат Хисамовның көй-мелодияләрендә дә хис белән логик төгәллекнең гармониясе, ягъни тәңгәлләшүе ачык сизелә. Аның җыр иҗатында гади формаларны куллануы үзен аклый. «Гадилектә – даһилек», диләр ләбаса. Әйтик, иң уңайлы эш коралы саналган чүкечнең төзелеше дә бик гади бит, күпме генә тырышсаң да, аны әллә ни камилләштереп булмый. Менә шундый җырлар иҗат итеп калдырды арабыздан бик иртә киткән Ифрат абыебыз.

Әле дә хәтердә, 50 нче елларда аның Мәхмүт Хөсәен сүзләренә язган «Ак каеннар» дигән лирик җыры (Ифратның тәүге җыры булса кирәк) шулкадәр популярлашып китте ки, кая барсаң да шуны җырлыйлар иде: мәҗлестә дә, сәхнәдә дә. Кызганыч ки, хәзерге вакытта ул җырга реклама җитмиме, әллә җырчыларыбыз элеккеге җыр хәзинәләренә битарафмы? Ул җанга ятышлы җыр хәзерге вактөяк җыр-мырулар өемендә күмелеп калса да, элеккеге буын кешеләренең күнелендә онытылмаслык бер яшьлек ядкяре булып яши әле!

Ул елларда Ифрат Хисамов түрәләргә оппозицион кеше булса да, аның иҗатында совет тәрбиясенең рухы нык чагылды. 50-60 нчы елларда иҗат иткән бар җырлары да диярлек шул заманның ихтыяҗына туры килә иде. Әйтик, «Хөршидә-Мөршидә» (Г.Зәйнашева сүзләре), «Шалт, Мөхәммәтҗан» (Ш.Галиев), «Үти-үти үрдәкләрем» (Н.Арслан), «Ромашка» (М.Харисов) социализм чорына бик яраклы җырлар булып, радио аша даими тапшырылып тордылар. Шунысы кызганыч, ул елларда Ифрат Хисамов бик актив эшләүче заман композиторы булып саналса да, нигәдер аны әгъза итеп Композиторлар берлегенә алмадылар. Аңлавымча, Ифрат Хисамовның гади генә формаларда җырлар язып уңышка ирешүе һәм халык арасында популярлык казануы үзләрен югары профессионал дип санаган кайбер кешеләрнең эчен пошыра иде булса кирәк. «Указлы» композиторлар гомер буе халыкчан җыр язучы һәвәскәр авторларны күралмадылар. Аларның җырлары профессиональ дәрәҗәдә түгел, имеш, сәнгати кыйммәте юк, янәсе. Әйе, барысы да Ключарёв, Яхин кебек объектив карашлы, гадел була алмады шул. Казан консерваториясе ректорының Ифрат Хисамовны ниндидер бер гомуми фәннән имтихан бирә алмаганы өчен консерваториядән чыгаруы

Беръюлы ике курайда уйнау – бик сирәк күренеш. 90 нчы еллар

да шуны күрсәтә. Нәҗип Җиһановка Хисамовның үзенчәлекле таланты түгел, ә аның имтихан тотканда алган белгесе мөһим булып чыга. Югыйсә, Ифрат Хисамов инде эре формаларда да үзен күрсәтә башлаган иде. Консерваториягә кергәнче үк инде ул дүрт кисәкле «Симфония, флейта һәм оркестр өчен концерт» дип аталган күләмле әсәр авторы иде. Зур талант иясенә карата кылынган бу гаделсезлек милли музыка тарихында бер кара тап калдырды...

Ифрат Хисамовның җыр иҗаты чәчәк аткан чорда Татарстан композиторлар берлегенең рәисе Мирсәет Яруллин иде. Яшерен-батырын түгел, аны рәис итеп сайлауда Нәҗип Җиһанов хәлиткеч роль уйнады. Җиһанов урынында рәис булып эшли башлаган Мирсәет, кеше буларак та, композитор буларак та Ифратны никадәр ихтирам итсә дә, аны берлеккә алырга кыймады, аннары Мәскәүнең әгъзалыкка алу кагыйдәсе дә комачаулады, әлбәттә. Белгәнебезчә, Композиторлар берлегенә югары махсус белеме булган иҗатчыларны гына әгъзалыкка алалар иде ул чакта. Кызганыч ки, әле хәзер дә шул кагыйдәгә буйсыналар.

Ифрат Хисамовның музыкаль иҗаты башкалардан ни белән аерыла соң?

Ул җырларын хәзерге күп кенә

Татарстан радиосында тавыш режиссёры булып эшләгән чагы. Сулда – яшьләр өчен тапшырулар мөхәррире Флүс Латыйфи. 70 нче еллар

авторлар кебек, көндәлеккә чамалап түгел, ә вакыт-хөкемдар иләгенең кырыс булганын яхшы аңлап, киләчәккә күз атып язды. Тормышка яраклы актуаль текстлар сайлый белде. Шуңа күрә дә ул Нури Арсланов, Шәүкәт Галиев, Мәхмүт Хөсәен кебек заман шагыйрьләре белән һәрчак элемтәдә торды.

Тормышка яраклы текстлар дигәннән, кем бәрәңгегә багышлап җыр чыгарырга җөрьәт итте соң әле? Мәңге «картаймас» бәрәңге турында җыр кирәк иде халыкка ул заманда! Бәрәңгене әрчегәндә дә, ашаганда да һаман Ифрат абый искә төшә.

Аның бик күп еллар элек язылган «Бәрәңге» дип аталган җыры белән бәйләнешле бер кызыклы вакыйга-

ны искә алып, үзалдыма көлеп куям. Ифрат абый берәр уңышлы җыр язса, ихлас күңеле белән куана иде, ләкин бервакытта да мактанмый иде. Ничек итеп без Казан музыка училищесында укыган чакта, курсташым баянчы Насыйх Вилданов белән әле яңа гына табадан төшкән «Бәрәңге» җырын беренче тыңлаучылар һәм дә ул җырга беренче бәя бирүчеләр булдык – хәзер сүзем әнә шул хакта.

Башта ук шуны искәртим: без музыка училищесында укыган елларда (60 нчы еллар башы) Ифрат абый бездән күпкә олы булса да, училищеның карт студенты булып, композиция классында белем алып йөри иде.

...Бервакыт Насыйх белән икенче кат баскычыннан төшеп килгәндә, Ифрат абый безне туктатты да, куанычлы аваз белән: «Егетләр, уемда әле генә бер яңа җыр кисәген әмәлләдем. Озак газаплады ул мине, әмма ерып чыктым бит мин аны барыбер! Кая, берәр баян табыгыз әле, көем башымнан киткәнче сезгә җырлап күрсәтим», – ди. «Нинди җыр соң ул Ифрат абый?!», – дибез. «Бәрәңге» дип атала», – ди. Шаяртып әйттеме бу, дип, без сәерсенеп калдык. Шулчак исә мин, кыюланып: «Ифрат абый, нишләп җырыгызны бәрәңгегә багышладыгыз, суганга багышларга иде. Суган — елата торган яшелчә бит» – дип төрттереп алдым. Ул, моңа кадәр булган халәтеннән бераз суына төшеп: «Их, егетләр, сез ачлыкны күрмәгән яшьләр шул. Бәрәңгене олыларга, аңа мәдхия җырларга кирәк, ул — бар яшелчәләрнең дә патшасы бит», – диде. Яңа җырны «тикшерү» өчен буш класс табылмады: кайсы скрипка чината, кайсы тромбон гүләтә. Яңа җырны училище каршысында гына торган Насыйх квартирасында тыңларга булдык. Сизенәбез – абыебызның кәефе шәп. «Яңа җырны юмыйча булмый, егетләр, мин тиз генә кибеткә кереп чыгыйм әле», – ди. Ул шәраб алып килеп җитүгә, ниһаять, яңа җырны тыңларга керештек. Ифрат абый Насыйхның баянын алды да, бераз уйланып, иреннәрен кыймылдатып торганнан соң: «Йомры гәүдәле, йодрык кадәрле, их тәмле, бигрәк тәмле бәрәңге», – дигән сүзләр кушымтасы белән җырлап та җибәрде.

Ул вакытта нindidер каршылык булдымы, әллә ул җыр үзенең башкаручысын таба алмадымы, әллә инде автор тыйнаклык саклап, бер җырчыга да ул җырны тәкъдим итмәдеме, мин ул җырны берничә елдан соң гына Сөләйман Йосыпов башкаруында радиодан ишеттем.

Ифрат Хисамовның бик күптән иҗат иткән җырларының хәзерге көнгәчә искермәвенең хикмәте, актуальлеге — авторның бу фани дөньяда оптимист булуында һәм көйдән-көйгә, җырдан-җырга яңалык таба белүендә, үз-үзен һәм башка авторларны кабатламауда, беркемнекенә дә охшамаган иҗади үзенчәлегендә, дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Мин 60 нчы еллар башында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшләгән дәвердә генә дә Ифрат Хисамовның хорга кушылып җырлау өчен язган «Умартачы сөйгәнем» дигән шаян җыры Советлар Союзы шәһәрләрендә 500 мәртәбә башкарылып, ансамбльнең «коронный» номерына әйләнде. Хор, гомумән, Ифратның стихиясе иде. Хәрби хезмәттән соң ул Балтач районының мәдәният йортында үзешчән хор сәнгатендә, беренчеләрдән булып, күптавышлы академик хор оештырды. Соңрак, бер үк вакытта, Татарстан халык иҗаты йортында да эшләп, Актаныш, Норлат, Сарман, Мөслим, Әгерҗе районнарына барып, хорлар, җыр һәм бию ансамбльләре оештырды.

Гомеренең соңгы елларында ул уен кораллары ясау белән генә мәшгуль иде. «Татарстанны курайчылар иле итәм әле мин», – дип бертуктаусыз янып эшләде. Аның исеме курай исеменнән аерылгысыз. Республикабызның кайсы гына төбәгендә, нинди генә фести-

Беренче рәттә, уңнан өченче – Ифрат Хисамов. Һәвәскәр композиторлар берләшмәсенең I корылтаеннан соң. Казан. 1990 елның ноябре

валь-конкурслар, бәйрәм концертлары уздырылмасын, курай, кубызчылар, сорнайда уйнаучылар чыгыш ясамый калмый. Бу милли уен коралларының биниһаясен Ифрат Хисамов үз кул көче белән эшләде. Ул чын мәгънәсендә алтын куллы кеше иде. Белмәгән һөнәре юк иде аның.

Югары даирәләр, гәрчә аның фидакяр хезмәтен күрмәмешкә салышсалар да, ул гомере буе курай моңын сөйгән милләттәшләренең һәм күпсанлы шәкетләренең ихтирамын тоеп яшәде. Исән вакытында анын турында киносюжетлар да төшерелмәде, иҗат бенефислары да оештырылмады. Матди ярдәм булмаганлыктан, 70 яшьлек юбилеен да уздыра алмады. Гаеп Ифратның ифрат тыйнаклыгында гына микән?!

Хәсән Туфанның бер җыр текстында күпкырлы мәгънәгә ия шундый сүзләр бар:

Сөйсәң, сөй син миннән яхшыракны.
Ләкин сөймә миннән түбәнне!

Әйе… Ифрат Хисамовтан түбәннәрне сөйделәр дә, күккә дә чөйделәр. Исеме инде әллә кайчан халык теленә кергән милли композиторыбызга иҗат берлегендә дә урын табылмады, «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем дә тәтемәде.

Берьюлы композитор да, хормейстер да, инженер, радиотехник, фотограф та, сәгать төзәтүче, унлаган музыка уен коралында уйный белгән һөнәрмәнд музыкант та, күптөрле халык музыка уен коралларын ясаучы үзенчәлекле һөнәр иясенең арабыздан вакытсыз киткәненә дә менә инде 14 ел булып килә. Әгәр исән булса, быел аңа 14 ноябрьдә 84 яшь тулыр иде. Бу уңайдан, Ифрат Хисамовның күпсанлы шәкертләрен генә түгел, республикабызның мин белгән музыка сөючеләрен дә менә нәрсә борчый: мәрхүм композиторны искә алу кичәсе оештырылачакмы, аның олуг иҗади мирасын барлап, күркәм бер милли кичә уздыру өчен матди ярдәм бүленәчәкме?

Республикабызның Мәдәният министрлыгы бу мәсьәләне уңай хәл итәр, дигән ышанычта калам. ■

ТЕЛ ЯЗМЫШЫ – МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

Миргазиян Юныс
(1927-2014)

Туган телне саклау бүгенге көндә кешелек экологиясен саклау дәрәҗәсендә тора. Тел — кеше рухының формасы, эчтәлеге һәм аның яшәү шарты. Тел — рухи экология. Туган телдә — мең еллар буена гореф-гадәтләр хәзинәсенең сөземтәсе, әдәп һәм әхлак кануннары, мең еллар туктаусыз язылып торган тарихның хакыйкый эчтәлеге. Тел тудырган топонимнар аша ата-бабаларыбыз моннан мең ел элек яшәгән җирләрнең табигатен, хәтта географиясен реконструкцияләп өйрәнергә була. Иван Грозный чорында һәм аннан соңгы гасырлардагы катаклизмнар иң чыдам, иң түзем генотип вәкилләрен генә исән калдырган. Минем милләтем менә шундый шартларда барлыкка килгән һәм аның ыруглардан милләткә әверелү юлы туган телебездә сурәтләнеп калган. Бүгенге көндә без шул телне югалту куркынычы алдына килеп басканбыз.

Тел югалту фаҗигасенең нәрсә икәнлеген аңламаган кешеләр, бу нигә безне куркытырга тели, без бит бөтенләй телсез калмыйбыз, киресенчә, Советлар Союзының теләсә нинди төбәгендә теләсә кем аңлый торган җиңел һәм кулай тел вәкилләренә әйләнеп киләбез, дип юанулары мөмкин. Без, татарлар, урысчага кайда һәм нинди шартларда өйрәнәбез? Уку йортларында, шәһәр тормышында, армия хезмәтендә, партия һәм администрация эшендә, урыс гаиләсендә туып, урысның бишек җырларын, әкиятләрен тыңлап, урыс халык иҗаты тәэсирендә үскәннәрнең теле бөтенләй үзгә. Ул — чын халык теле. Толстой, Достоевский, Чехов, Андрей Платонов теле — халык теленең байлыгын туплаган әдәби сөйләм безнең арабызда бөтенләй очрамый диярлек. Без үзләштергән тел — административ-бюрократлар теле, культ чорында безне камчылап эшләткән, торгынлык чорында ялганларга, урлашырга, аракы эчәргә, зина кылып йөрергә өйрәткән тел. Бу телдә рухны җанландырып торган шифалы көч, хисләр сизгерлеген сакларлык моңлы яңгыраш һәм әхлакны бөтенләйтүче ашламалар бармы соң? Административ-бюрократлар телендә каян булсын ди?! Шушы хәлне аңласаң, соңгы елларда кеше үтерү, йорт басу, гаилә таркалу статистикасының кинәт үсеп китүенә төшенү бер дә катлаулы эш түгел.

Японнарның электроника, машиналар ясау, фән, техника буенча беренче урынга күтәрелүләре турында сөйләп торасы юктыр. Хикмәт нәрсәдә? Японнар телне саклау буенча башка

Телне саклау, аның байлыгын халыкка җиткерү өчен тотылган акча Япония дәүләтенең бюджетында икенче урында тора.

халыклар арасында беренче урында тора. Ярлыландырылган телгә яңалык кертүе кыен икән ул, японнарга исә һәр яңалык үзеннән-үзе агылып тора. Чөнки искелек исән…

Телне саклау, аның байлыгын халыкка җиткерү өчен тотылган акча Япония дәүләтенең бюджетында икенче урында тора. Кешене хезмәт сөяргә, һөнәргә, эшне җиренә җиткереп башкарырга өйрәтү туган телдә төрле әйтемнәр, табышмаклар рәвешендә яши. Аларның тәэсире махсус кулланмалар, инструкцияләр белән чагыштырганда, көчлерәк тә икән. Туган телдә кешене тәртипкә, җыйнаклылыкка, тугрылыкка өйрәтү кануннары да яшәп килә. Бүгенге һәм борынгы катламнарны эченә сыйдырган киң диапозонлы бай телне өйрәнү процессы үзе дә зур белем икән һәм туган телне үзләштерү вакытында кешенең фикер йөртү сәләте көчәя, эрудициясе киңәя һәм теләсә нинди фәнне тирәнтен аңлау мөмкинлеге ачыла икән. Японнар шушы хакыйкатькә башкалардан алда төшенгән, телне кадерләп саклауга, аны баетуга киткән чыгымның керем булып кире әйләнеп кайтуын аңлаган. Япониядә ясалган әйберләрнең сыйфаты, эстетик камиллеге безне хәйран калдыра. Шулай сокланып карап торганда, без Япониянең техника һәм җитештерү буенча беренче урынга чыгуына туган тел ярдәм итүен күз алдына да китерә алмыйбыз, чөнки безгә бу турыда аңлатканнары юк.

***

Казан каласы 1552 елның 2 октябрендә басып алына. Башкалабызның урамнарында кан елга булып ага. Бу вәхшәтне онытырга хакыбыз юк безнең. Иван Грозный вандалларының иң беренче эше шуннан гыйбарәт: татарларның байлыкларын талау белән бергә, ничә гасырлар тупланып килгән елъязмаларны, архивларны яндыру коточкыч вәхшилек белән башкарыла. Казан ханлыгындагы 403 мәчет белән 483 мәдрәсә көлгә әйләндерелә. Татар аристократиясенең күбесе Иван Грозный ягына күчә. Татар теленең зур бер өлеше юкка чыгуны аңлатып тору кирәк түгелдер, дип уйлыйм. Йөз егерме биш елга сузылган азатлык көрәшендә татар халкының өчтән бер өлеше үтерелә. Калганнары төрле якка тарала. Бу хәл, билгеле, туган телгә тәэсир итми калмый. Бөек урыс тарихчысы Михаил Худяковның фәнни эшләре белән таныш кеше белә: Иван Грозный Казанны алырга юнәлгән чакта татарлар сан ягыннан урыслар белән тигез була. Ул чорда, билгеле, халык санын исәпкә алу булмаган. Тарихчыларның кайберләре, бу ике халыкның саны ун миллион чамасы булган, дип әйтә, икенчеләре алты миллион белән чикләнә. Эш анда түгел. Бүгенге көндә без һаман шул чама исәпләнәбез. Казан ханлыгын җимерүче халыкның саны исә бүгенге

Йөз егерме биш елга сузылган азатлык көрәшендә татар халкының өчтән бер өлеше үтерелә.

көндә йөз кырык миллионга җитеп килә. Территория өчен башланган көрәш тел өлкәсенә дә күчми калмый. Шуларның кайсы җиңеп чыгарга тиеш? Әлегә көч һәм перспектива — урыс теле ягында. Ләкин «тимер пәрдә»не алып ташлап, ирекле сәүдә башланганнан соң урыс теленең дә дәрәҗәсе югала, кимсетелү аңа да бәрә башлады. Бәлки, киләсе буыннар Пушкин теленең Тукай теле язмышына дучар булуын күрер? Кем белә…

Берничә гасырга сузылган чукынды-

ру процессы, татарларның җирләрен килмешәк алпавытларга, патша кушташнарына кисеп биреп, халыкны туган җиреннән куу да телнең үсүенә, ныгуына ярдәм итми, билгеле. Тик шушындый чаралар да хәтта татар телен җиңә алмый. Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Дин! Дин халыкны эчтән, рухи яктан, шәхеснең әхлагы, җаны аша берләштерә, шул диндәге рухи егәрлек безне башка халыкларга тоташтыра. Кыскасы, унтугызынчы гасырның азагында, егерменче гасырның башында җанланып киткән татар ренессансына кадәр халыкның иҗатын, телен, гореф-гадәтләрен, милли горурлык хисен дин саклап торган.

***

Безнең туган телебезне юкка чыгаруда нинди көчләрнең роль уйнавын да күрсәтү кирәк кебек. Минемчә, менә болар:

— мөстәкыйльлекне югалткандагы катаклизмнар, җимергеч борылышлар;

— ялган, ясалма, кара тарих; хаким милләт каршында тез чүгү, куштанлану;

— Сталинның милли сәясәте аркасында өченче сортлы милләткә әйләнеп, милли хокукны югалту; урыс теленә, суга батканда саламга тотынгандай ябышып, геноцидтан шушы юл белән котыла алырбыз дип ышану;

— туган җиребезгә туктаусыз китерелеп торган миграция яулары һәм, шуңа параллель төстә, төп халыкны читкә җибәрү хәрәкәте;

— табигатьне һәм телне катастрофага китереп җиткергән экология кризисы;

— идарә эшенә үзенең туган теленә дошман кешеләрне сайлап утыртуларның яман нәтиҗәсен дә онытырга ярамый. Бу процесс 1938 елны Сталин һәм Молотов имзасы белән Советлар Союзында яшәүчеләргә урыс телен белү мәҗбүри дигән карар чыкканнан соң башланды. Ул карар үзгәртелмәгән, яши, «эше» дәвам итә;

— татар теле өчен кара кайгылы, канлы еллар — Сталин диктатурасы еллары. Ул чорда «милләтче» яисә «халык дошманы» исемен алу өчен туган телгә тугрылык та җитә иде. Татарларның бик күпләре, туган телдән ваз кичеп, урысча сөйләшеп яшәүне исән калу юлы дип сайлады;

— әдәбият мәсьәләсе. Сталин чорында безнең әдәбият культка хезмәт итте, торгынлык елларында — җитәкчеләр мафиясенә. Кызганычка каршы, минемчә, әдәбиятыбыз халыкка хакыйкатьне җиткерә алмады. Халык — әдәбияттан, бер уңайдан, әдәбиятның нигезе булган телдән дә бизде. Бу процесс әле һаман дәвам итә.

Кадыйр Сибгатуллин
(1942-1994)

ШӘҺӘРЛӘРДӘ ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫЛАРЫ

Дәрес эзли. Сәгать, вакыт эзли,
Мәктәп буйлап эзли балаларын.
— Укысыннар! Тукай теле бит! — ди,
Үгетләргә чыккан аналарын.

Әкият укып уздыра ул көн дә
Ятим татар теле дәресләрен.
Унөч яшьлек малайларга бүген
Өйрәтмәкче татар хәрефләрен.

Рус телендә тәрҗемәсен ясап,
Тоз сипкәндәй канлы яраларга.
Үзебезнең телне өйрәтә ул
Үзебездә туган балаларга…

Кайда Тукай?
Кайда Такташ? Сәйдәш?
Чит ил җыры барын алыштыра.
Унөч яшьлек малай күзләрендә
Моңсыз-җансыз безнең язмыш тора.

Гафу итмәс халык, телне кыйнап,
Тәхетләрдә утыручыларны.
...Бер гаепсез башын иеп йөри
Татар теле укытучылары.

....

Мөҗәһит Әхмәтҗанов

ВЕТЕРАН — «ВЕТЕР» СҮЗЕННӘН

5 нче сыйныфта татар теле дәресе бара. Укучылар сүзләрнең дөрес язылышы буенча күнегү эшли. Чират «ветеран» сүзенә килеп терәлде. Тактадагы укучы аны «и» хәрефе белән язып куйды. Арттагы рәттән берәү төзәтмә кертте:

— Тамырына кара, «ветер» сүзеннән алынган бит! Шуны да белмисеңмени?

«И» тиз генә «е»гә төзәтелде. «Ветеран» сүзе дөресләнде. Мөгаллим буларак, миңа кызык тоелды бу. 5 нче сыйныф укучысы сүзнең этимологиясенә, ягъни килеп чыгышына мөрәҗәгать итә түгелме соң?

— Син нәрсәгә нигезләнеп, «ветеран» сүзе «ветер» сүзеннән килеп чыккан, дип әйтә аласың? — дип кызыксындым.

— Нәрсәгә дип инде, абый... Ветераннар бит алар карт инде. Катырак җил иссә дә, аварга гына торалар, — дип җавап бирде укучым.

...Мин үзем дә ветеран, пенсионер исемен йөртәм. Әллә ничек, кыен да, кызык та булып китте.

АЧЫШ

Тарих дәресе. Борынгы Мисырда дин темасын аңлатканда, Ра дигән Кояш алласы турында сөйләп туктагач, бер укучы:

— Абый, алайса «радуга» сүзе «Раның дугасы» дигән сүз булып чыга инде, әйеме? — дип сорады.

Күңелемә рәхәт булып китте. Аның үзенчә тел галиме Гомәр ага Саттаровныкыннан да ким булмаган ачышы иде бит бу.

РӘХМӘТ ИНДЕ

Мөслим урта мәктәбенә берзаман Чаллы язучылары кунакка килеп төште. Әдипләрнең берсе «Нур» гәзитендә җаваплы сәркатип булып эшли икән. Очрашу тәмамлангач, бер укытучы сәркатип янына килде дә:

— Рәхмәт инде сезгә... Минем кызны бик матур итеп баскансыз, — дип үзенең рәхмәтен белдерде.

...«Нур» гәзитендә теге ханымның кызы турында мәкалә һәм фоторәсеме басылган булган икән.

АВЫР ҖӨМЛӘ

Синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмләләр турында яңа тема аңлатканнан соң, тактага бер җөмлә яздым да, укучыларга:

— Бу нинди җөмлә? — дигән сорау бирдем. Ягъни синтетикмы, әллә аналитикмы, дип соравым иде.

Тыныч кына утырган Галимне бастырдым. Ул бераз уйлангандай итеп торды да, башып кашып:

— Бу — авыр җөмлә, абый, — диде.

*Сәхифәне **Рөстәм Акъегет***
Татарстан радиосының
«Тел күрке — сүз» тапшыруы язмаларына нигезләп әзерләде. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

....

Адлер Тимергалин

АТ — Гомумтөрки сүз — *елкы/йылкы.* «Ат» сүзенең борынгы төрки формасы — *ахта,* монгол телендә — *агыт.* Борынгы төркичәдә ат мәгънәсендә *йүнд* сүзе дә теркәлгән. Телдә күзәтелә торган бахбай сүзе (ат чакыру ымлыгы) шулай ук *ат* мәгънәсенә ия. Осетин телендә *баек* — ат, Вятка ягы руслары сөйләшендә *бах* —«кляча». Себер татарларында ярым кыргый атны *имнек* дип атыйлар. Охшаш сүз байтак кына телләрдә дә бар.

Күп кенә галимнәр атны беренче башлап төркиләр кулга ияләштергән, дигән фикердә. Бу хәл моннан дүрт мең еллар элек Евразиянең дала һәм урмандалаларында булган, дип уйлыйлар.

Татар кешесе атны гомер-бакыйга яраткан, ат исемен мәңгелек җырларына кушып җырлаган, чөнки *«кара да гынай урман, караңгы төн, яхшы атлар кирәк лә үтәргә...»* Ат менгән татар җайдагы тимер «яраплан»нарга кадәр үк үзен очар кош итеп тойган. Такташ та: *«Бирегез ат миңа! Кем, әй? Мин атланыйм! Могҗиз көчләр бармы? Бирегез, канатланыйм!»* — ди. Ә Тукай әйтә: «Без тынычта аттан артык эшлибез!» — ди... Әгәр кеше кыргый атны кулга ияләштереп, тулпар иткән булса, адәмнең үзен кеше итеп малкае үстергән, тулпары аны алга алып барган — тукландырган һәм тәрбия кылган, гуманлы булырга, адәм булырга өйрәткән... Төрки сугышчысы яраланып, атыннан егылып төшә калса, аның өйрәтелгән аты, җайдак янына ятып, аңа ияргә утырырга булышкан һәм хуҗасын сугыш кырыннан алып чыккан...

Гомумән, атларның акылга ия булуы — бәхәссез факт. Тренировка үткән сугыш атларын моңа мисал итеп китерергә мөмкин. Мәс., 1815 елда Ватерлоо янындагы сугыштан соң сэр Эстли Купер бер дюжина (унике) яралы ат сатып алып, аларны дәваларга ниятли. Чыннан да дәвалау яхшы нәтиҗә бирә, атлар һәммәсе дә аякка баса. Эстли Купер аларны паркка иреккә чыгаргач, шуңа таң кала: болар бернинди командасыз-нисез бер саф булып тезеләләр, атакага ташланалар, аннан кире борылып кайталар... Һәр иртәне алар шушы күнегүләрен зур канәгатьләнү белән

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә. Автор искәрткәнчә, «...бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде».

кабатлый башлый. Мондый бушлай спектакльне карарга ерак җирләрдән дә халык килә торган була...

Бездә атларны яше һәм җенесе буенча төрләргә бүлү системасы шактый җентекле итеп эшләнгән. Мәс., *айгыр* — иркәк ат, *асау айгыр* яки *өер айгыры* — токым иркәге, *азман* — печелергә билгеләнеп тә, печелмичә калган айгыр, *бия* — инәк ат, *байтал* — әле колынламаган яки колынлаудан туктаган бия, *тай байтал* —ике яшьлек бия, *конан байтал* — өч яшьлек бия, *ту бия* — симертелә торган бия, *кырыс ат* — кызрач ат, кысрак — бөтенләй колынламый торган бия, *колын* (колкай, көлкәй, көләш) — бер яше тулмаган ат, *кырыкмыш* — икенче яшькә киткән яшь ат, *тай, ябага тай* — ике яшьлек ат, *тай-тулак* — төрле яшьтәге колыннар, *конан* — өч яшьлек ат, *дүнән* — дүрт яшьлек ат, тулак — бишенче яше белән бара торган ат, *алаша* — печтерелгән ат (Тау ягы-Тархан сөйләшендә алашаны *къазакъ ат* диләр).

Бик ябык, бетеренгән атны татар җәләк дип атаган (диалект). *Озын торык* дип озын гәүдәле атка әйтәләр.

Р.Әхмәтьянов атларның бәдән төзелешенә һәм холкына бәйле шактый күп атамаларны телгә ала («Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары», 2003). Мәс., *чабышкы* — узыш аты, юрга һәм *юртак* — чабу рәвешләре буенча бирелгән атамалар, *чаман (чәмән)* — әкрен йөрешле ат, *чалык* — тиз йөрешле ат, *чарыс* — тиз йөрешле ярсу ат, *җилаяк ат* — чалык ат, *артак* — кыргыйлашкан, өйрәтелмәгән яисә холкы бозык ат, *тухшун* — көтмәгәндә тибә торган холыксыз ат. Шәп йөреп, тиз арый торган атны *авык ат* дигәннәр. *Йөремтәл ат* — бер урында гына торырга яратмый торган, йөремсәк ат. *Ярашык* — чабыш өчен алдан күнектереп куелган ат. Артын сикертеп, атланган кешене егып төшерә торган атны Себер татарлары *мөңки торган ат, мөңкөшәк ат* диләр.

Ат төсләре: ак, акбүз, алмачуар, болан, бурлы, бүз (мәс., бүз байтал), бүртә (саргылт-ак, русча — *мухортый*), җирән, кан җирән, калтар, кара, кир яки кире ат — борын очлары, аяклары сары төстә булган туры (көрән, җирән) ат, коба, коба кызыл (русча — *муругий*), коба туры, кола, коңгыр, көрән, күк (мәс, күк байтал), күк-ала, күк-җирән, кыяр-чуар, сары, тимеркүк, таргыл, туры, тәңкә-чуар, чагыр, чал, чалка, чуар, чел, чөлкәр, җара, җирән һ.б. (барысы утыздан артык). Бу төсләрнең кайберләре татардан рус теленә дә кереп үзләшкән (*буланый, каурый, чалый, чубарый*

кебек). Бүртә ат белән русча *мухортый* сүзләренең охшаш яңгырашы да колакны сагайта.

Маңгаенда һәм томшыгында ак тап булган атны *кашка* дип (Мәхмүд Кашгарыйда – *угар ат*), ак аяклы атны *чаптар* дип атыйлар («ялы һәм койрыгы чал булган, аксыл җирән ат» дигән билгеләмә дә бар).

Эшкә иң яраклы яшьтәге атларны *татау ат* дигәннәр.

Даһи Гомәр Хәйям (XI-XII гасырлар) үзенең бер трактатында атларның фарсы телендәге 42 төрле төсен атап, ул атларның сыйфатларын күрсәтә. *«Элекке заманнарда,* – дип яза ул, – *бер генә халык та атларны, аларның өстен якларын һәм кимчелекләрен фарсылардан артык белмәгән, чөнки фарсылар ул чакта бөтен дөньяга хуҗа булганнар һәм гарәптә яки үзләрендә нинди яхшы ат күренсә, аларга китерә торган булганнар. Бүген исә бер генә халык та моны төркиләр хәтле белми, чөнки болар көне-төне ат белән шөгыльләнәләр һәм бөтен дөньяга алар хуҗа».*

Борынгы төркиләрдә атлы гаскәр төркемнәре, кайда урнашуына карап, төрле төстәге атларга атланган була. Мәс., көнбатыш канаттагы гаскәри атлар барысы да акбүз, көнчыгыштагылары соры (кашка), төньяктагылары кара, ә көньяктагылары җирән булган.

Бөгәч – зур, йомры гәүдәле, бик көчле ат; *субай (субагай)* – озын торыклы, сылу гәүдәле ат; *җабай (ябай)* ат – кыска аяклы тәбәнәк ат; *казак ат* – алаша (Тау ягы сөйләшендә); *ядау* яки *җәләхә* – начар, арык, бетешкән ат; *маштак* (фарсыча пастак) – тәбәнәк ат; *көмре ат* – калку *томшыклы* ат токымы; *бөкрәч ат* – рус халык әкиятендәге Конёк-горбунок. һ.б. Мифологиядә канатлы эт *комай* дип аталган. *Канатлы ат* (дөлдөл) – пегас (поэзия символы).

XIX гасыр азакларында Россиядә хәрби-ат исәбен алу вакытларында барлык атларнаң 60-65 проценты тәбәнәк токымлы (дөресрәге – токымсыз) буларак теркәлгән, ягъни аларның сыртларына кадәр биеклеге 1 аршын 14 карыштан артмаган.

Менге атлар арасында дон атлары, кыргыз, башкорт, калмык, текин, кабарда һ.б. токымлы атлар югары бәяләнгән.

Татар һәм башкортлар календарь буенча елкы елында туган угылларына «Елкыбай» исеме кушканнар. Хәтта елкы елының ничек киләсен дә Кояш чыкканда кайсы атның Кояшны беренче булып күрүенә карап гөманлаганнар. Мәс., әгәр Кояшны туры ат күргән икән, елны әйбәткә юраганнар.

«Татар ат дирбиясенә игътибарлы булган, атын матур итеп «киендерергә», бизәргә яраткан. Атның сәламәтлеген, чисталыгын кайгырткан. Әйтик, татар тимерчеләре арасында ат дагалау осталары булган. Әле безнең көннәрдә дә, 1986 елда, Казан ипподромы җайдагы Ренат Гайнуллин Түбән Новгородта (ул чагында Горький шәһәре) үткәрелгән бер бәйгедә атны 12 минут 28 секундта дагалап, беренчелекне яулап алган иде.» (Милли архив директоры Дамир Шәрәфетдиновның бер әңгәмәсеннән.)

Шулай да Казанда атлы һәйкәл юк. Шәһәр ипподромы каршындагы калай малай белән калай малкайны исәпкә алып тормыйбыз. Бу хакта шагыйрь Марсель Галиев тә күптән борчыла: *«Ханлыкка нигез салган Олуг Мөхәммәдкә шундый [атлы] һәйкәл куелу – милләт бар, яши һәм яшәячәк икәнен раслау булмас идемени»,* – дип яза ул.

Әйе, татар атка һәйкәл куярга бурычлы. Юк, ул аны иярләмәсен, иркә тулпарына йөгән салмасын, муеныннан кочып янәшәдә яланаяк килеш басып кына торсын, ә иңенә тулпарының озын толымнары салынып төшсен. Чөнки элек татарның һәм атның чәче-чәчкә бәйләнгән булган. (Соң булса да уң булсын дигәндәй, шулай да Татарстанның Нурлат шәһәрендә атның *үзенә генә* куелган һәйкәл бар

икәнен искәртик. Арт аякларына баскан гайрәтле ат һәйкәле шәһәрнең үзәк мәйданында тора.)

Нурлат, Әгерҗе һәм Әлки муниципаль районнарының гербында ат сурәтләнгән булуы турында да әйтеп китик.

XVII гасыр урталарына кадәр Мәскәүне һәм башка рус шәһәрләрен атлар белән тәэмин итү эше башлыча татар кулында була. Ә борынгырак чорда Киев Русена атларны кыпчаклар китереп сатканнар. Рус елъязмалары андагы мал базарында *Велес* дигән алла сыны торган, дип сөйли. Фәндә Велес/Волос исемен «вол/мал иясе» дип аңлатучы версия дә бар икәнен әйтеп китү урынлы булыр.

Казан каласының үзендә ат сәүдәсе өчен махсус базар (*Елкы мәйданы* – «Коневая площадка») эшләп килгән.

1712 елда Пётр патша чыгарган указ нигезендә Россиядә дә нәселле атлар үрчетү өчен заводлар оештырыла башлый.

1887 елда Н.Д.Сазонов дигән кеше Спас өязендә *ат заводы* ачкан. Татар сәүдәгәре Ишморатов Габдрахман Әхмәт улы да нәселле атлар үрчетүгә зур өлеш кертә. Арча төбәгендә ул оештырган ат заводында атларның күпчелеге орлов токымлы булып, ул Америкадан саф токымлы юргалар да кайтарткан.

Татар ат чабышларын яраткан, мондый ярышлар сабантуйны бизәп торганнар. Хәтта XIX гасыр азакларында рус җәмәгатьчелеге, хайваннарны яклау сылтавы белән, мондый чабышларны тыярга бик омтылса да, максатына ирешми. Петербург мулласы Гатаулла хәзрәт Баязитов «рус атсөярләре»нә тыныч һәм дәлилле итеп: «Коръән малтуар белән мәрхәмәтсез эш итүгә юл куймый», – дип җавап биргән.

Чабышкы атлар, ярыш буласын сизенеп, биеп-биеп торганнар... Кайчагында җайдагы егылып калган чабышкының ярыштан чыкмыйча, ялгызы гына финишка иң алда килгән очраклары да билгеле. Ата-бабадан калган йола буенча, мондый атка беренчелекне биргәннәр.

Төркиләрдә (мәс., үзбәкләрдә) чыгып килүче яки баеп баручы Кояш ягына чаба алмый торган атның *шапак* дигән махсус атамасы булган.

1988 елдан бирле дүрт елга бер тапкыр (октябрь аеның икенче якшәмбесендә) дөнья күләмендә «Ат көне» билгеләп үтелә. Кайбер Европа илләрендә бу көнне атларны ял иттерәләр, ялларын, койрыкларын тарыйлар, бизиләр, үзләрен көмеш савытларга салган кишер, шикәр кебек тәм-том белән сыйлыйлар. Шулай да: *«Малай чакта безнең хыял атлар иде, Бәйгеләрдә урын бирмәс чаптар иде, Бәйге үткән, атлар беткән бу заманда, Абзыкаем, хыялыңа атлан инде!»* (Гарифҗан Мөхәммәтшин.)

Татар төшендә ат күрүне сөенечкә, байлыкка, ат менүне мәртәбәле булуга юрый.

//Башкорт аты – ат токымы. Ялан ат – иярсез ат. *Җикмә ат* – җигеп йөрергә яраклы ат. *Төпке ат* – төпкә җигелгән ат. *Мичәү аты* – янга җигелгән ат. *Менге ат* – атланып йөрүгә күнектерелгән ат. Электә сугыш эше өчен яраклы менге атларны аерым атап күрсәткәннәр. «*Атыңнан кан чыгарма. Минемчә, аннан катырак гаеп юктыр*» («Мөнйәтел-гозат» китабыннан.) Бу сүзләр Болгар йортына Багдадтан илчелек җибәргән әл-Мөкътәдир Биллаһ хәлифәнең (908-932) атбагарлар башлыгы Мөхәммәд бине Ягъкуб бине Гали Хаззам исемле затныкы булса кирәк.

«Атлы дәверләргә – салават!

Югалмасын юргалар, армасын аргамаклар, чалыкламасын чаптарлар, елкылдасын елкылар, айгылдасын айгырлар...» Марсель Галиевтән.

Төркиләрдә уенда яки ярышта иң кыйммәтле малыңны – атыңны «салып» уйнау атлашу дип аталган.

Гарәпчә ат – *фәрәс.* Кыргый ат – *тарпан.* ■

АК КЫЯ

Ак Кыя (Aq Qaya, Акъ Къая – кырым-татарча) – Кырым ярымутравының Биек Карасу елгасы үзәнлегендәге кыя. Үзәнлектән – 100 метр, диңгез өсте тигезлегеннән – 325 метр биеклектә. 1981 елдан республика күләмендәге табигать һәйкәле булып исәпләнә.

Кыя борынгы океаннан тупланган палеоген акташ, ком һәм акбурдан гыйбарәт. Заманында галимнәр биредә 50 миллион ел элек яшәгән китның бик яхшы сакланып калган скелетын тапкан. Борынгы кешеләр (неандерталец, мустьер чоры) яшәгән мәгарәләрдә исә мамонт, мәгарә аюы, болан, сайгак, борынгы үгез, кыргый ишәк һәм кыргый ат сөякләре табылган. Соңрак биредә сарматлар (борынгы төркиләр) яши башлаган. Алар кыя түренә юлбашчыларын җирли торган булган. Кыядагы иң зур, риваятьләргә кергән мәгарә — Алтын Тишек!

Урта гасырларда Ак Кыя һәм тирә-юньдәге уңдырышлы туфраклы үзәнлек затлы Ширин нәселеннән чыккан татарларга күчә. Ширин ыруы исә Идел, төгәлрәге — Нократ (Көмеш Елга) буенда яшәгән Дангы бәйдән (Чыңгызхан нәселе) башлана. Туктамыш хан Дангы бәйнең улы Рухтимер бәйгә үзенең сеңлесен кияүгә биргән. Тора-бара бу нәсел ханнар — Гәрәйләр ыруы белән дә туганлаша башлый. Никах вә туй йолаларын алар Ак Кыя өстендә уздырган. Ширин нәселе «Идегәй» дастанында да телгә алына.

Мәгълүм булганча, «Идегәй» дастаны болай тәмамлана:

…Идегәйнең башын кискән Барык булды,
Башын китергән Ширин булды…
*Кырым, Казан, Аҗдаркан**
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды.

Биредән дөньякүләм әһәмияткә ия Бөек Ефәк Юлы үткән, XIII гасырда сәүдә каласы — Карасубазарга (хәзер — Белогорск, 1944 елда кырым татарлары сөрелгәч, Сталин фәрманы белән кушылган атама) нигез салынган.

…1620 елда әсир төшкән Богдан Хмельницкийны, упкынга ыргытырга дип, шушы кыя башына алып менәләр. Бер татар морзасы, аны кызганып, акча түли, гетман исән кала.

Совет чорында Ак Кыяда һәм Карасу үзәнлегендә «Человек с бульвара Капуцинов», «Всадник без головы», «Вождь краснокожих», «Звезда и смерть Хоакина Мурьеты», «Чипполино» кебек кинофильмнар төшерелә. Урыс телендә. Татарчасына исә, әлбәттә инде, гадәттәгечә, «өлгерә» алмаганнар…

Морад Дусай

*Аждаркан — Әстерхан

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның сентябрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Фәкыйрьләр мәктәбе

Ошбу сентябрь җидесендә якшәмбе көн мәдрәсәи «Мөхәммәдия»нең фәкыйрь вә ятимнәр өчен булган шөгъбәсендә дәресләр башланачактыр. Ватан сугышына киткән гаскәри балалары да бушлай укытылачак. Кирәк кадәр китап вә язу әсбабы биреләчәк. Теләгән адәм идарәнең шөгъбә вәкиле, Ак мәсҗед[1] мәхәлләсенең мөәзине Бәдигъ әфәндегә мөрәҗәгать итсен. Мәдрәсәи «Мөхәммәдия» идарәсе.

Кояш. — 1914. — №500. — 3 сентябрь.

Тукай каберенә таш

Бу җәйдә Казанда мосафир булган затларның бик күбесе Тукай каберенең бу көнгә кадәр ташсыз вә ихатасыз торуыннан рәнҗенеп сөйләделәр, Казан яшьләренә бу кадәр игътибарсызлыклары өчен үпкәләр бәян иттеләр. Ләкин бу хөрмәтле кабер бу көнгә кадәр әле ташсыз вә ихатасыз торуында дәвам итә.

Пороховой имамы Габделбари әфәнде Мөәминов[2] бу ел Мәкәрьядән Тукай кабере өчен махсус бер таш китерткән иде. Мәгълүм булганча, Габделбари әфәнде Казандагы таш язучыларның маһирларыннан хисапланадыр. Тукайның тәкфин-тәҗһизе[3] белән шөгыльләнгән дуслары мәзкүр ташны барып карап, муафикъ [яраклы] тапсалар, аны яздыртып куйдыртырга тәшәббес итсәләр [керешсәләр] бик күркәм булыр иде. Тасдыйк ителмәгән [расланмаган] вә ителүе әле мәгълүм булмаган җәмгыятьләрнең[4] вөҗүдкә чыгуын [барлыкка килүен] көтеп торганчы, шагыйрь кабере ташлы ителсә, бик тиешле эш кылынган булыр иде. Моңар без әрбабенең[5] игътибарын җәлеп итәбез.

Кояш. — 1914. — №504. — 8 сентябрь.

Кызлар мәктәбе

Фатиха ханым Аитова[6] мәктәбендә кабул имтиханнары башланды. Дәрес укулар 10 сентябрьдә башланачак. Ләбибә ханым[7] мәктәп бинасы зур янгыннарда яну[8] сәбәпле, бу ел сабак башлаулар яңа йорт салынып беткәнгә кадәр кичеккән. Бу мәктәпнең бинасы якын көннәрдә тәмам булачак вә 15 сентябрьдән калмыйча сабаклар башланачак, диләр.

Кояш. — 1914. — №505. — 9 сентябрь.

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Ак мәсҗед — Галиев мәчете, 5 нче җамигъ мәчет — Тукай һәм Париж Коммунасы урамнары чатындагы 40/22 йорт. Имамы — Галимҗан Баруди.

[2] Габделбари Мөәминов — имам, ташка уеп язучы, хаттат.

[3] Тәкфин-тәҗһиз — кәфенләү, мәетне күмәргә әзерләү.

[4] Г.Тукай вафатыннан соң, Казан шәһәрендә аның исемендә җәмгыять ачырга уйлыйлар. Мөгаен, бу җәмгыять ачылмагандыр. Кара: Кояш. — 1914. — №352. — 4 март.

[5] Әрбабе — биредә әрбабе каләм, ягъни каләм әһелләре күз уңында тотылса кирәк.

[6] Аитова Фатиха Габделвәли кызы (1866-1942) — иганәче, җәмәгать эшлеклесе. 1897 елда Казанда кыз балалар өчен мәктәп оештыра.

[7] Хөсәенова Ләбибә Һади кызы (1880-1920) — педагог. 1904 елда Казанда кыз балалар өчен мәктәп оештыра.

Дога

Дүшәмбе көн 8 сентябрьдә Ак мәсҗедтә ахшам намазыннан соң Казанның бөтен имамнары вә хазирун[9] һәм дә өяздән Казанга килгән имамнарның хозуры белән гаскәрләребезнең Галициядәге мозаффарияте[10] мөнәсәбәте белән шөкранә догасы кылынды.

Ахшам намазы укылып, догалар кылынганнан соң, дамелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләре михрабта халыкка каршы аякка торып гарәпчә хәмед вә салаваттан соң, төркичә[11] сугышның китеше, хәзерге хәле, бу сугышка сәбәп булган германнарның золым юлы белән сугыш ачканлыгы, Ватаныбызның һәммә халкы бәрабәрендә без мөселманнарга да бу золымның тәэсире булганлыгы, дәүләтебез гаскәренең галәбәсе [җиңүе] безнең өчен иң матлуб [теләнгән] икәнлеге вә безнең Галициядәге олуг мозаффариятьләр [җиңүләр] хакында кыскача изах [мәгълүмат] бирде. Моннан соң, янә гарәпчә хәмед вә салаваттан соң, төркичә падишаһ хәзрәтләренә, зәүҗәи мөхтәрәмәләренә [хатынына], әһле бәйтенә [сарай әһелләренә], вәли гаһед[12] хәзрәтләренә, әгъян дәүләтебезгә[13] тынычлык, саг вә сәламәтлек, гаскәребезгә галәбә теләп, гомум мөселманнарга сәгадәт теләп дога кылды. Зикер ителгәннәрнең һәрберенә аерым-аерым кылынган дога вакытында кычкырып: «Амин!» — дип тордылар. Дога мәрасиме шуның белән тәмам булды. Сафлар артында полициядән бер вәкил бар иде.

Кояш. — 1914. — №506. — 10 сентябрь.

Гаскәриләр файдасына

1914 елда 11 сентябрьдә сугышта мәҗрух булган гаскәриләр файдасына Нигъмәтҗан Мөхәммәдҗанов рәфикасе [хатыны] Камәрия ханым Кәмалетдинова үз иҗтиһады берлән шәһәр башлыгыннан талонная книга алып һәм полицмейстердан печать бастырып, ханым вә туташлардан иганә җыярга кереште. Иганәләр ошбу урында кабул ителә: 5 нче частьта Мыловаренная урамда[14] Нигъмәтҗан Мөхәммәдҗановның үз йортында.

Ханым вә туташлардан иганә кылмакларын үтенәбез. Нинди генә нәрсә булса да кабул ителәдер.

Суфия ханым Агиева

Үткән язда Петербургның хатын-кызлар өчен булган гали тыйббия [югары медицина] мәктәбен тәмам иткән Суфия ханым[15] бу көннәрдә Петроградта булып, аннан хатын табибәлек шәһадәтнамәсен алып кайтты һәм авырулар кабул итә башлады. Киләсе кышта ул «Шәрык» клубында үзе ихтисас [белгечлек] иткән мәсьәлә хакында берничә лекция укырга хәзерләнәдер.

Кояш. — 1914. — №508. — 12 сентябрь.

---

[8] Казан шәһәрендә 1914 елның 29 апрелендә (13 маенда) бер көндә ике зур янгын була.
[9] Хазирун — күз алдында, шунда булучылар, биредә мәчеткә җыелган мәхәллә һәм тирә-як халкы күз алдында тотыла.
[10] Галициядәге мозаффарияте — 1914 елның август-сентябрь айларында Галициядә Беренче Бөтендөнья сугышының иң зур бәрелешләре була. Россия Көнчыгыш Галицияне яулап ала, австриялеләр җиңеләләр.
[11] Төркичә — ягъни татар телендә.
[12] Вәли гаһед — патшаның үзе урынына тәхеткә утырачак варисы.
[13] Әгъян дәүләтебезгә — ягъни дәүләт башлыкларына.
[14] Мыловаренная урам — хәзерге Фаткуллин урамы.
[15] Суфия Агиева — табибә, күренекле язучы Гафур Коләхмәтовның сеңлесе, мәгърифәтче, «Ак юл» журналының баш мөхәррире Фәхрелислам Агиевның хатыны.

Гаспринский рухына дога

Бөек остаз рухына[16] җомга көн Казан мәсҗедләрендә догалар кылынды. Дамелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәт мәсҗедендә әтраф [тирә-як] имамнары хозурында ахшам намазыннан соң Коръән хәтем ителеп, остазның рәхәт рухы өчен догалар кылынды.

Печән базарында

Печән базарында Госманов йортында[17] торучы Әхмәдҗан Сафиуллин дигән 19 яшьлек егет, гаиләсе белән әрләшкәннән соң, серкә эчеп агулан-ган хәлдә Шамов шифаханәсенә[18] җибәрелгән. (Мөселманнардан мондый кабахәтлекләр ишетелми иде. Бу егет агулану кабахәтлеге кылучыларның беренчесе булса кирәк.)

Шакшы тоткан өчен

11ендә 2 нче участок мировая судьясы Большая Мещанская урамын-дагы[19] йорт хуҗасы Шәехгаттар Иманаевка йортын шакшы тоткан өчен 5 сум штраф түләргә хөкем кылган. Судья хөкемнең карарын укып бетермәс борын, Иманаев эшләпә киеп чыгып киткән. Судья аны яңадан чакыртып кертеп: «Ник башыңа кидең?» — дип сорагач, ул: «Салкыннан саклану өчен кидем», — дигән. Судья Иманаевның бу эшен карар укылып бетмәс борын чыгып китүгә хисаплап, канун буенча хөкемнең карарын тыңлаудан тартынуда гаепләп, янә 5 сум штрафка яки бер көн ятарга хөкем кылган.

Кояш. — 1914. — № 509. — 14 сентябрь.

Мәҗрухларга укырга

Төрле шифаханәләрдәге мәҗрух мөселман гаскәриләребезгә укырга ки-тап вә гәзитәләр кирәк. Бу ихтыяҗны җитештерү өчен сатып алып яки паширләр тарафыннан ихсан [изгелек] ителү ысулы белән тәгәлләнүен көтү уңайсыз, бәлки һәркем үзе өчен алып, укып чыккан китабын яки газетасын начальствоның рөхсәте илә шифаханәгә бирә барса, һәдия итүчеләр өчен дә җиңелгә киләчәк, мәҗрухларыбызның ихтыяҗлары да үтәләчәктер.

Мөселман карендәшләр мондый иганәне мәгалмәмнүнийять кылырлар [шат-ланып кабул итерләр] вә карендәшләре булган мәҗрух гаскәриләребезнең күңелләрен җуатырга тырышырлар, диеп өмет ителәдер.

Кояш. — 1914. — №510. — 15 сентябрь.

Хәерчелек белән «кәсеп итүчеләр»

Соңгы көннәрдә хәерчелек белән «кәсеп итүчеләр»нең иске солдат киеме сатып алып, киенеп, мәҗрухка сабышып «кәсепләрен рәваҗландырганнары»[20] сизелә башлаган. Мондыйлардан ике кеше тотылып, берсе 15 елга крепость-ка, икенчесе өч айга төрмәгә ябылырга хөкем ителгәннәр.

1914. — №513. — 18 сентябрь.

---

[16] Исмәгыйль Гаспринский 1914 елның 11 (24) сентябрендә вафат була.
[17] Госманов йорты — Печән базары (хәзерге Париж Коммунасы) урамында 1877 елда сәүдәгәр Мөхәммәдгали Госманов (1801-1878) төзеткән йорт.
[18] Шамов шифаханәсе — хәзерге Калинин урамында 1908-1910 елларда сәүдәгәр Я.Ф.Шамов белән хатыны А.Х.Шамова иганәсенә төзелеп, шәһәргә бүләк итеп бирелгән бина.
[19] 2 участок, Большая Мещанская урамы — хәзерге Нариман урамының Г.Камал урамы белән киселешенә кадәрге өлеше.
[20] Рәваҗ — уңышлы кәсеп итү мәгънәсендә.

Мөхтәрәм мөхәррир әфәнде

Ошбу түбәндәге юлларны гәзитәгезнең иртәгә чыккан номерына, тиешле кыйсемендә [өлешендә] кыстырып чыгаруыгызны түбәнчелек илә үтенәбез.

Казанда 27 сентябрьдә мәҗрухлар файдасына галәмәт сату көненә мөселманнар кыйсеменә — 15 нче районга «Шәрык» клубы бинасы тәгаен ителде. Мәзкүр көн галәмәт сатарга теләүчеләр «Шәрык» клубы конторына һәр көн иртә сәгать 11дән кич 6га кадәр килеп, язылуларын үтенеләдер. Мөселманнарга уңайлылык өчен мөселман кыйсеме районнарында кызыл хач урынына кызыл йолдыз галәмәтләре сатылачак. 26 нчы сентябрьдә көндез сәгать 1дә кружкалар таралып тәмам ителергә һәм кичтән сата башларга керешергә тиеш булганлыктан, сатарга теләүчеләрнең мәзкүр вакытка кадәр язылып бетүләре мәрҗүдер [өмет ителәдер]. 15 нче район мөдирәсе Гаишә Терегулова[21]. Казанда кызыл йолдыз сату көненең 15 нче һәйәт [комитет] идарәсе.

«Кызыл йолдыз» көне

27 нче сентябрьдә булачак «Кызыл хач» көнендә мөселманнарга кызыл йолдыз сатар өчен 18 нче районга сатучы кирәк. Язылырга теләгән кемсәләр һәр көн иртә сәгать 11дән кич 6га кадәр Яңа Бистәдә Олуг Симбирская[22] урамындагы ханәбезгә яки Екатеринская[23] урамындагы йортыбызга килеп әйтүләрен үтенәбез. 18 нче район мөдире: мелла Кәшшаф Тәрҗемани[24].

Кояш. — 1914. — №515. — 21 сентябрь.

Бишбалтада

Бишбалтада Мәскәүский урамында[25] Эккерт йорты якынында Мөхәммәдгали Вафин дигән Казан мещаны белән бер запасный мөселман вагонга утырганда урын өчен тартыша башлаганнар. Тартышу тора-тора этешү-төртешүгә барып җиткән. Эш городовой чакыртуга барып җиткән. Кузнецов дигән городовой килеп, запасныйны хаклы тапкан һәм Вафинны төшерә башлаган. Вафинның кәефе кырылып, городовойны сүккән, төрткән һәм суккан. Шушы эшләре өчен, Вафинны җавапка тарту өчен протокол куелган.

1914. — №518. — 24 сентябрь.

Талчок базарында

Талчок базары[26] каршында тротуарга басып торып үтүчеләргә уңайсызлык кылганнары хәлдә, полиция килеп, тротуардан китәргә кушкач та, китмичә, полиция әмеренә мохаләфәт кылганлыклары [каршылык күрсәткәннәре] өчен Галимҗан Садыйков, Сәедбаттал Миңлебаев, Б.В.Тулинов өсләреннән протокол куелган.

1914. — №523. — 30 сентябрь. ■

---

[21] Гайшә Терегулова (1868-1940) — тәрҗемәче, концерт-кичәләр оештыручы.
[22] Олуг Симбирская урамы — хәзерге Мехчылар урамы.
[23] Екатеринская урамы — хәзерге Г.Тукай урамы.
[24] Кәшшаф Тәрҗемани (1877-1943) — дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин галиме, мөдәррис.
[25] Мәскәүский урам — Бишбалта бистәсендәге хәзерге Клара Цеткин урамы.
[26] Талчык яки талчук базары — иске-москы сатыла торган базар. Бистә татарларында талчокчы вак сәүдәгәрләр шактый булган.

КӨЛКЕ КУА КИЛӘ...

Сирин Батыршин (1896-1969)

НӘНИ ОРАТОР

Өй эчендә уйнап йөргән нәни бала
Үзенә бер кызыклы эш табып ала:
Менеп баса биек артлы урындыкка,
Әйтерсең лә лектор килгән
зур клубка.

Сөйли кызып, тирә-якка кулын болгап,
Гүя аны бик күп халык тора тыңлап.
Ә каршында беркем дә юк.
Һай, шуктыр ул,
Су эчә дә тагын сөйли, әйтерсең лә
Чын лектор ул...

Нәҗип Думави (1883-1933)

БЕР МӘХӘББӘТ ТАРИХЫ

Көзге яңгырдан ышыкланып, су буенда, мунча артында ике авыл егете — «никрутлар» эч серләрен сөйләшеп утыралар:

— Сез аның белән ничек күрешә башладыгыз? Сөйлә әле, иптәш.

— Мин бит һәр көнне аларда булам. Ничек күрешә башладым дияргә, әле бит, иптәш, аның белән чыннан күрешкәнебез дә юк. Тик әле сөешеп кенә йөрибез.

— Ничек сөешә башладыгыз, дим шул?!

— Әй, шәп тә булды да инде ул, малай. Мин белми дә йөри идем. Беркөнне шулай, кулыма көрәк алып, сыер тизәкләрен җыя идем. Уйламадым да, Асма килеп чыкты. Карыйм, малай, бу бәрәңге юарга төшеп бара. Мин лапас астында, ындыр капкасы янында тизәкләр көрәп маташам. Минем янымнан узганда, теге чабатасының бер чите белән минем аягыма басмасынмы! Мин, тизәкле көрәк белән кизәнеп аркасына «шап» иттердем. Ул көлә-көлә китте. Мин дә шулай көлеп калдым. Менә шулай сөешә башладык, малай.

— Соң тагын?..

— Аннары, беркөнне, мин аның атасын, Хисмәтулла абзыйны, ашка чакырырга кергән идем. Асма чиләк белән кер суы түгәргә чыгып бара. Каршук килдек. Мин нишләргә дә белмичә, тоттым да беләгеннән чеметтем дә. Ул кер суын бөтен чиләге белән минем өскә «шау» иттерде.

— Ха-ха-ха!.. Үзе көләме?

— Көлә шул. Мин дә көләм. «Әй, маржа! Җүешләттең бит», мин әйтәм. «Авырттырдың бит, чукынган урыс», — ди. Бусы шулай булды. Менә шуннан соң инде, мин гел аны гына уйлап йөри башладым.

— Шуннан соң күрешкәнегез юкмы?
— Бар, бар! Әле кичә генә, менә мин бик кызык төшләр күреп яттым да, җае килсә, үзенә шуларны да сөйләрмен дип, кичә кичләп кенә аларга барган идем. Ул лапасларында утын алып маташа. Мин дә тиз генә, әйдә, малай, лапаска! Бардым да: «Утын пүләне белән бәрмәсәң ярар иде, җанкаем, — дидем. Ул оялып торган төсле булды да:
— Әллә мине сихерләдеңме, — ди. — Бүген төн буе төшемдә синең белән саташып чыктым, — ди.
— Мин дә шул, җаным, дим, шулай булдым, дим.
Миңа карады да көлде.
— Соң?..
— Шуннан мунчага киттек. Әллә нәрсә генә әйтергә теләгән иде дә җиңгәсе мишать итте. Алар җиңгәсе белән мунчага киттеләр. Мин дә юри генә алар артыннан барган булдым. Җиңгәсе әйләнде дә:
— Ник печтергән тәкә төсле арттан киләсең? — диде. Әй, көләләр, малай. Асманың эче ката. Асма әйтә:
— Көпә-көндез кызлар артыннан йөрсәң, шулай була ул. Егет булсаң, төнлә кил! — ди.
— Әнә, эш пешкән икән, пешкән!..
— Малай! Син кешегә сөйли күрмә инде. Мин бүген төнлә аларның лапасына барып качып торам. Ул инде чыкмый калмас.
— Калмас, калмас! Бар, малай!

Зыя Мансур (1916-1965)

СУКБАЙ

Сукбай кайчак бик бай була.
Ләкин, барыбер, сукбай була.

ӘҖӘТ МӘСЬӘЛӘСЕ

Бер каныкса, әҗәл китми, диләр,
Мин ышанам моңа, әлбәттә.
Ул да ләкин качып йөрер кебек,
Акча биреп торсаң әҗәткә...

Гамил АФЗАЛ (1921-2003)

ГЫЙЛЬМАН ГЫЙЛЬМЕТДИНСКИЙНЫҢ МЕМУАРЛАРЫ

Матур җәйләр үтте, ява карлар,
Ташлап китте безне сөйгән ярлар.
Давыл кебек яшь гомерләр үтте,
Мемуарлар язам, мемуарлар.

1
...Без Латыйп Үсми белән бер,
Кәефләр шәп чагында
Очрашкан идек нигәдер
«Казан» ресторанында.

Төнге уникеләр җитте,
Кузгалмыйбыз, хәлбуки,
Милиция алып китте,
Әллүки-бәллүки.

2
Без Фәсил Күрми белән бер,
Күңелләр хуш чагында
Очрашкан идек нигәдер
«Совет» ресторанында.

Күп анекдотлар сөйләдек,
Ямьле булды ул кичен.
Ун сум штраф түләдек
Тәрәзә ваткан өчен.

3
Без Гали Кәли белән бер,
Кесәләр буш чагында
Очрашкан идек нигәдер
«Парус» ресторанында.

Күп сүз сөйләми генә,
Җырлар көйләми генә,
Ашадык та чыгып тайдык
Акча түләми генә...

4
Без Шамил Шәйхи белән бер,
Шаулы шәһәр читендә
Утырган идек нигәдер
Аэропорт буфетында.

Күтәрүләр ямьле икән
Бокалларны чек итеп.
Самолет очкан да киткән,
Тормаган безне көтеп.

5
Без Бәкер Бетчи белән бер,
Баш авырткан чагында,
Очрашкан идек нигәдер
«Волга» ресторанында.

Пар күгәрчендәй гөрләшеп,
Стаканнар чәкештек.
...Культура өчен көрәшеп,
Үтте дә китте яшьлек.

1969

Әпкәли
(Фаил Шәфигуллин, 1939-1982)

ҖИЛ
РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВКА
(Ак новелла)

Мин — шагыйрь. Мин атналарны ярып алга барам. Баш очымда болыт — төссез симфония, җилле кояш, җилле ай.

Йөзгә яфрак катыш кар сибәли, икебезгә уртак толыбыбыз бар, зәңгәр күзле сылу. Син кайгырма тирәкләрнең яшел лампалары тагын да янар язлар килгәч. Ә хәзер кыш сызгыра урманда. Без өйдә бит, кайгылардан өстен бул! Блокны, йә мине кочакла да, әйдә, толып астына...

Син кертмәдең мине толып астына, туган шагыйреңә сүрән карыйсың син, йолдызларга учак якмыйсың, гомер чатында калдырасың мине. Нишлисең, миңа тагын шампан шикелле бөтерелгән язгы сулар эчеп йөрәк ялкыннарымны басарга туры килә инде.

Хыял фонтаннары ерак ата, ак фикерләр каскадына кадәр. Ылыслардан февраль аккордлары коелып төшә шыбыр-шыбыр килеп. Бу — сөю атнасы...

Мин — шагыйрь, аңлыйсыңмы, сылу?! Миңа кирәге юк йон оекбаш. Мин сүзләрдән бәйләп киям аны, әгәр теләсәм. Телем — станок минем. Телим икән — кырдырам, кисәм, шомартам имәнне, талны. Телем — талкы, сүзләр талкыйм, яшелле-зәңгәрле, кызыллысарылы булып балкыйм...

Хуш, зәңгәр күзле сылу, гомер чатыннан киттем мин йолдызлар чатына. Каршымда йолдызлар базары. Алалар, саталар. Мин дә утырам шунда чумадан өстендә. Бу базар эчендә шигырем һәм мин бер өтер нибары. Юк, өтер генә түгел, һич югы өндәү билгеседер без, әйе бит, шигырем. Кысан монда, черт возьми — башым йолдызга орына, «мә таһәрәтеңне, китер башмагымны « дигәндәй, «мә йолдызларыңны, китер болынымны!»Җитте туйдым барсыннан да. Җил теңкәмә тиде тәмам. Үзәннәрдән тулып җил ага, йолызларга кагылып җил ага, җил комнан киндерә ишә, таулар җилли, иртә дә җил, кич тә җил. Җил чалкан ятып әллә нишли, мөртәт!... Ауный-ауный кешни азгын айгыр кебек, җилне җиңеп, җилфер-җилфер килеп йөргән иде дә, булмый шул! Җил йөрәгемә шигырь ялкыны булып сырышкан. А, кызыл җил — кызыл яктылык! А, зәңгәр җил — зәңгәр яктылык! А, тыгыз җил. А, сыек җил... А, каты җил. А, куштан җил. Җил дә җил! Үземне нинди җилләрдән сакларга да белгән юк!..

(«Тынгысыз каләм», 1977) ■

Мирасворд



Рәис Габдулла төзеде.

8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: «Ника», фут, корт, Даян, Ари, Алла, Гаташ, Плетцензее, ат, Шу, Рамо, хатирә, Әхмәт, яса, Кормаш, маш, ба, имана, Суар, до, Ге, Кави, Лев.
Өстән аска: нида, Әлки, алап, кам, ял, ям, Атнашев, Хәсәнов, арата, Ади, ацетат, миск, ятаган, шор, уяз, әдрәс, Фоат, егу, укра, Шабаев, иш, шар.

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
ЕЛЪЯЗМАСЫ / СЕНТЯБРЬ

465 ел элек (1549)

● Казан ханы Сафагәрәй (1510, Бакчасарай — 1549, Казан) хыянәтчеләр тарафыннан үтерелә.

175 ел элек (1839)

● Казан университеты типографиясендә Александр Казимбәкнең «Грамматика турецко-татарского языка» исемле китабы басылып чыга.

120 ел элек (1894)

● 3 сентябрьдә күренекле тарихчы, археолог, этнограф Михаил Худяков (1894-1936) дөньяга килә.

110 ел элек (1904)

● 16 сентябрьдә язучы Максуд Сөндекле (1904-1981) дөньяга килә.

100 ел элек (1914)

● Күренекле галим, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе Һади Атласиның (1876-1938) «Сөембикә» әсәре китап булып басылып чыга.

95 ел элек (1919)

● «Кызыл йолдыз» газетасында (65 нче сан) 13 яшьлек Мусаның «Кечкенә Җәлил» имзасы белән «Бәхет» исемле беренче шигыре басылып чыга.

80 ел элек (1934)

● 22 сентябрьдә Татар дәүләт академия театрының яңа сезоны Шамил Усмановның «Кичеккән фәрман» пьесасы белән ачыла.

70 ел элек (1944)

● Фашистларның Дахау лагеренда әсир татар шагыйре, подполковник Хәйретдин Мөҗәй җәзалап үтерелә.

65 ел элек (1949)

● «Совет әдәбияты» журналында Салих Батталның «Олы юл буйлап» исемле поэмасы басыла.

55 ел элек (1959)

● Уфада элекке «Галия» мәдрәсәсе булган йортка Мәҗит Гафурига багышланган истәлек тактасы куела.

● СССР элемтә министрлыгы Муса Җәлил рәсеме төшерелгән почта маркасы чыгара.

20 ел элек (1994)

● 22 сентябрьдә «Казан Кремле» тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы оештырыла.

РӨСТӘМ ХУҖИН

Рөстәм Фаит улы Хуҗин 1975 елның 28 ноябрендә Уфа шәһәрендә туа. Пенза сәнгать училищесын (1996), Мәскәүдәге Россия рәсем сәнгате академиясен (2002) тәмамлый. 2005 елдан — Россиянең Рәссамнар берлеге әгъзасы.

Рөстәм Хуҗин портрет, лирик пейзаж, натюрморт, тарихи, сугыш күренешләре һәм көнкүрешне тасвирлау жанрларында иҗат итә. Борынгы Болгарга багышланган рәсемнәре аеруча киң танылу алды. Аның әсәрләре Россия, Төркия, Франция һәм Германиянең шәхси һәм дәүләти тупланмаларында саклана.



«Болгар илендә. «Яңа очрашуга өмет белән». 2000.
Киндер, майлы буяу

«Иман өчен! Болгар хакына!» 2008-2010.
Киндер, майлы буяу

ИНДЕКС:
Татарстанда – 54132
Чит төбәкләрдә – 70275



4 612750 670172